Безнен МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

05
май 2019
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

РАУЛЬ НУРМӨХӘММӘТОВ «ИШЕГАЛДЫ»

Фотолар shaimiev.tatarstan.ru сайтыннан алынды

ЗАТЛЫ КҮРГӘЗМӘ

2 апрель көнне «Эрмитаж-Казан» үзәгендә «Алтын Урда һәм Кара диңгез буе. Чыңгызыйлар империясе сабаклары» дигән күргәзмәне ачу тантанасы булды. Әлеге чарада ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Дәүләт Эрмитажының генераль директоры Михаил Пиотровский катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

05 (305)

май 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

75



64 **ХАТЫЙП МИҢНЕГУЛОВ: ГАЛИМ ҺӘМ ОСТАЗ**
Таһир Гыйлаҗев

104 **ЗУР ИҖАТКА БЕР КАРАШ**
Рәдиф Сәгъди

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Сәгыйть Сүнчәләй**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
9 **Париж выставкасында.** *Г.Гали*
13 **Такталачык: ятимнәр сыенган җылы йорт.** *И.Салихҗан*
16 **«Мәктәп тотып үскән баллы Багъбостан ханым...»** *А.Зиннәтуллина*
23 **Әтрәк әл-Каткан кыйссасы.** *А.Минһаҗ*
24 **Шәрип Шәймиевнең музей-йорты**
27 **Чишмә авылы тарихы**

ТАТАР ГАМЕ

32 **Ихлас күңелле спикер.** *Ә.Фәйзрахманов*
34 **Энгель Фәттахов: «Сабан туе милли горурлыкны арттырырга тиеш!»**
40 **Дөнья бәһасе торырлык инсан.** *Р.Закиров*
42 **Кем ул Эдуард хаҗи Ганиев?** *И.Хәлимов*
44 **Эдуард хаҗи Ганиев ядкяре**
52 **Кулаткы укулары тарихы.** *И.Сафин*
55 **Апанай мәчете: тарихы һәм хәзерге заман.** *Н.Сабиров*
59 **Бөркет биектән курыкмас.** *Ф.Җәүһәрова*
64 **Хатыйп Миңнегулов: галим һәм остаз.** *Т.Гыйлаҗев*
72 **Яшел камин яктысы.** *А.Закир*

ДИНИ МИРАС

75 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

80 **Әгәр Фаил исән булса...** *Э.Шәрифуллина*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

88 **Сугышта җиңеп кайткан әтием.** *Р.Хуҗахмәтова*

91 **Иске Мостяк хатирәләре.** *Ф.Хәсәнов*
95 **Сергей Михалков белән очрашу.** *С.Ибраһимова*

СӘНГАТИ МИРАС

98 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары**
100 **Музыкабыз.** *С.Сүнчәләй*
104 **Зур иҗатка бер караш.** *Р.Сәгъди*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
114 **Симетбаш һәйкәлләре**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы**. *Май*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Мөдәррис Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №О-1097. Тираж – 3353 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 23.04.2019.
Чыгу көне: 07.05.2019
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, "Татар энциклопедиясе" томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Ишегалды»**. 1955. ***Рауль Нурмөхәммәтов рәсеме***

Сәгыйть Сүнчәләй
(1889-1937)

ҖЫРЛАРЫМ – КҮЗ НУРЛАРЫМ!

Әй, минем күңелем ярасыннан чыгучы җырларым!
Әй, җәһәннәм тормышымны оҗмах иткән хурларым!
Таңдагы моңлы азан илне уяткан төсле үк
Яңрагыз сез дә туган җирдә, минем күз нурларым!

Бар татарның күңленә дуслык кояшын кертегез!
Ул да якты дөньяда барлыкны белгертегез.
Бар, булыр, бетмәс татарлар; бар теле – тәмле теле,
Бар җаны, бар яшьләре, үлмәс татар, үлмәс, ди(е)гез.

Күп өмидсезне җуатып, кайгылыга кул сузып,
Күп үлекне тергезеп, сансыз читенлеккә түзеп,
Күп катып беткән күңелләрне төбеннән йомшатып,
Яктылык җырлап, халыкка таң туасын белгезеп,

Моң белән сез җырлагыз! Тик үз татар халкым өчен
Җырлагыз сез – яңрасын тормышны баскан вәхши төн!
Җырлагыз, атсын таңы, чыксын кояш, бетсен газап,
Җырлагыз, күз нурларым! Бик бит кыен, бик бит читен!..

1912 ■

Сәгыйть Сүнчәләй (Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев) 1889 елның 14 (иске стиль белән – 2) августында элекке Саратов губернасының Хвалын өязе Иске Мостяк (хәзер бу авыл Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткы районына карый) авылында крәстиән гаиләсендә туа. 1937 елның 27 октябрендә Соловкида һәлак була.

СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән:

Сафагәрәйнең бәйсез ханнарча эш итүе, әлбәттә, урыс кенәзләренә ошамый: алар, аңардан үч алу максатында, Казан өстенә йөри башлыйлар. Казанлыларның Мәскәүгә уңышлы яу чабуы гына илбасарларның юлын кисә. Һади Атласи язганча: «Сафагәрәй хан булдыклы бер хан исә дә, башбаштак Казан халкы аны яратып бетерми... 1541 елда Сафагәрәй ханга каршы Казанда астыртын кузгалу башланды... Шул елның җәендә Мәскәүгә илче җибәреп, Иваннан Казан өстенә гаскәр җибәрүен үтенделәр. «Без олуг кенәзгә хезмәт итәрбез, ханны үтерербез яисә урыс башлыкларына тотып бирербез», – диделәр. Казанның үзара талаша башлавы Иван өчен чиктән тыш куанычлы нәрсә иде...» Бүгенгебезгә әйләнеп карасак та, гыйбрәтле хәл түгелмени?!

«Сөембикә». Билгесез рәссам эше

Ал бүлмәгә чыккач та, Тимер иңнәрен турайтты, күкрәгән киерде, карашы кабат кырысланды һәм рәхимсез төс алды. Ул бөердән чыккан гайрәтле тавыш белән юлдашларына кычкырды. Нөкәрләр, атларын тиз генә җитәкләп, корал һәм башка кирәк-яракларын барладылар, йөзбашы артыннан барырга булып, иярләренә сикереп менделәр. Тик шул арада Тимергә бер аксөяк – Мөхәммәд бәкнең ышанычлы кешесе килеп ябышты. Котлык морза моңарчы һәрвакыт кәгазь боткасы арасында кайнашты, бер бәрелешне дә үз күзләре белән күрмәде, хәзер аның йөзе тәмам аптырап-каушап калганны белдерә иде. Хуҗасы аңа якынлашып килүче урысларга яшерен хат илтергә кушкан, ә мәҗлесләрдә һәм гәп корганда гына кыюлыгы белән аерылып-ялтырап торган морза хәзер боегып-сүнеп калган, ул кяферләр арасына берүзе барып керүдән өркә икән. Котлык шул мәлдә Мөхәммәд бәк бусагасына җыелышкан нөкәрләрне күреп алган да, элек-электән кыю сугышчы саналган йөзбашы Тимер белән киңәшми генә хәтәр юлга чыгарга курыккан.

– Миңа әфәндем бер бик хәтәр йомыш тапшырды. Чирмешләр җире аша узып, Казанны яуларга килүче урыс гаскәренә каршы барырга тиешмен. – Морзаның тавышы калтырады, ишетелер-ишетелмәс кенә булып калды. – Ялгызым бара алырмын микән, дим. Менә сез юлга кузгаласыз, мине дә үзегез белән алсагызчы, йөзбашы.

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

Тимер, нәфрәт уты көйрәгән күзләрен кысып, Котлыкның тавышында чын-чынлап калтырануны ишетеп, аңа текәлде. «Хуҗабыз бу күзле бүкәнгә шундый җаваплы бурыч йөкләгән, ә бит ул аны яндырырга мөмкин. Нихәл итәсең, әфәндемнең эше – минем дә эш, бу саргайган кәгазь, күгәргән каләм кортын үзем белән алмыйча булмас. Бәкнең миңа кушканын үтәгәч, морзаны озатырга туры килер инде». Әлеге уй-фикерләр мизгел эчендә баш миендә кайнап узды, нөкәрләр, ияргә менгән килеш, аны гына көтәләр иде. Чабышкы атны йөзбашына да җитәкләп китерделәр, озак уйлап торырга вакыт юк.

– Хат Сезнең яндамы соң, морза? – дип, кырыс кына сорап куйды йөзбашы.

Котлык әле дә дерелдәвеннән туктамаган куллары белән муенында асылынып торган кечкенә күн букчага ашыгып шапылдатты:

– Биредә, биредә. Мине сакчылар озата барырга тиеш иде, ләкин үзем Сезгә күбрәк ышанам.

– Алайса, мыштырдап тормыйк, әйдәгез, алга, – дип әмер бирде Тимер. – Безгә ашыгырга кирәк!

Мөхәммәд бәк күзе төшкән хатынны алып кайтырга дип юлга чыгучыларның ераклаша барган ат тояклары тавышын ишетте. Тик урыныннан кузгалып, артларыннан карап калырга ирене, шуңа күрә, Котлык морзаның да аларга ияреп китүен күрмәде. Бәкнең бу вакытта күңеле бик күтәренке иде, ул яшереп куелган җиреннән затлы шәрабын алып, тирән касәгә йотлыгып ябышты. Яшерен эшләр белән идарә итүче ояты качкан түрә муенын чабасы җәза кылычын әле күрми, ә бер генә минут эчендә ишегалдында булып алган вак-төяк хәлләр үзләрен кодрәт иясе дип санаган бик күп хыянәтченең башына җитәчәген, әлбәттә, белми.

Булуы ихтимал фаҗигаләрне алдан сизенеп торган хан да йоклап ятмады: аңа олы илче Тәңреколның гаиләсен камалыштан Нократтагы биләмәсенә яшереп торырга теләгәне мәгълүм иде...

Ә бу вакытта Сафагәрәй ханның уң кулы булган Кечүк углан үзенең җыйнак кына Кырым яугирләре төркеме белән Арча төбәгеннән кайтып килә. Ул анда, хаким исеменнән, Казан өстенә өерелеп килүче урыс баскынчыларыннан башкаланы саклашырга өндәү өчен барган иде. Кечүк углан Арча бәенең ризалыгын алып кайта. Шул ук вакытта алда торган бәрелеш аның үзен дә кызыктыра һәм ымсындыра. Кылыч булып ялтырыйсы корал кын-өнендә күпме йокымсырап ятарга мөмкин! Хәтәр бәрелешкә кереп, дошманның өстенә очып барудан йөрәкне җилкетә, башларны әйләндерә, бугазга-бугаз килеп сугышудан әсәртә торган бу хис-тойгыны ул берни белән дә чагыштыра алмый. Егет көрәш өчен яратылган, сарай тирәсендәге ыгы-зыгы килүләр аңа бик вак һәм игътибарга бөтенләй дә лаек түгел булып тоела. Бүгенге вазгыять шундый: Казан ханы аны якын итте, Кырым бәенең тугызынчы улы буларак, аны Бакчасарайда әле һич кенә ирешә алмастай биеклеккә күтәрде. Кечүк тә Сафагәрәйне үз агасыдай күреп яратты. Шуңа күрәдер, әле кичә генә дуамалрак, җиңел акыллырак булып тоелган угланның сизгер күңеле, тугры карашы ханга һәм Казанга янаган куркынычны беренче көннәрдән үк сизеп алды.

– Казан аксөякләре көтүләре белән Сезне күралмый, – дип, яугирләрчә ачыктан-ачык ярып салды ул бер җае чыкканда. – Әмер бирегез, хакимем, мин, бер дә озак көттермичә, әлеге этләрнең муеннарын борып, Сезнең аяк астына китереп ташлыйм.

Сафагәрәй угланның кайнарлыгын көлемсерәбрәк кабул итте дә, сабыр гына җавап бирде:

– Миңа аларның гаепләрен расларлык дәлил кирәк, калганын үзем хәл итә алырга көчем-куәтем бар, әлһәмделилләһ.

Бу сүзләр Кечүкнең хәтерендә уелып калды. Шул чактан алып ул, тыштан барысына да битараф кебек тоелса да, хәйләкәр һәм тапкыр-зирәк адымнар гына ясый башлады,

моңа кадәр гадәтләнмәгән юллар белән – һәр сүзгә колак салу, сораштыру һәм карап-күзәтеп тору аша уңышка ирешергә мөмкин икәнлеген аңлады. Ләкин казанлылар бик сак кыландылар, шикләнүләрдән, һавада хан гвардиясе башлыгының хыянәт исе тоелудан кала, әлегә бер дәлил дә юк кебек. Ул урысларның һич көтелмәгәнчә, мәкерле рәвештә һөҗүмгә күчүенең Казан түрәләре гаебе белән булуын аңлый, әмма барыбер турыдан-туры раслый алмый иде.

Кечүк менә әле дә, ашыкмыйча гына, кыска тезгеннәрен бушатып, Арча якларыннан кайтып бара. Хан кушкан йомыш үтәлде, инде беркая да ашыгасы юк, ә атының салмак адымнары исә иркенләп уйланырга мөмкинлек бирә. Ләкин шулчак алдан күзәтеп кайтучылар кинәт туктады, юлны карап баручы олы яугир, игътибар итәргә чакырып, кулын өскә күтәрде. Углан, гадәтенчә, тезгеннәрен киеренке учында кысып, зур кыргый мәче сыман, аты өстенә елыша төште. Барысы да колакларын торгызды, ә Кечүк ул арада иң алга очып чыкты да атын туктатты. Өзәңгесенә басып күтәрелә төште дә быкырдык юл тасмасы буйлап кереп югалган урман авызына текәлеп катты. Аннан аермачык булып ниндидер чыр-чу килү, кемнәрнеңдер көрәш-тартыш авазлары, хатын-кызларның өзгәләнеп-өметсезләнеп кычкырганына кушылып, сабыйлар үксүе-елашуы ишетелә иде.

Карурман эчендә ни генә булмасын, бу – кимсетелгәннәрне яклау, батырлыгыңны күрсәтү өчен җай чыккан дигән сүз. Кечүкнең йөзе яктырды, ул кояшта ялтыраган кылычын тартып чыгарды да өскә күтәрде:

– Алга!

Юлдашлары бер тын эчендә кузгалып, мизгел эчендә яңгыр белән изелгән юлны кичтеләр дә әле үзләре дә ни буласын белмәгән көрәш эченә ташландылар. Аланда ишекләре ачык көймәле арбалар өсте-өстенә өелгән, ишекләрдән хезмәтче хатын-кызларның куркынган йөзләре генә күренә, иясез калган атлар янында ат йөртүчеләрнең ук белән һәлак ителгән гәүдәләре аунап ята. Бу төркемне саклап килүчеләр башы бозыклар белән аяусыз көрәштә өстенлек ала алмаган, күрәсең. Кечүк көчсезләрне яклау ягына басарга кирәклеген шул мәлдә үк аңлап өлгерде. Шуңа күрә углан, ике дә уйлап тормыйча, үз кул астындагы яугирләр белән әлегә билгесез кечкенә кәрванны якларга ташланды. Мөхәммәд бәкнең нөкәрләре дә, Тәңрекол гаиләсенә мондый көтелмәгән яклау килүдән каушап калмыйча, кырымлыларга каршы ярсып күтәрелделәр. Әмма көчләр тигез түгеллеге бик тиз аңлашылды. Кырым егетләре мондый алышларда куркусыз, чыныккан булуларын тагын бер кат расладылар. Күз ачып йомган арада диярлек, кодрәтле түрәнең ялчылары көзге юлның сутлы быкырдыгында аунап яталар иде инде.

Каны кызган Кечүк арбалардан коела башлаган хатын-кыз җәмәгатенә күз ташлады:

– Кемнәр буласыз?

Тегеләр, коткаручыга рәхмәт укый-укый, әле генә кичергәннәреннән тынычлана алмыйча, елый-елый, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, нәрсәдер бытылдадылар, Кырым угланы бу хатын-кыз мәһшәреннән иң мөһимен генә аралап алды: болар – олы илче Тәңрекол хәрәмханәсе «кошлары» булып чыкты.

– Кая барырга чыктыгыз соң сез? – дип бүлдерде ул бу озакка сузылырга мөмкин чыр-чу килүне.

– Хуҗабызның Нократ буендагы биләмәсенә. Инде нихәл итик? Безнең ат йөртүчеләребез дә юк бит, саклап баручыларыбызны да һәлак иттеләр.

Кечүккә, мескен хатыннарның ат тезгененә ябышып ялваруы, үзенең исә бу хәлдән өстен чыгуын тою рәхәтлек тойгысы бирде. Өстәвенә, болар Тәңрекол йортыннан икән ләбаса, ә углан бәкнең Кострома янындагы бәрелештә нинди кыю яугир икәнлеген күрсәткәнен, бергәләшеп хакимне котылгысыз үлемнән коткаруларын онытмаган иде.

– Яле, барыгыз да арбаларыгызга менеп кунаклагыз, – дип боерды ул. – Курыкмагыз, исән-имин булырсыз. Минем егетләрем атларыгызны юлга алып чыгар. Тик сезгә

хәзер кире Казанга кайтырга туры килер. Сынау сәгатендә үз калаңны һәм хуҗаңны ташлап китү яхшыга илтми! Казан түрәләре, артларында хатыннары вә бала-чагалары тулы йорт булганын белгәндә, сугышка үтә тәвәккәллек белән керәләр.

– Углан, карагыз әле... – Нөкәр, ияреннән төшми генә, кечкенә күн капчыкны сузды. – Моны мөртәтләрнең берсе куенына яшергән булган. Килеш-килбәте буенча ул сугышчы түгел, хәбәр илтүче генә.

Кечүк капчыктан кәгазь төргәген тартып чыгарды, башта, бик исе китмичә, өстән-өстән генә күз йөртеп алмакчы булган иде, тик шунда ук аңа чытырдап ябышты. Игътибар белән укый башлауга, үз күзләренә үзе ышанмады: мондый уңышка аның күптән ирешкәне юк бит. Аллаһ Тәгалә аны изге гамәле өчен бүләкләде. Углан хатын-кызарны таларга ябышкан өердән коткарды һәм шунда ук соңгы айларда һичнинди нәтиҗәсез эзләп йөргәненә – Казан түрәләренең хыянәтен фаш иткәнен раслаучы дәлилне кулга төшерүгә ирешә.

***

Атна-ун көн дә үтмәгәндер, төрле яклап килгән Мәскәү яулары Казанны бер ыргылыштa уратып алды. Кала дошманнарны ныгытып бикләнгән капкалары һәм киеренке хәлләргә әзер торуы белән каршылады. Чик буе сакчылары тарафыннан кисәтелгән хан, казакларга һәм кырымлы гаскәрләренә, урманда тозак корып, үзеннән хәбәр көтәргә кушты.

Бөек кенәз Иван, күз күремендәге биек үрдән торып, яхшы ныгытылган кальганы күзәтте. Ул килгәнче, Булатширин яклылар хан тәхетен түнтәреп куйганнардыр инде, дип, Казанны җиңел генә тезләндерү өмете күңелен алгысыткан иде, югыйсә. Әмма нәрсәдер булды бугай, карачы яраннары, ни өчендер, урыс гаскәрен ипи-тоз белән каршы алырга чыкмады. Яшь кенәзне шөпшә күчедәй борчулы уйлар урап алды, ул мондый орышларны күп күргән гаскәр башларына астыртын гына карады: бәлки алар мондый очракта нишлисен беләдер? Ә тегеләр, бернигә дә исләре китмичә, утсыз-өнсез калган Казанны боҗра эченә кертеп буарга күрсәтмәләр бирүләрен дәвам итә.

Сафагәрәй хан, ныгытма диварларыннан торып, каланы чолганышта калдырган дошман гаскәрен күзәтә иде. Аны чиктән тыш ярсу биләп алды. Әлбәттә, бәйсезлекне саклап каласыларына ышанычы нык, кирмәннең камалышта озак торырга әзер булуын, биек диварларны ишеп, яхшы ныгытылган капкаларны җиңел генә ачтыра алмасларын белә ул. Илбасарның тыныч күршесенә бер сәбәпсез яу чыгуыннан бигрәк, Казан аксөякләренең мәкерлелеге вә хаинлеге ачуын чыгарды ханның. Алар, үз максатларына ирешмәк өчен, чәчәк атып утырган каланы, илдәшләрен канга батырмакчы булып чыкты. Ә мәскәүлеләр, ныгытмаларга якын килергә базмыйча, тирә-юньдәге бистәләрне һәм биләмәләрне таларга керештеләр. Кораеш, Бишбалта бистәләре ут эчендә калды. Казанлылар «кызыл әтәч» юк итә башлаган өйләр, урамнар һәм мәчетләрне ачы күз яшьләрен агызып күзәтте.

– Менә ул – хаинлек бәһасе! – Илбашы ярсып кулын күтәрде дә, шәһәр тирәсен аяусыз талаучы урыс баскынчыларына төртеп күрсәтте. Аның артында торган кырымлылар ханның беренче ишарәсе белән үк дошман өстенә ташланырга әзер булып, киерелгән җәя кебек тартылдылар. Әмма Сафагәрәй аларга түгел, манарадагы күзәтчеләргә боерык бирде:

– Кечүккә ишарә ясагыз, вакыт җитте!

Шул мизгелдә урман авызлары ачылып, гайрәт җәясе белән тартылып торган атлы гаскәрне чыгару өчен, артка чигенеп алгандай булды. Җайдаклар – бер яктан казаклар, икенче тарафтан кырымлылар, дәһшәтле тавышлар чыгарып, дошман өстенә ябырылдылар. Аларның кулында кылыч һәм кәкре ятаганнар биеп, илбасарларның таркау

рәтләрен кырып бара башлады. Мондый каршылыкка очрыйсыларын көтмәгән урыслар, кан исе килеп торган табышларын ташлап, аннан-моннан әтмәлләнгән өннәренә чабыштылар да, шуларга кереп постылар. Казан атлы гаскәре «кунаклары» башына ничек көтмәгәндә очып кунган булса, шундый ук тизлек белән күздән дә югалды. Бөек кенәз Иван, кашын җыерып, үз яугирләренең үләксәләренә җирәнеп карады, болар – олы карачы Булатның кан коюсыз гына җиңү вәгъдә иткән татлы телле илчеләренең беренче корбаннары иде. Һәм алар әле соңгылары булмады. Казан янындагы яулар тагын берничә көн нәрсәдер көтеп яшәде. Бөек кенәз Пермьнән килергә тиешле гаскәргә коры өмет баглап торды, әмма ул һаман күренмәде дә күренмәде. Ә Казан атлылары баскынчыларны тынычлыкта калдырмады, көненә берничә кат килеп ботарлады, урыс ягындагы яугирләрне йолкып алып, җәза бирә торды. Мәскәүлеләр авыр мылтыкларыннан атарга дип артларыннан сикереп чыксалар да, җайдаклар шул арада эреп күздән югалалар иде. Урмандагы һәр агач төбе таныш иде аларга: казанлылар, үзләрен саклаган туган җир рух-ияләре, күзгә күренмәс шүрәлеләр кебек, гаярьләр булып чыкты. Ни Пермь гаскәрен, ни, янәсе, үзен көтеп торган ханкаланың капкалары ачылганны көтеп ала алмыйча, гайрәте чиккән Иван IV чигенергә боерды. Гаскәрләр, Зөя аша кичеп, кайтыр юлга кузгалдылар. Ә аларның артыннан сызгырып калган хуҗалар илбасарларга ярдәм итәргә, дигән яман уй белән Казан капкасына соңлап килгән Пермь явын шаркылдашып каршы алдылар. Бер генә арга* да ул көнне бу уттан исән-имин чыгу мөмкинлеге язмаган иде шул.

Әмма ханга һәм аның яраннарына дип ясалган әҗәл тигәнәге хаиннарга да рәхимсез булып чыкты. Ул инде хәзер яңа корбаннар каны белән тулып таша башлады. Менә, беренчеләрдән итеп, тәхет бусагасына яшерен эшләр идарәчесе Мөхәммәд бәкне ташладылар. Ул, кяферләр ягына чыгып, Казан иленә хыянәт итүе өчен гаепләнергә лаек табылган иде. Бу адәмчекнең монафикълыгын кире кага алмаслык дәлилләр белән фаш иткән хатны Сафагәрәйнең алдына Кечүк углан үзе китереп салды. Ак төргәктәге һәр сүзнең артында кара йөзләрнең шәхси мәнфәгатьләрен генә кайгырткан, илне, аның халкын фаҗигагә дучар итәсе коточкыч мәкерле сәясәт яшеренгән иде. Шуңа күрә, хан Казанны дошманга бирергә омтылу гамәлендә тагын кемнәр катнашканын ачыклауны дәвам итәргә кушты. Мөхәммәд бәкне шул көнне үк богаулап, тиздән кырыс җәзасын гына көтәсе салкын зинданга ташладылар. Якыннарыннан, фикердәшләреннән берсе булган әлеге түрәне якларга олы карачы үзе ашыгып килде. Булатширин, барс кыюлыгы белән, үткен тешләрен ыржайтып, бәкне шәригать хөкеме алдына бастыруларын таләп итте. Сафагәрәй белә: Мөхәммәдне кулдан бер ычкындырсаң, эшне чуалтырга гына торган шәригать хөкемдарлары аны акларга мең сылтау табачаклар. Булатширин әмирнең гарызнамәсе кире кагылды, инде шуннан соң олы карачы, үз җанын саклап калу өчен, бүтән яшерен күрсәтмә бирергә мәҗбүр булды. Хаким җәлладларына кичә генә әтәч булып, чиксез кодрәте һәм оятсызлыгы белән, башкаларның бил бөгүеннән тәм табып йөргән түрәне җәзалауда осталыкларын күрсәтергә җай калмады. Иртән яшерен эшләрнең элеккеге идарәчесен сулышы киселгән, тәне суынган көе зиндан идәненнән өстерәп чыгардылар.

– Бичараның авыру йөрәге өстенә гаепсез гөнаһ ташлаулар хурлыгын күтәрә алмыйча шартлагандыр, – дип, Мөхәммәд бәкнең үлеменә йомгак ясаган булды олы карачы Булатширин.

Дәвамы бар

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

* Ар (урысча – вотяк) – удмурт кавеме (тәрҗ.иск.).



ПАРИЖ выставкасында

Гомәр Гали

СССР 1924 елның 28 октябрендә Франция белән дипломатик мөнәсәбәтләрне җайга салганнан соң, Парижда узачак «Хәзерге заман гамәли һәм сәнәгать сәнгате халыкара күргәзмәсе»нә («Exposition Internationale des Arts Décoratifs et Industriels Modernes») чакыру ала.

1925 елның апрель-октябрь айларында Парижда оештырылган әлеге күргәзмәдә 50дән артык ил катнаша, 200дән артык павильон эшли. К.Мельников проекты буенча төзелгән СССР павильоны 10 июньдә СССРның Франциядәге илчесе Л.Б.Красин һәм Франциянең мәдәният министры де Монзи катнашында ачыла. Ә Франциянең Президенты Гастон Думерг аны беренче тамаша кылучылардан була. Павильон эчендәге татар халкының гамәли сәнгатенә багышланган махсус урын чит ил кунакларының игътибарын аеруча җәлеп итә.

Алда тәкъдим ителгән өзек «Безнең юл» журналыннан алынды (1925. – №9-10. – Б.49). Мәкаләнең авторы Гомәр Гали (1900-1954) дә, язучы һәм мөхәррир буларак, Парижга бара һәм дөньякүләм масштабтагы әлеге вакыйгада катнашып, СССР данын яклый.

Редакция

Париж выставкасында СССР павильонының тышкы күренеше. Архитектор К.С.Мельников проекты буенча агачтан һәм пыяладан төзелгән



Париж выставкасында Татарстан почмагы. Күргәзмә өчен материал этнографлар П.М.Дульский һәм Н.Н.Воробьев тарафыннан әзерләнгән

Татарстан Җөмһүриятенең Париж выставкасына җибәргән кешеләреннән берсе булу сыйфатым белән мин бу урында Татарстан турында аерым берничә сүз әйтеп үтәргә телим.

Татарстан Җөмһүриятенең бу ел театр һәм сәнгать өлкәсендә эшләгән эшләренең иң зурларыннан һәм уңышлыларыннан берсе, һичшиксез, аның Париж выставкасында катнашуы, татар халык сәнгатен дөнья аренасына илтеп күрсәтүе булды. Татарстан Җөмһүрияте Париж выставкасында аерым хәзерлек белән катнашты. Нәтиҗә дә күз алдында: Париж выставкасы ачылыр алдыннан, шул выставкага багышлап «Правда»га язылган мәкаләләрдә Татарстан экспонатлары коллекциясенең тулылыгы һәм Татарстан сәнгатькәрләренең үз өсләренә төшкән бурычларын яхшы үтәүләре турында әйтелде. Соңгы вакытта француз телендә чыккан каталог-

Традиция дәвам итә: «Тукай» артеле эшчеләре (сулдан уңга): Тәнзилә, Әминә, Зөфәр, Рәйсә һәм Илсөя исемле осталар. 1957 елның җәе. Фото Арча шәһәрендәге «Казан арты» тарих-этнография музеенда саклана

ларда, Мәскәү Художество фәннәре академиясе президенты Б.Коган мәкаләләрендә дә шул ук фикерне күрәбез.

СССР павильонының Татарстан бүлегенә татар халкы иҗатының оригиналь итеп исәпләнерлек сәнгать әйберләреннән 45ләп экспонат куелган. Болар эченә төрле баш киемнәре (кәләпүшләр, калфаклар), ювелир нәрсәләре, үзләренең эшләнүләре һәм материаллары белән оригиналь итеп алынырлык җаймәләр, сөлгеләр һәм башка шундый нәрсәләр керәләр. Ике зур витринаны үзләренең эшләнүләре, бизәүләре ягыннан декоратив сәнгать әйберләре арасына тезелерлек татар китаплары каплап алганнар. Болар арасында аерым дикъкать белән каралганнары, аерым рәсемгә алынганнары, каталогларга урнаштырылганнары да юк түгел. Мәсәлән, Мәскәүдә басылган французча каталогта – татар художнигы Ф.Таһиров* тарафыннан эшләнгән обложка. Кайберләре, карагач: «Гарәп хәрефләре конструктивизмны да тыңлыйлар икән», – диләр.

Җыеп әйткәндә, **Татар Җөмһүрияте** *(Автор шулай язган! – **Ред.**)* үзенә чынлап күз төшерерлек итеп куелган иде.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

* Фаикъ Шакирҗан улы Таһиров (1906-1978) – график, китап бизәү рәссамы, техник фәннәр кандидаты.

Безнең мирас №5 май 2019

Такталачык: ятимнәр сыенган җылы йорт

Ильяс Салихҗан

1939-1945 нче елларны – кешелек дөньясының акылдан язган еллары, дип әйтерлек. Башлануына инде сиксән ел үтеп барса да, Икенче Бөтендөнья сугышы ясаган яраларны оныттырлык түгел. Һәм онытырга ярамый да аларны! Чиксез кайгы-хәсрәт китергән дәһшәтнең иң авыр мирасы – ятимнәр... Күпме бала әти-әнисез кала шул елларда?! Мөгаен, төгәл генә җавап биреп булмас бу сорауга. Дәүләт күпләп балалар йортлары төзергә мәҗбүр була. Татарстанда гына да аларның саны 112гә җитә. Безнең үткәнебез бу. Моны истән чыгарырлыкмы соң!..

Сугыш елларында эвакуацияләнгән ятимнәрне сыендырган балалар йортларының берсе 1944 елда Актаныш районындагы Такталачык авылында оештырыла. Дөрес, аның нигезе иртәрәк салына, дисәң дә ярый. Ул авылга Ленинградтан эвакуацияләнгән балалар 1942 елда ук китерелә.

Хәер, коллективны нигездә көнбатыштан күчерелгән балалар тәшкил итсә дә, очраклы рәвештә табылган ятимнәр дә кабул ителә анда. Әти-әнисез калып, ач-ялангач йөргән үксезләр – ул елларның гадәти күренеше. Юл буйларында, урман-кырларда яисә ташландык биналарда очраган нарасыйларны бернинди тоткарлыксыз кабул итеп җылыталар бу йортта. Ашаталар-эчертәләр, юындыралар, медицина ярдәме күрсәтәләр һәм балалар йортына тәрбиягә алалар. Мондый сабыйларның күбесе үзләренең исемнәрен дә хәтерләми бит әле. Аларга исем-фамилия бирелеп, тиешле документлар тутырыла әлеге йортта.

Такталачыктагы 3 нче балалар йортының директоры итеп Әминә Гайнетдинова билгеләнә. Әйе, җитәкчене аерым әйтергә кирәк биредә. Эшнең уңышлы оештырылуы тулысынча аннан тора. Шөкер, Такталачыкта тәрбияләнүчеләр уңа директорларыннан. Тынгысыз йөрәкле педагог үтә четерекле тәрбия эшенә җиң сызганып тотына. Әмма ни генә эшлим, дисәң дә, юклык аяк чала. Озакка сузылган сугыш катыкотыга калдырган авыр еллар шул бу. Балалар йорты ил ярдәме белән оештырылса да, тәэмин ителү тиешенчә булмый. Әти-әнисез калган ятимнәрне тәрбияләп үстерү өчен тегесе дә кирәк, бусы да җитми. Һәм һәр кирәкне китереп бирергә тиешләр дип көтеп торудан да мәгънә юк. Барысы артыннан да үзеңә чабарга туры килә. Колхоз яисә район җитәкчелегенә ярдәм сорап барганда үҗәтлек күрсәтергә һәм еш кына, «ишектән кусалар, тәрәзәдән кереп тә», гозерен җиткерергә туры килә аңа. Әкренләп, тартыша-көрәшә, өч йокы бүлмәсе булган яңа йорт һәм канцелярия белән медпункт биналарын төзеттерүгә ирешә ул.

Директор шулай ук ярдәмче хуҗалык булдыруны да максат итеп куя. Колхоз белән җир мәсьәләсен хәл итеп, төрле яшелчә үстерергә керешәләр. Абзарлар төзетеп,

ат, сыер, сарык һәм каз-үрдәк асрауны да җайга салалар. Бу хезмәт аеруча мөһим. Балалар үз-үзләрен ризык белән тәэмин итеп, эшкә дә өйрәнеп үсәләр.

Әминә Гайнетдинова, оештыру эшләре белән бергә, педагог буларак, балаларга тәрбия һәм белем бирүдә дә башлап йөри. Җитәкчеләренә карап, бүтән хезмәткәрләр дә эш сәгате дигән чикләрне белми тырыша. Ихлас күңелдән бирелеп эшләгән тәрбияче апаларына бигрәк тә кечкенәләр тартыла. Кичләрен йокларга яткач та: «Апа, миңа әкият сөйлә әле!» яисә «Апа, бүген син минем белән ят инде!» – дип үтенәләр әти-әни назын күрмәгән нарасыйлар. Аһ, ничек ташлап китсен соң шул оланнарны хатын-кыз?!

...Әминә Гайнетдинова Такталачыкта 1944 елның 12 августыннан 1957 елның 18 июленә кадәр хезмәт куя. Лаеклы ялга чыккач, Казанга күченә. Балалар йортында үскәннәр аның хәлен белешеп тора. 1985 елда, әниләрен алыштырган шушы олы апаларына сиксән яшь тулган көнне, җыелып, аның юбилеен зурлап бәйрәм итәләр. Мөхтәрәм Әминә ханымга ятимнәрне тәрбияләүдә бөтен көчен-сәләтен биреп эшләгәне өчен рәхмәт сүзен күп ишетергә насыйп була. Олыгайгач, ул үзе үк Агыйдел буендагы шул балалар йортында тәрбияләп үстергән детдом егете Миңлефарсый Әхмәдиев гаиләсендә яши. Бу мәрхәмәтле шәхес аны соңгы юлга да зурлап озата.

Такталачыктагы 3 нче балалар йорты тагын да ныгый һәм зурая. Аңа Актанышта́н – Мәчти һәм Яңа Әлем, Минзәләдән – Хуҗамәт, Мөслимнән – Ольгино, Сарманнан – Карамалы, Шөгердән Сарабиккол авылларындагы балалар йортларында тәрбияләнүчеләрне дә алып киләләр. Әминә ханымны Яңа Әлемдә директор булып эшләгән Нәҗип Газизов алыштыра. Ул ятим балаларны хезмәт белән тәрбияләүне тагын да киңәйтеп җибәрә.

Бүлеп бирелгән 12 гектар җирдә бәрәңге, кыяр, помидор, чөгендер, кәбестә, суган, сарымсак кебек яшелчә үстереп, балалар үзләрен яшелчә белән тулысынча тәэмин итәләр. Ярдәмче хуҗалыкта 4 ат, 19 баш мөгезле эре терлек, 17 баш дуңгыз, бер көтү сарык һәм тавык, күркә, каз асрыйлар. Эшләре ару гына бара. Хуҗалыкны авылда хәтта колхозның бишенче бригадасы дип тә йөртә башлыйлар. Хак сүз! Аның кереме елданел үсә бара һәм 1963 елда чиста табышы 17454 сумга ук җитә. Әлбәттә, балаларның хезмәт күрсәткече дә бу. Алар, эшкә өйрәнеп, сау-сәламәт булып үсәләр. Тәрбия бирү күзлегеннән караганда, аның отышлы ягы шул. Сүз дә юк, бирелә эшне ифрат дәрәҗәдә уңышлы оештыра алган сәләтле җитәкче Нәҗип Газизовка баш иярлек.

Педагогның аталарча кайгыртуы моның белән генә чикләнми әле. Үсеп җитеп Такталачыктан киткәннәргә дә тормышта аякка басарга ярдәм итә ул. Шәһәрләрдә укыган студентларны каникул вакытларында эшкә алып хезмәт хакы түләүне, аларны азык-төлек һәм кием-салым белән тәэмин итүне оештыра...

Кызганыч ки, уңган педагоглар коллективы тупланган төпле балалар йорты 1966 елда таратыла. Шулай итеп, Актаныш районындагы Такталачык авылында 1944 елда оештырылган балалар йортында 22 ел эчендә 700гә якын ятим бала тәрбияләп чыгарыла.

... Сүземне йомгаклап, мәкаләмдәге мәгълүматларны һәм фотосурәтләрне Хаҗирә ханым Әхмәтҗанова бирүен әйтим. Хаҗирә ханым әлеге балалар йортына 1954 елда китерелә һәм анда унбер ел укып, урта белем алып чыга. Нәкъ 1966 елда тәмамлый ул мәктәпне. Такталачыкта узган балачагы истәлекләрен – фоторәсемнәрне, хатларны һәм газеталарда язылган мәкаләләрне, җыеп, кадерләп саклый икән үзе. Без аның белән, альбомын карый-карый, озаклап сөйләшеп утырдык. Соңында үземне гаҗәпләндергән бер үзенчәлек турында сорамый булдыра алмадым.

– Хаҗирә ханым, балалар йортында үскәннәрне, гадәттә, басынкы-боек була, диләр. Ә сезнең фоторәсемнәрдәгеләр барысы да елмаеп карый...

Хаҗирә Әхмәтҗанова (уңнан беренче) сыйныфташы Нәсимә белән. 1954 ел

– Ямансулау булгалый инде ул, бигрәк тә кечкенә чакта. Тик безгә моңсуланып ялгыз йөрергә вакыт калдырмыйлар иде. Тәрбиячеләребез аңлагандыр инде безнең хәлне. Һәрвакыт игътибарда булдык. Һәрчак ни дә булса эшли идек: йә чигәбез, йә тегәбез яисә акробатика белән мавыгып шөгыльләнәбез... Мин үзем, шул акробатика белән җенләнеп, республика ярышларына ук барып җиттем бит әле. Шунда җиңгәч, Кара диңгездәге Артек лагерена да җибәрделәр апагызны!.. Аннары бәйрәм ясарга тырышалар иде. Бала-чаганың күңелен күтәрергә күп кирәкме инде! Әйтик, төрледән-төрле «тәмнүшкәләр» пешереп, әйбәт ашаталар иде безне. Матур киендерүләре дә күңелгә хуш килә иде. Кайдан гына кайтартмыйлар иде бит кием-салымны! Бихисап бәйрәм чараларын оештырулары да истә. Кышын Яңа елны каршы алуларыбызны әйтәсеңме, җәен – Агыйдел буенда ясаган Сабан туйларыбызнымы... Менә Такталачыкны уйлый башласам, шундук тәрбияче апаларыбызны искә төшерәм: безне кеше итәргә никадәр көч куйганнар икән алар! Моны мин балачакта да, яшь чакта да башка алмаганмын, билгеле. Үзем гаилә корып балалар үстерә башлагач кына аңладым мин апаларыбызның ничек чиләнүләрен... Такталачык детдомында безне үз балаларыдай якын күреп тәрбияләп үстергән педагогларыбызга олы рәхмәт әйтеп баш иясе килә, дисәм, төчеләнә бу, дип уйлый күрмәгез берүк! Юк. Һәммәбез шундый фикердә без. Бергә үскән кызлар-егетләр белән еш очрашып торабыз бит. Сагындыра шунда үткән балачак!.. Тәрбияче апаларыбыз Гүзәл Фәтхиева, Дәлифә Ибраһимова, Кифая Габдрахманова, Кәнҗемә Латыйпова, Нәсиха Миңгалиева, Мәгъшия Солтанова, Мөзәянә Тимерова, Мәхмүзә Вагыйзова, Нәҗибә Талипова, Сәмига Шәйхразыева, Фазыйлә Закирова, Һидая Галиева һәм беренче директорыбыз Әминә апа, аны алыштырган Нәҗип абый, завучыбыз Яхъя абыйларның игелекле эшләрен беребез дә онытмый. Аларга рәхмәтне күпме генә әйтсәк тә, аз булыр кебек.

...Олы йөрәкле педагоглары белән горурланган Хаҗирә ханымның теләгенә, һичшиксез, кушыласы килә. Хәер, үзен тәрбияләп үстергән педагогларга бик күпләр җиткерер иде андый җылы сүзләрне. Әйткәнемчә, сугыш елларында йөздән артык балалар йорты сыендырган ич әти-әнисез калган нарасыйларны. Сөбханаллаһ, күңеле киң безнең халыкның!.. ■

«МӘКТӘП ТОТЫП ҮСКӘН БАЛЛЫ БАГЪБОСТАН ХАНЫМ...»

Алсу Зиннәтуллина

XX гасыр башында тарих сәхнәсенә күтәрелгән күренекле шәхесләр арасында Багъбостан Вилдан кызы Мөәминова үзенең лаеклы урынын алып тора. Соңгы елларда әлеге шәхескә артык зур игътибар бирелмәсә дә, үз чорында аңа багышлап шигырь юллары иҗат ителгән, һөнәри эшчәнлеген яктырткан хезмәт дөнья күргән, хәтта чит ил газеталарында да аның кыюлыгын сурәтләп мәкаләләр басылган.

Кем соң ул, шагыйрь Шәехзадә Бабич шигырьләрендә искә алынган, «мәктәп тотып үскән баллы Багъбостан ханым»?

Багъбостан ханым 1884 елда Уфа губернасы Минзәлә өязе (хәзер Азнакай районы) Мәндәй авылының ярлы крестьян гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Кызга өч яшь вакытта этиләре вафат була һәм әниләре Гафифә ханым, биш кызын алып, Оренбургка күченеп китә. Шәһәргә килеп төпләнгәч, ана кеше кече кызы Багъбостаннан кала башка балаларын асрауга биреп, үзе бай гаиләләренә хезмәткә урнаша.

Шәһәрдә күренекле иганәче сәүдәгәр Гани бай Хөсәенов тарафыннан яңа ысул белән укытуга нигезләнгән кызлар мәктәбе ачылгач, Багъбостанны шунда укырга бирәләр. Әлеге мәктәпнең җитәкчесе Фатыйма Әдһәмова аның беренче тәрбиячесе һәм остазы була.

Багъбостан кечкенәдән бик зирәк һәм үткен кыз булып үсә. Кыш көне укыса, җәй айларында йон фабрикаларында эшкә булышып, үзен-үзе тәэмин итеп тора, үзлегеннән физика, математика һәм география фәннәрен үзләштерә, төрле юллар белән гыйлем эстәргә омтыла. Әнисе аны кечкенәдән кул эшләренә күнектерергә тырыша. Ул, бик тиз тегү-чигү эшләренә өйрәнеп, калфаклар чигә башлый. Багъбостан гайбәт сүзләрдән куркып тормый, осталыгын тагын да камилләштерү максаты белән, монастырь каршындагы кул эшләре түгәрәгенә дә йөри[1].

Балалар укытырга хыялланып йөргән Багъбостан ханымга Беренче рус революциясе нәтиҗәләре, милли матбугат битләрендәге мәгърифәткә, тәрәккыяткә өндәгән мәкаләләр зур йогынты ясый. Тиздән, 1908 елда ул, ире Гобәйдулла Рәдүди[2] һәм остазы Фатыйма ханым булышлыгы белән, Оренбургта кечерәк кенә кызлар мәктәбе һәм кул эшләре түгәрәге ачып җибәрә. Шул чор мәгълүматларына караганда[3], бу мәктәп 1905 елгы революциядән соң Оренбург шәһәрендә ачылган беренче җәдиди кызлар мәктәбе булып тора. Мәктәпнең даны халык арасына бик тиз тарала һәм бирегә белем алырга илнең төрле төбәкләреннән мөселман (татар, башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз) кызлары килә башлый. Ачылган елны мәктәптә бары 15 кыз гына укыса, өченче уку елына укучылар саны 117 кешегә җитә, ә инде ун ел эчендә әлеге мәктәптә барлыгы 1212 кыз бала белем алып чыга[4].

---

[1] Сәйфи Кудаш. Халкыбызның каһарман бер кызы // Казан утлары. – 1984. – №10. – Б.164.

[2] Рәдүди Гобәйдулла Габделмөәмин улы (1885-1912) – шагыйрь, педагог, хәзерге Оренбург өлкәсенең Рәдүт авылында туган. «Кыйссалы вә хиссалы шигырьләр» (1907), «Гөлзаре сыйбиян» («Балаларга чәчәк түтәле», Оренбург, 1907), «Мәктәп өчен шигырьләр» (Оренбург, 1909) исемле шигъри җыентыклар, «Табигатькә сәяхәт яки тарихы табигыйә» (Оренбург, 1908), «Тәсһиле җәгърафия» («Гадиләштерелгән география», Оренбург, 1911) исемле дәреслекләр авторы.

[3] Унъеллык гыйльми хезмәт. – Оренбург, [елы юк]. – Б.6.

[4] Унъеллык гыйльми хезмәт. – Оренбург, [елы юк]. – Б.22.

Багъбостан ханым гомеренең иң гүзәл вакытын, яшьлек елларын балалар тәрбиясенә, кыз балаларга белем бирүгә багышлый. Аңа күп кенә авырлыкларны җиңеп чыгарга туры килә. Мәктәпнең даны күтәрелү белән кадимчеләр тарафыннан күптөрле гайбәтләр, яла ягулар саны да арта. Нәтиҗәдә, дәүләт органнары тарафыннан мәктәптә еш кына тикшерүләр һәм тентүләр булып тора. Шуның өстенә, 1912 елда күкрәк авыруыннан тормыш иптәше Гобәйдулла Рәдүди вакытсыз дөнья куя. Багъбостан ханым барлык авырлыклар алдында бирүзе кала. Кадими муллалар төрле сәбәпләр табып, шул исәптән, Багъбостан ханымның мөгаллимәлеккә рәсми шәһадәтнамәсе юклыгын да истә тотып, мәктәпне берничә мәртәбә яптырырга тырышалар. Бу хәлләрдән соң, 1913 уку елы тәмамлангач, Багъбостан ханым, Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, укытуга хокук бирүче рәсми документ алып кайта.

Мөгаллимә Багъбостан ханым (Сөембикә, 1915, № 8. – 7 бит)

Әлеге чор мөгаллимәләренең үз эшләренә җаннары-тәннәре белән бирелгәнлеге бигрәк тә сокландыра. Багъбостан ханым, мәсәлән, үзенең укучыларын «газиз шәкертләрем» дип искә ала, аларны «гөл чәчәкләре»нә тиңли, ә җәйге каникул айларын елның «иң күңелсез, иң рухсыз вакыты» дип саный, үзен исә бу чакта дөньяның иң «кыерсытылган, җәберләнгән кеше»ләре рәтенә кертә. *«Минем өчен елның иң күңелсез вакыты май ае була. Табигатьнең төрле чәчкәләр, яшь чирәмнәр белән зиннәтләнеп, бөтен җан иясенә яңа хәят, яңа рух өреп үзенең бөтен балаларын шатландырган вакытлары, мин мәкъһур (кыерсытылган) бәндә өчен әллә нинди рухсызлык, күңелсезлек дәверләре. Ул вакытлар мине җанымнан газиз шәкертләремнән, гөл чәчкәләреннән, нәфис, сөекле балаларымнан аера. Табигать никадәр генә зиннәтләнсен, купшылансын, үз өем таланган йорт кебек калгач, аннан миңа ни шатлык? Анда нинди ямь дә нинди матурлык бар? Май керүе белән телемнән җәй буена төшми торган [...] шигырь тагы минем телемә килеп ябыша. Иртә дә, кич тә шул сүзләр тәкърарлана башлый. Күңелсез, пошыну дәкыйкаләремдә (минутларында) явыз табигатькә шелтә кылам, ләгънәт укыйм»*, – дип яза ул үзенең «Сәяхәт хатирәләре»мәкаләсендә[5].

Әлеге ялгызлыктан котылуның бер юлы буларак, шул ук вакытта, әлбәттә, белемен камилләштерү, башка кызлар мәктәпләренең уку-укыту эшләре, мөселман халыкларының тормыш-көнкүреше белән танышу ниятеннән чыгып, Багъбостан берничә ел рәттән төрле төбәкләргә сәяхәт кыла. Алар арасында иң кызыклысы, һәм, мөгаен, иң әһәмиятлесе – 1914 елның җәендә Төркиягә баруыдыр.

Төркиядә ике ай ярымлык сәяхәте вакытында Б.Мөәминова Истанбул һәм

[5] Багъбостан. Сәяхәт хатирәләре // Сөембикә. – 1915. – № 21. – Б.16.

Эдирне шәһәрләрендә, хатын-кызлар өчен чыга торган журнал идарәсендә була, кызлар мәктәпләренең эшчәнлеген өйрәнә, төрле җыелышларда катнаша. Багъбостан ханымның Төркиягә баруы төрек Хөкүмәт мәҗлесе үткән көннәргә туры килә. Татар мөгаллимәсе, мөселман халыклары тарихында беренчеләрдән буларак, моңарчы хатын-кызлардан һичкем аяк басмаган, фәкать ирләр катнашында гына уза торган утырышка керергә рөхсәт ала[6]. Ул гына да түгел, утырышта сүз сорап, төрек телендә чыгыш ясый. Анда ул үзенең кызлар мәктәбе мөдирәсе икәнлеген белдерә һәм мәктәбенең эше белән таныштыра. Бу адым Төркия дөньясы өчен бик кыю адым була. Иртәгесен әлеге хәл турында Төркиядәге «Фикер» газетасында «Хөкүмәт мәҗлесендә беренче мөселман ханымы» дигән исем белән мәкалә дә басылып чыга[7].

Гобәйдулла Рәдүди (М.Рахимкулова. Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России. – Оренбург: Яңа Вакыт, 1998).

Сәяхәтләргә йөрү тиздән үзенең уңай нәтиҗәләрен дә бирә. Мәктәптә уку программасы киңәйтелә, өстәмә фәннәр кертелә. Анда дини фәннәр белән беррәттән, дөньяви фәннәргә дә зур игътибар бирелә башлый, теләге булган рөшди сыйныф укучыларына атнага өч мәртәбә рус теле дәресләре, ибтидаинең беренче һәм икенче сыйныфларыннан кала биш сыйныфка атнага өч тапкыр кул эшләре дәресләре кертелә. Мөгаллимәләр саны сигезгә җитә[8].

Багъбостан ханым бу юнәлештә беренче юл ЯРУЧЫ, ике кардәш мөселман хатын-кызлары арасында дуслык күпере салучыларның беренчесе, дисәк, ялгыш булмастыр, мөгаен. Аның белән таныш булган ханым һәм әфәнделәр дә Багъбостанның тормышы белән гел кызыксынып торалар. Аның кылган сәяхәтләре, йөргән җирләре һәм шул сәяхәтләр вакытында күргән кызык вә гыйбрәтле вакыйгалар белән таныштырып баруын сорап мөрәҗәгать итәләр. Мөгаллимә, әлеге үтенечләрне истә тотып, «Сөембикә» журналы (1914. – №22. – Б.4-8.) битләрендә «Оренбурглы мөгаллимә Багъбостан» имзасы белән Төркиягә сәяхәте турында «Истанбул хатирәте» исемле саллы гына мәкалә бастырып чыгара. Текстны игътибарыгызга хәзерге сөйләм теленә өлешчә яраклаштырып тәкъдим итәбез.

---

[6] Миңнуллин Җ. Багъбостан мәктәбе // Казан утлары. - 1987. - № 6. – Б.157.
[7] Сәйфи Кудаш. Халкыбызның каһарман бер кызы //Казан утлары. – 1984. - №10. – Б.168.
[8] Унъеллык гыйльми хезмәт. – Оренбург, [елы юк]. – Б.20.

ИСТАНБУЛ ХАТИРӘТЕ

Багъбостан Мөэминова

Истанбулга баруымнан беренче максатым мөселман кардәшләребез – төрек ханымнарының уку вә тәрбия эшләре, йорт-көнкүреше, иҗтимагый тормышлары илә танышу булганлыктан, ике ай ярымлык сәяхәтемнең иң күп вакытын шул юлга сарыф кылдым. Кирәк Истанбулның үзендә, вә кирәк булса Эдирнедә булсын, төрек ханымнарының һәр катлавы илә таныштым. Мәктәп вә мәдрәсәләрен, уку торышы вә программаларын күрдем. Җәмгыятьләрендә, «Кадынлар журналы»[9]ның идарәханәсендә, мәгариф җәмәгать хадимнәре, мөхәррирә вә әдибәләрнең хосусый вә гомуми мәҗлесләрендә булдым. Кирәк хосусый утырыш, вә кирәк гомуми җыелышларында булсын, төрек ханымнарының хәтергә килмәгән бер рәвештә уянганнарын күрдем. Русиядә икән вакытымда төрек ханымнары хакында бик түбән фикерләр ишетергә тугры килә иде. Күп кешеләр Истанбул ханымнары арасында булган тәрәккъкыятьне бик әһәмиятсез итеп күрсәтәләр, Аурупа мәгънәсе илә фикер иясе ханымнары бармак санынннан артмый, тәгълим вә тәрбия эшләренә әһәмият бирелми, хокук мәсьәләсен төрек ханымнары авызларыннан чыгарырга куркалар, хиҗаб вә ачык йөрү мәсьәләләре иң әһәмиятсез мәсьәләләрдән санала. Вә яхуд әһәмият бирелә икән, икенче ягыннан әһәмият бирелә – фәлән вә фәлән диләр иде. Бу фикер бер Истанбулдан кайткан кешеләр авызыннан гына ишетелми, матбугатта да кайчак күренеп кала иде.

Ихтимал, төрек ханымнары элегрәк шулай булса да булганнардыр, әмма хәзер, якыннан танышканның соңында, мин монда укыган вә ишеткән фикерләрнең хакыйкатьтән бик ерак вә бөтенләй ялгыш идеген күрдем. Төрек ханымнары арасында гаять җитди бер фикер кузгалышы – хәрәкәт бар. Кайбер ханымнар илә булган сөйләшүләремне бөтен проблема вә тәфсыйль фикерләре илә ачык вә тугры әйтеп язсам, укучылар минем бу сүзләремнең һич арттырусыз идекләрен бик яхшы расларлар иде, фәкать бәгъзе сәбәпләр аркасында хосусыйлык сыйфатын алган вә хатыннарның үз араларына гына махсус булган бу фикерләрнең күбесен шул көе халыкның игътибарына куюю тиеш күрелмидер. Шуның өчен мин сәяхәтемдә күргәннәремнең гомуми ягын гына язып китәргә тиешле күрәмен.

Истанбулда 800гә якын мәчет бар икән, менә шул мәчетләрнең янында ир балалар мәктәбе булган кебек кыз балалар мәктәбе дә булганлыгы аңлашылды. Аның өстенә, төрле программада һәртөрле урта мәктәпләре бар. Мәгариф нәзарының рөхсәт вә мәгавәнәте[10] аркасында, кызлар мәктәбе белән бергә ирләр мәктәпләренең бик күпләрен күрдем. Игъдади *(хәзерлек)* (гимназия) хәрбия, мөлкия *(хөкүмәткә караган)*, бәхерия *(диңгез)*, тыйббия *(медицина)*, тешчелек, акушер вә фельдшерлык.

Шундый исемнәр белән Аурупа дөньясында нинди мәктәпләр булса, анда да шул мәктәпләр бар. Дарелфөнүннәре[11] ике җирдә: берсе – хокук, әдәбият, табигыять, илаһият кеби берничә бүлеккә аерылган, икенче берсе – яңа ысулда гаять яхшы бер бинада тыйббия шөгъбәсеннән гыйбарәттер. Бу мәктәпләрнең кәмаләт вә фазыйләтләрен Русия вә Аурупа мәктәпләренә чагыштырып карарга сәләтем булмаганлыктан, ул хакта сүз озайтмыймын. Кызлар мәктәбе исә күп җирдә үзләренең тәртипле вә җитеш бер рәвешкә куелулары белән миндә бик яхшы тәэсир калдырдылар. Үзләре дә бу мәктәпләрнең соң дәрәҗәдә игътибарсыз бер хәлдә тордыгы хәлдә, хәзер

[9] «Кадыннар дөньясы» – Төркиядә 1913-1921 елларда хатын-кызлар өчен нәшер ителгән журнал.
[10] Мәгавәнәт – булышлык.
[11] Дарелфөнүн – югары уку йорты.



Төрек хатын-кызларыннан беренче очучы Бәлкыйс Шәүкәт һәм Фәтхи бәк (Сөембикә, 1914, 10 нчы сан. Тышлык)

елдан-ел ислях ителдекләре вә гакылга килмәгән бер рәвештә миллиләштердекләрен сөйләделәр. Кызлар өчен төзелгән мәктәпләрдән: дарелмөгаллимат[12], инас солтани *(солтан кызлары)*, кыз санигъ *(кызлар өчен һөнәр)* мәктәбе, инас рөшдиясе *(кызлар өчен урта мәктәп)*, иттихад *(фикер бердәмлеге)* вә тәрәккый мәктәбе, вә башка берничә мәктәпләрен якыннан күреп өйрәндем. Бу мәктәпләрнең һәркаюсында дин вә тел дәресләреннән башка гомуми мәгълүмат бирә торган фәннәр өстенә, һөнәр, сәнагать, гимнастика, музыка дәресләре дә кертелгән. Электә бары ярты-йорты ибтидаи мәктәпләр белән ялгыз бер дарелмөгаллиматлары булган. Хәзер исә югарыдагы белән һәр җирдә урта мәктәпләр вә һөнәр курслары ачылган. Бу мәктәпләрнең барлыкка килүләренә башлыча сәбәп истибдад *(деспотизм)* дәвереннән соң башланган бер гомуми үзгәреш булса да, асыл җан кертүчеләр – ханымнардыр. Бу юлда соң дәрәҗәдә гайрәт иткән ханымнар бар. Шуның белән бергә, ханымнар бу хакта үзләренә бөек бер юлбашчылык иткән мәгариф министры Шакир бәк җәнапларына дә рәхмәтледер.

Хатын-кызларның мәгариф эшләренең юлга салынуында Шакир бәкнең бөек бер иҗтиһад кылганлыгын сөйлиләр. Бу ел дарелмөгаллимат янына бөек бер бина төзелеп ята. Бина кызлар өчен махсус дарелфөнүн булачак. Монда: әдәбият, риязият *(математика)* вә табигыять шөгъбәләре булачак. Тиздән тыйббия *(медицина)* кисеме дә оештырылачагы да сөйләнелә. Моңа кадәр урта мәктәпләрдә мөдирә вә мөгаллимәлек итәр өчен җитәрлек төрек ханымнары булмаган. Германия һәм Балтикадан китерткәннәр. Хәзер шул мәктәпләрдә Аурупа тәрбиясе күреп гали мәктәпләргә керерлек хәзерлек алган төрек кызлары Франция, Германия вә Англия югары мәктәпләренә китәләр. Укуны бетереп кайтканнары да бар.

Әүвәлләрдә дә бу хәл булгалаган икән, ләкин бик аз булган. Хәзер исә һәр ел берничә төрек кызы Аурупага китеп, берничәсе тәмам итеп кайтып тора. Шунлыктан, берничә ел эчендә кызлар өчен ачылган урта мәктәпләрнең һәркаюсы төрек ханымнары, төрек мөгаллимәсе вә төрек мөдирәләренең идарәсенә керәчәге аңлашыла.

[12] Дарелмөгаллимат – хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты.

Багъбостан ханым мәктәбендә Мәүлид бәйрәме (Сөембикә, 1915, 11 нче сан. – 9 бит)

Төрек кызлары никадәр мәгълүмат алмасын вә никадәр яхшы бер тәрбия күрмәсен, аларга шул көнгә кадәр тулы хокуклы мөстәкыйль бер инсан баласына караган кебек карау юк икән. Төрек ханымнары шуннан бик рәнҗи дә вә чарасыз булдыкларын аңлаттылар. Аннан соң төрек мөгаллимәләре никадәр тырышсалар вә никадәр фидакарьлек күрсәтсәләр дә аларга шул көнгә кадәр читләргә бирелгән вазыйфа бирелмәгән. Бер мәктәп вә бер сыйныфта укыган немец, француз кызларына айга ун лира хезмәт хакы биреледеге хәлдә, төрек кызларына шуның ялгыз яртысы биреледекне сөйләделәр. Шулай булганы хәлдә, төрек ханымнары үзләренең вазыйфаларында кимчелек күрсәтмиләр.

Дарелмөгаллимат, инас солтани, кыз санигъ мәктәбе дигән мәктәпләренең һәрберендә 7-8 йөз шәкерт-кыз булып, иң кечкенә мәктәпләрендә 2-3 йөз шәкерт бар. Яңа мәктәп ачылу илә кызларның тулып калганын сөйлиләр. Элек мәктәпкә йөрү иң ихлассыз эшләнә торган бер буш вакыт үткәрүдән гыйбарәт булса, хәзер иң ләззәт белән үтәлә торган бер мөкаддәс эш хәленә килгән.

Мәктәпләрнең күбесе хөкүмәт тарафыннан тәэмин ителгән. Хөкүмәт мәктәпләре өстенә, әллә никадәр хосусый мәктәпләр дә бар. Хөкүмәтнең боларга да ярдәм иткәнен сөйләделәр. Истанбул кызлары башкала кызы булу вә үзләренә махсус ягымлы, матур милли киемнәр киюләре белән дә бик җыйнак, матур вә бик ягымлы. Мәктәп кызлары бигрәк тә матур вә һәр тугрыда үзләрен тота беләләр. Вә барлыгы бертөстә киенәләр, кирәк мәктәптә вә кирәк өйләрендә булсын, үзләрен чиста вә гаять тәрбияле, әдәпле тоталар.

Мәктәпләр пансионлы вә нәһари *(көндез укый торган)*. Ике төрле. Пансионлы мәктәпләрдә ашау-эчү, яту-тору бүлмәләре, гыйбадәт урыннары аерым, гигиена таләпләренә туры китереп зурайтып эшләнгән. Гаять пөхтә, һәр урынга үзенә махсус караучы вә эш күрүче хезмәтчеләре бар. Мәктәпнең һәр китапханәсе, музәханәсе, мунчасы бар. Дарелфөнүн янында ирләр өчен дә конферанс (лекция) заллары бар. Айда ике мәртәбә конферанс бирелә икән. Бу залда тарих вә иҗтимагый төрле темаларда шәкертләргә махсус нотыклар сөйләнә, кинематограф лентасы белән дөньяда булган һәртөрле вакыйгалар, яңа чыккан нәрсәләр күрсәтелеп тора.

Партада утырып арыган вә талган балаларга кинематограф ленталарында булган файдалы вә кызык вакыйгалар күрсәтелү илә балаларның рухлары күтәрелеп, арыганлыклары онытылып, йөзләрендә шатлык яктылары күренә, өстенә, шул

арада томлы китаплар актарып алынмый торган мәгълүмат алынадыр. Берничә мәктәпләрдә гимнастика өчен ясалган әсбабы җитеш аерым тәртипле бүлмәләр, гөлләр, чәчәкләр утыртылган матур мәктәп бакчалары бар, имтихан вакытларына тугры килгәнлектән, дәрес бирү ысулларын күрә алмадым. Имтиханнарын күп күрдем. Берничә мәктәпләрендә икешәр, өчәр көн төрле дәрестән имтихан вакытларына бардым. Имтиханда һәр җирдә төрек кызларының гаять тере, кыю вә үткен булганлыкларын күрдем. Тартынып, оялып, ык-мык итеп торулар, сүз сорагач, тукталып аптырап торулар һич күренмәде. Дарелмөгаллимат мөдирәсе мөхтәрәмә Самия ханымның тырышлыгы илә дарелмөгаллимат имтиханында берничә көн булдым. 13 яшьлек бер кыз баланың чалмалы, фәсле байтак төркем вә мөдәррис һәм зыялылар алдында сораган бер сүзгә туктаусыз ярып җавап биреп торуы шул көнгә кадәр хәтеремнән чыкмый.

Төрек ханымнары арасында шундый үткен гайрәтле, сәләтле яшь кызлар җитешкәнен күргәч, бу халыкның киләчәге өметле идекендә шөбһә килергә урын калмады. Дарелмөгаллимат, кыз санигъ мәктәбе, инас солтани мәктәпләрендә ана мәктәбе (балалар бакчасы) шөгъбәләре бар. Бу шөгъбәләргә 3 яшеннән 8 яшенә кадәр булган балаларны кабул итәләр. Боларның үз кулларына китап бирелми. Һәрнәрсә хакында телдән мәгълүмат бирелә. Әхлак дәресләре сөйләнә. Бу шөгъбәләрдә һәрнәрсә җиңел. Теле ачылган вак балаларның һәркаюсы аңларлык рәвештә һәрнәрсә алга куелып (гамәли) рәвештә өйрәтелә. Музыка (пианино) белән һәртөрле милли көйләр, ватан маршлары зиһеннәре йөкли алган кадәр өйрәтелә. Үзләреннән сүз, нотык сөйләтәләр. Һәр сүзгә туры китереп әгъзаларын килешле рәвештә хәрәкәтләндерәләр. Гаять оста вә матур сөйлиләр.

Хатын-кыз мәктәпләренең күбесендә төрек теле соңында йә француз, йә немец, йә инглиз теле өйрәтү бар. Теләгән кешеләр чит телләрдән ике-өч тел белергә мөмкин. Белгәннәре һәм дә бик яхшы белгәннәре бар. Кайбер гаиләләр арасында французча, немецча мөкәммәл сөйләшүчеләрнең бик еш очраганлыгы аңлашылды. Соңгы елларда кирәк мәктәпләрдә, вә кирәк өй әчләрендә музыка бик тәрәккый иткән. Бераз хәле булган гаиләләрнең һәркаюсында пианино бар. Төрек кызлары пианинода уйнап, янына саф вә нәзек бер тавыш белән шәркый сөйләгән (җырлаган) вакытларда күздән яшьләр килеп, тәэсиремнән үземнең кайда икәнемне оныта торган идем. Белмим, төрек ханымнарының ябык тырыштан хасыйл булган моңнары, белмим, музыка вә шигырьләрендә булган нәзакәт вә нәфасәт шулкадәр тәэсир итәме? Музыка катыш төрек шәркыйсы сөйләгән вакытта адәм бөтен дөньясыннан ваз кичәдер. Махсус рәвештә Бешикташтагы «Иттихад тәрәккый» кызлар мәктәбе минем күңелемдә бик тирән тәэсир калдырды. Гаять тәртипле вә киң юлга салынган бу мәктәптә мадемуазель Руута ханым мөдирәлек итә. Мөгаллимәләре танылган төрек ханымнарыннан Харикә, Хәдичә, Белкис Шәүкәт (һавада очкан беренче төрек кызы) тырыш ханымнар икән. Яһүди вә немец мөгаллимәләре дә бар икән. Бу мәктәпкә махсус чакыру буенча барган идем. Имтихан ахырында кызлар тарафыннан төрекчә, французча дастаннар укылды. Күңелемдә иң тирән бер тәэсират калдырган мәктәп шушы мәктәп булды.

Текстны басмага Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының
Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге фәнни хезмәткәре
***Алсу Зиннәтуллина** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2019

ӘТРӘК ӘЛ-КАТКАН КЫЙССАСЫ

Элек әбием миңа:

– Нәрсә әтерәк әләмедәй катып торасың? – дияр иде. Яисә : «Җыен әтрәк-әләмнәр җыелган!» – дигән гыйбарәне ишетергә яки әдәби әсәрләрдән укырга туры килгәне бар иде. Халык хәтере, теле шундый нәрсә: анда берни дә югалмый, һәрнәрсәнең без белмәгән бер хикмәте була. «Күп укысаң, күп белерсең, чи надан ки үләрсең!» – дигәндәй, каяндыр укыган яисә ишеткән бик күп нәрсәләрнең хакыйкый мәгънәсен белмибез шул. Еллар узгач та шул гыйбарәләргә тап булсаң, кылт итеп искә төшә. Инде бу вакытта мәгълүматлырак та икәнсең, чын эзенә дә төшүең мөмкин. Менә шундый бер гыйбарәнең сәбәбенә тап булмадыммы икән, дип уйлыйм әле. Сез ни диярсез?!.

Багдад хәлифәсе әл-Мокътәдир илчелегенең Әхмәд ибне Фадлан җитәкчелегендәге төркеменең 921-922 елларда Идел буе Болгар дәүләтенә килгәндә язылган сәяхәтнамәсенә мөрәҗәгать итик (Әнвәр Хәйри тәрҗемәсе): *«Төрки угызлар җиренә җиткәч, без аларның гаскәр башлыгы янына тукталдык. Һәм аның исеме – Әтрәк ибне әл-Каткан. Ул безнең өчен төрки чатырлар кордырды һәм безне аларда урнаштырды. Без аңа бүләкләребезне бирдек: илле динар, өч мыскал мускус, карасу-кызыл күннәр, ике Мәрү киеме, карасу-кызыл итекләр, парча киемнәр һәм биш ефәк кием дә бар иде. Һәм гаскәр башлыгы, без телгә алган бүләк ителгән киемнәрне кияр өчен, өстендәге парча киемне салды. Мин аның астында булган җиләнне күрдем, ул пычрактан кисәкләргә телгәләнеп тора.Чөнки кисәкләргә таркалып бетмичә торып, үзенең гәүдәсенә тиеп торган киемен салмау – аларның йолалары икән. Әтрәк ибне әл-Каткан үзенең бөтен сакал-мыегын йолкып бетергән һәм хезмәтче кебек калган... Бервакыт ул безне үзенең аты өстендә озатып бара иде, кинәт яныбыздан бер каз очып үтте. Һәм гаскәр башлыгы үзенең җәясен киереп тартты да, атын казның астына куып алып китте. Аннан соң ул аңа атты һәм менә инде аны атып аска төшерде».*

Без бу кешенең Каткан улы Әтрәк икәнен һәм гаскәр башлыгы булуын белдек. Гаскәр башында озын, каты агач сапта әләм, ягъни хәзергечә әйтсәк, байрак җилфердәгәнлеге аңлашыла булса кирәк. Минемчә, әбием сүзе шуңа ишарә һәм халык телендә бу турыдагы ядкяр бүгенгәчә сакланган. Икенчедән, ул чактагы ышану-ырымнарга таянган киенү рәвешен, юынып, көн дә биш вакыт намаз укучы гарәп кешесе күзлегеннән моның ничек кабул ителүен күз алдына китерсәк, бар да аңлашыла. Түбән тәгәрәгән, холыксыз, шалама киемле, пычрак адәмнәргә карата кулланылучы әтрәк-әләмнәр гыйбарәсе, минемчә, нәкъ менә мең еллар элек яшәгән гаскәр башы Каткан улы Әтрәккә әйтелгән сыман тоела. Ялгышсам, кичерә күр, ерак тарихта калган борынгы кардәшем!

Әтрәк борынгы уйгыр телендә конфет дигән мәгънәне бирә. Каткан конфет килеп чыга. Ул исем үз чорында һәр балага зур өмет һәм ышаныч белән бирелә торган булган һәм явыз көчләрне, килүче җәбер-золымны адаштыру өчен дә. Нинди генә булса да, бу шәхеснең халык хәтерендә, язу-риваятьләрендә сакланырлык эшләре булган булса кирәк.

Алмаз Минһаҗ,
Кече Кайбыч ■

Шәрип Шәймиевнең музей-йорты

Шәрип Шәймиевнең музей-йорты – күпләргә үрнәк булырлык изге гамәл мисалы. Татарстанның тәүге Президентын үстергән гап-гади авылны күрергә килүчеләр өчен бу бина татар йорты символы да әле. Аерым бер шәхеснең генә түгел, милләтебезнең үткәнен чагылдыручы музей буларак та игътибарны җәлеп итә ул.

Күмәк хуҗалыклар төзелгән 1930 нчы елларда авыл җыенында бертавыштан сайланган колхозның беренче рәисенә ул вакытта 28 яшь була. Шушы көннән алып гомеренең 26 елдан артык вакытын авыр сугыш алды, сугыш чоры һәм аннан соңгы иң ачы елларда колхозның беренче җитәкчесе булып туган җирендә хезмәт куя Шәрип Шәймиев. Аның халыкка кылган игелеге бүгенге көндә дә онытылмый: исеме телдән-телгә күчеп, яшь буынга үрнәк итеп сөйләнә.

Актаныш районының Әнәк авылы халкы Шәрип ага нигезендә музей-йорт булдыру турындагы тәкъдим белән чыккач, 2001 елдан эш башланып китте: 1956 елда салынган иске йорт кабат төзекләндерелде, абзар, келәт, мунча, кое, кар базы, капка-коймалар өр-яңадан эшләнде. Музей-йорт дүрт өлештән гыйбарәт: беренче бүлмәдә Шәрип аганың үзе исән чакта кулланган әйберләре, мәсәлән, мылтыгы, телевизоры, радиоалгычы, киеп йөргән тужуркасы, утырып ял иткән диваны һ.б. бар. Шулай ук биредә аның һәм хатыны Нәгыймә Сафиулла кызының, балаларының, шул исәптән Татарстанның беренче Президенты, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең фотосурәтләре, шәхси истәлекле әйберләре дә урын алды. Икенче бүлмәдә Шәймиевләр гаиләсенең көнкүрешен чагылдырган экспонатлар тупланды. Бүлмәдәге әйберләр Шәрип аганың кызлары Дөргалия Шәрипова, Мәрзия Хамаева һәм Мәдәния Ильясоваларның истәлекләренә нигезләнеп урнаштырылды. Шулай ук монда Нәгыймә апаның күлмәге, алъяпкычы, яулыклары һәм Шәрип аганың Сабан туендагы ат ярышларында алган сөлгеләре куелды. Зур мич шул заманга туры китереп чыгарылды.

Өйалды ике бүлмәдән тора. Бер ягында – шкаф, караватъ, икенче ягында эш кораллары урын алган. Ул вакытта Илшат Шәех улы Фәрдиев «Татэнерго» ААҖнең генераль директоры иде, бу эш нигездә аның финанс ярдәме белән башкарылды.

Музей үзенең ишекләрен 2005 елның 11 июлендә ачты. Шәрип аганың балалары, оныклары музей-йортның беренче һәм кадерле кунаклары булдылар.

Музейның экспозицияләр залында Шәймиевләр гаиләсенә кагылышлы шәхси әйберләр, XX гасырга караган йорт җиһазлары һәм башка бик күп кызыклы экспонатлар белән танышырга мөмкин.

«Шәрип Шәймиевнең музей-йорты» эшчәнлеген 2011 елдан Мәдәният

министрлыгының «ТРның Актаныш районы Туган як музее» филиалы буларак дәвам итә. Хәзерге көндә музей-йортның гомуми фондында 634 берәмлек экспонат саклана.

«Шәрип Шәймиевнең музей-йорты»ннан халык өзелми. Актанышка чит илләрдән һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән вәкилләр, республика җитәкчеләре, кунаклар музей белән танышмыйча китми. Туристларда ул Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең туган нигезе буларак та зур кызыксыну уята.

«Шәрип Шәймиевнең музей-йорты» мөдире Гөлназ Гыйбадуллина ■

Безнең мирас №5 май 2019

Чишмә авылы тарихы

Чишмә авылы урыны борынгы дәвердән үк кешеләрнең игътибарын җәлеп иткән. Б.э.к. II меңьеллыкта ук бу тирәлектә яшәүчеләр булган. Авылның көньяк-көнчыгышында б.э.ның I, VI-IX гасырларына, төньяк-көнбатыш юнәлештә 300 метр читтәрәк урында б.э.к. I, II меңьеллыкларга, б.э.ның IX-X гасырларына караган кабер-лек, курган сакланып калган. 1978 елда археолог Е.П.Казаков биредә өч каберне өйрәнә. Аларның икесе – ирләрнеке, берсе яшь балалы хатынныкы була. Кабернең берсендә – һәлак булган яугир сөякләре. Хәрбигә бакый дөньяда туклану өчен бер сан ат ите дә салып калдырганнар. Башка мәрхүмнәрнең дә җәсәде янына ат ите куйганнар. Көмеш, бронза бизәнү әйберләре дә кабер иясе белән бергә күмелгән... Мәрхүмнәр Көньяк Урал, фин-угыр кабиләләренә хас йола буенча җирләнгән.

Акмалов Гаязетдин өе

1438 елда Казан ханлыгы оешкач, хәзерге Актаныш җирләре яңа дәүләти берәмлек составына керә. Табигый, ханнар Сөн һәм Ык елгалары буендагы искиткеч гүзәл җирләр белән үзләре теләгәнчә идарә итә алган. Мәсәлән, Ибраһим (?-1479) 1467 елда хан булгач, Тыңламас тирәсендәге биләмәләрне Котлыгыш бигә бүләк итеп бирә. XIX гасыр азагы-XX гасыр башында Котлыгыш бинең варислары, Мәгъдән нәселе кешеләреннән 9 гаилә җәйләү урынына – Чишмә авылына килеп төпләнә. Авылның өлкән буын кешеләре хәтерендә, әлбәттә, аларга әби-бабалары сөйләп калдырган булса кирәк, күчү вакыйгалары менә болайрак саклана.

Чишмә авылы җирләре Бакалы бояры Алексей кулында булган. 1896 елда Тыңламастан Мөхәммәтгали Әлмөхәммәтов, Харис, Габсабир, Гапсамат, Нәби, Гыйздекамал исемле кешеләр белән бергә боярга биләмә сорап барган, ләкин юллары уңмаган – җир бирмәгәннәр. Бояр аларга җиденче кеше алып килергә куш-

кан. Мөхәммәтгали, кайтып, Меңнәр авылыннан Камал атлы кешене алып килә. Нәтиҗәдә, бояр Алексей бу егетләргә җир бирә. Бирелгән биләмәне Гыйздекамал һәр гаиләгә дисәтинәләп бүлә. Ә Камалның үзенә җирне Чарлак өстеннән бирә. Бу кешеләр икмәк үстереп, аренда хакын байга шуның белән түләргә тиеш була.



МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ:

«Әле тагын шунысы бар: сөйләүләренә караганда, узган көздә генә университет студентлары «Чишмә» колхозында ындыр табагында эшләгәннәр икән дә, шунда кафедрадан өстәмә җитәкче булып М.Ногман килгән һәм, күп тә үтми, Аккүз авылындагы бер кызгамы-хатынгамы гашыйк булып, ялкынлы утлар эчендә калган, ди.

Инде сандугачлы җәйдә шөлдерле атлар белән Аккүз авылына килеп төшкәч, Ясәви белән балыклы күлләр, кымызлы тау битләрендә йөргәч... Күлләрнең берсендә пар аккошны күргәч... Теге кызнымы-хатыннымы тагын бер мәртәбә очраткач... Ничек итеп тумый калсын ул җыр? Юк, тумыйча кала алмый ул. Тумаска хакы юк аның. Инде Сара апа да иләсләнеп беткән, Мостафадан текст көтә. Көтә, дулый, малайлар урынына сүгә тегене, әллә ниләр әйтеп бетерә. Һәм...июнь иртәләренең берсендә, Сөн аръягында кымыз бияләрен урманга чыгаргач, күл өстендә балыклар чупылдаган, күршедәге Меңнәр авылы зәңгәр рәшә белән капланган сәгатьтә, шалаш янында җырның сүзләре туа.

Җыр тексты мәсьәләсендә бәхәс чыга. М.Ногман җырга теге ындыр табагы чорын кертергә тели:

«Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең...»

Сара апа бик нык каршы тора.

– Юк, юк, – ди ул, – алай ярамый. Җырның мәгънәсен алай бер кешегә кайтарып калдырырга ярамый. Рөхсәтем юк...

Ахырдан, шулай да, җыр текстында М.Ногман варианты беркетелеп кала». (Беренче вариантта – «Сөн буйларын сагынам Чишмәнең...» – ***Ред.)*** ***«Ачы тәҗрибә»дән***

Шәкүров Федот
һәм Ситдиков
Фәнәви

Тыңламас егетләре әлеге җирне әүвәлге чорда ат белән иртә таңнан килеп эшкәрткән, кайберләре, землянка казып, шунда яшәп калган. Гайнулланың ике улы – Мәгърүф һәм Мөхәммәдьяр, каравылга калу сәбәпле, авылда беренче даими яшәүчеләр булып санала. Гайнулла картның улы Мөхәммәтфатыйх хәзерге Чишмә авылы зиратына беренче мәрхүм булып җирләнә.

Тыңламас авылы кешеләрен кабат күздән кичерик. Аларның эчәргә сулары булмаган. Тау асты тоташ урман булып, тирә-ягы сазлыктан гына торган. Гыйздекамал тау итәгендә чишмә табып, Мөхәммәтгали белән Камал шул чишмәне бурап, улак куйган. Берникадәр вакыттан соң аның янәшәсендә тагын ике чишмә челтерәп ага башлый. Алга китеп булса да шуны әйтим: 1995 елда тирә-ягы төзекләндерелгән әлеге чишмәләргә «Өч чишмә» исеме бирелә.

1906-1910 елларда бу җирләргә Мөхәммәтгали, Мөхәммәтбасыйр, Гапсамат, Гайнулла, Нәби, Гыйздекамаллар килеп төпләнә. Аештан – Шәкүр, Кәзкәйдән Ногман исемле кешеләр дә боларга кушыла.

Күчеп килүчеләр мәхәллә тормышын җайга сала. Яңа төзелгән мәчеттә имам-хатыйп хезмәтен Торачыдан килгән указлы мулла Мөхәммәтхәниф хәзрәт Кутлин башкара. Аның бертуганнары: Әбелфатих – Бишкүмәчтә, Мирзасалих Торачыда имамлык итә, ә Мирзамөхәммәт мәзин хезмәтен үти.

Нигез салынган көннән алып, Чишмә Уфа губернасындагы Минзәлә өязенең Байсар волостена керә. 1913 елгы мәгълүмат буенча, Чишмәдә 238 кеше яши. 1920 елдан ул ТАССРның Минзәлә контонына, 1930 елдан Актаныш районына карый. 1920 елда 413 кеше булса, 1938 елда 408 кеше яши. Башта авыл Арка дип йөртелә, соңыннан Яңа Тыңламас атамасын ала. 1924 елда гына авылга Чишмә исеме бирәләр. Халык игенчелек, терлекчелек, арба-чана һәм

Әхмәтясәви Хөсәенов

ОНЫТА АЛМАСАМ, НИШЛӘРМЕН

Сара Садыйкова көе
Мостафа Ногман сүзләре

Сөн буйлары бөдрә урман,
Агыйделләргә җиткән.
Сөн буйларын, Чишмә авылын
Ник барып күрдем икән?!
Кушымта.

Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең,
Оныта алмасам аны, нишләрмен.

Нигә туып үсмәгәнмен
Шул Чишмә якларында?!
Елмаюын күрер идем
Очрашкан чакларымда.
Кушымта.

Сагынуларны баса алмас
Ялкынлы хатлар гына.
Бәлки юллар илтер әле
Мәхәббәт хакларына.
Кушымта.

чүлмәк ясау, кирпеч сугу, аркан ишү белән шөгыльләнә. Чишмәлеләр Гражданнар сугышын, 1921-1922 еллардагы ачлык фаҗигасен бик авыр кичерә.

1929 елда авылда күмәк хуҗалык оеша, ләкин бик күп кимчелекләр аркасында ул тиздән таркала. 1930 елда янәдән «Чишмә» колхозы төзелә. Аның беренче рәисе булып Мәрвәр Низамов сайлана. Хисапчы вазыйфасын Зәки Әхмәтдинов башкара. Колхозга беренчеләрдән булып Мәлик Шәрипов, Кәрим Галимов, Фәттах Басыйров, Мәрвәр Низамов, Зәки Әхмәтдинов, Гәрәй Гәрәевләр керә. Күмәкләштерү барышында урта хәлле һәм таза тормышлы гаиләләрнең мөлкәтләре тартып алына. Кулак дигән хөкемгә дучар ителүчеләр арасында Мөхәммәтхәниф хәзрәт, Харис һәм Акмал исемле картлар, Шәмсегали Сабитов, Хөснимәрдән Мәгъдәновлар була. Аларны авылдан сөреп, каралты-кураларын ферма, ат абзары, амбар, келәт, мәктәп итеп файдаланалар.

1930 нчы елларда күмәк хуҗалык шактый гына уңышларга да ирешә: кирпеч заводы, тимерчелек, арба-чана ясау остаханәсе булдырыла, фермалар киңәйтелә, МТСтан беренче трактор кайтартыла. Яңа кайткан трактор Чишмәнең беренче механизаторы Хәмит Шәмсиев карамагына тапшырыла. Киләчәктә аның эшен Яфәс Йосыпов, Нәсип Галиев, Мәмдүдә Галиевалар дәвам итә. Колхозда төрле эшләрдә алдынгы булып эшләгәне өчен, Лотфикамал Сабирҗанованың Мәскәүдәге Колхозчылар слетында катнашуы район күләмендә зур яңалык була.

1939 елда мәчетнең манарасын кисәләр, бинасын мәктәп итеп үзгәртеп салалар. Бөек Ватан сугышы чорыннан алып, аның алыштыргысыз җитәкчесе һәм мөгаллиме Нәвап Фәттахов була.

Бөек Ватан сугышы елларында Чишмәдән 120 кеше сугышка китә, 68е мәңгелеккә ятып кала яки хәбәрсез югала.

Сугыштан соң, игенчеләрнең зур тырышлыгы һәм фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә, күмәк хуҗалык аякка баса. 1948 елда ук ул үз акчасы хисабына өр-яңа дүртьеллык башлангыч мәктәп бинасы төзетә. Колхозны Тәхави Шәйгарданов җитәкләгән чорда авылга ГАЗ-51 автомашинасы бирелә, ул 1955 елның декабрендә кайтарыла.

1959 елда Чишмә һәм Меңнәр авыллары бер хуҗалыкка берләшә. Колхозның исеме элеккечә «Чишмә» булып кала. Бу чорда чөгендерчелек тармагы үсеш ала. Әлеге юнәлештәге уңышлары өчен, икенче комплекслы бригада «Урал» мотоциклы белән бүләкләнә. Бригада җитәкчесе Дәниф Галимов 1967 елда СССР Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенең алтын медаленә лаек була. Төрле елларда авыл советы рәисе булып Нәҗибә Галиева, Хәмит Юнысов, Гыйлемҗан Мурзин, Хәния Галиева, Фәнил Басыйров, Фәһия Сабирова, Зәйнәп Сабирова, Фатих Нәфыйков, Рәвис Камалов, Рөстәм Мостафин, Нил Камалов, Илфар Салихҗановлар эшли.

«Нәвап» мәчете

1980 елда «Чишмә» колхозын Әхмәтясәви Хөсәенов җитәкли. 1988 елда колхоз «Чишмә» һәм «Ярыш» хуҗалыкларына бүленә. 1994 елда «Чишмә» кооперативлар берләшмәсе, 2003 елда «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте итеп үзгәртелә. Соңгы егерме елдагы җитәкчеләре – Муллаян Галимәрдәнов, Нил Камалов, Рәфыйк Сәхабетдинов. 2017 елның март аенда, Чишмә һәм Меңнәр авыллары «Чишмә» хуҗалыгыннан аерылып, «Чишмә» агрофирмасы (директоры – Ирек Галимов) оештыра.

2001 елда Чишмә авылында яңа мәчет салына. Аның имамы итеп Рәфит Сабирҗан улы Сабирҗанов билгеләнә. 2008 елның 17 сентябреннән башлап, Энгель Нәвап улы Фәттахов җитәкчелеге белән, мәчеттә төзекләндерү эшләре башкарыла, өстәмә уңай шартлар тудырыла. 2008 елның 8 декабрендә – Корбан гаете көнне Чишмә авылы мәчетенә Нәвап Фәттах улы Фәттахов исеме бирелә.

2015 елгы мәгълүмат буенча, Чишмәдә 136 кеше яши.

Чишмә – РСФСРның мәгариф отличигы, Бөек Ватан сугышы ветераны **Нәвап Фәттах улы Фәттахов;** техник фәннәр кандидаты, нефть сәнәгате технологиясе галиме **Илиза Заһит кызы Әхмәтшина;** ТАССРның атказанган зоотехнигы, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры **Әхмәтясәви Хөсәенов**; техник фәннәр кандидаты, ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Актаныш муниципаль район хакимияте башлыгы (1998-2012, 2017 елдан хәзерге көнгәчә), ТР Мәгариф һәм фән министры (2012-2017) **Энгель Нәвап улы Фәттахов;** ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, хезмәт ветераны **Фаил Әбүләес улы Зыязов**; ТРның атказанган артисткасы **Гүзәл Илгиз кызы Шакирова;** ТРның атказанган укытучылары **Миллур Гали улы Таймасов, Лена Нәвап кызы Нәҗмиева, Гүзәл Нәвап кызы Мансурова, Тәслимә Нәвап кызы Садыйкова;** ТРның атказанган механизаторы **Филүс Фәттах улы Фәттахов**ларның туган һәм яшәгән авылы.

Текстны басмага Меңнәр авылы китапханәчесе
***Ләйсән Мотавалова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2019

Ихлас күңелле спикер

Әгъзам Фәйзрахманов

«Буш вакытыгызны ничек үткәрәсез?»

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга бер әңгәмә вакытында шундый сорау биргән идем.

– Буш вакыт бөтенләй калмый диярлек. Гадәттә ял көннәрендә дә төрле чараларда катнашырга туры килә. Буш вакыт булуга, гаражга чыгып китәм. Анда Әлмәттә яшәгәндә үк алган машинам бар. Шуны сүтәм дә җыям, сүтәм дә җыям. Бу эш белән көне буе шөгыльләнә алам. Вакыт кына булсын.

Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимовның Фәрит Хәйрулла улының балык тотарга бик яратуы турында да сөйләгәне бар. Алар күршеләр икән. Ф.Мөхәммәтшин балыкны күп каптыра, ди ул. Чистарту эшен бергәләп башкаралар. Берсен-берсе уздырып, мәзәкләр сөйлиләр.

Рәсми чыгыш ясаганда да юмор кыстырырга була

– Сез гел көлеп кенә тормагыз, сорауларга да җавап бирегез!

– Урра! Безнекеләр җиңә...

Фәрит Хәйрулла улы кичләрен спорт ярышлары карарга ярата. Безнекеләр җиңгәндә балалар кебек ихластан шатлана, хәтта урынында да тыныч кына утыра алмый башлый. Телевизордан аның концертларда, спектакльләрдә, төрле юбилей кичәләрендә катнашуын да күрсәтәләр.

Инде олыгаеп барса да, бик хәрәкәтчән, күпләрне сокландырырлык актив кеше ул Фәрит Мөхәммәтшин. Көн дәвамында күп кенә чараларда катнашырга өлгерә, вакыйгаларның эчендә кайный.

Гадәттә закон сагында торучыларның йөзендә елмаю сизелми. Җитди кыяфәттә йөрергә күнеккән алар. Ә Фәрит Хәйрулла улының йөзеннән елмаю беркайчан да китми. Юк кына нәрсәдән дә тәм табып, рәхәтләнеп көлә ул.

Фотолар автор архивыннан алынды. ■

Энгель Фәттахов: «САБАН ТУЕ МИЛЛИ ГОРУРЛЫКНЫ АРТТЫРЫРГА ТИЕШ!»

16 июньдә булачак Ык буе авыллары Сабан туе уңаеннан, без – «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре, Актаныш муниципаль район хакимияте башлыгы ***Энгель Нәвап улы Фәттахов*** *белән очрашып, райондагы мәдәни тормыш белән танышып кайттык. Биредәге күркәм башлангычлар, милли традицияләрне киңрәк таныту өчен, район җитәкчесе сөйләгәннәр белән сезне дә таныштырырга булдык.*

Фотолар «Актаныш информ»нан алынды

«Актаныш минем күңелемә җыр булып кереп калды».
Мөхәммәт Мәһдиев

БЕЛЕМ, МӘДӘНИЯТНЕҢ НИГЕЗЕ – ГАИЛӘДӘН

Әтием Нәвап 1938 елда Иске Әлем мәктәбен бары тик «биш»ле билгеләренә генә тәмамлап, Минзәлә педучилищесына укырга керә. Берничә елдан 18 яшьлек егетне Кызыл Йолдыз башлангыч мәктәбенә мөдир һәм укытучы итеп билгелиләр. Аның сугышка китү вакыйгасы шактый маҗаралы. Солдатларны Себердән Казан аша Мәскәүгә алып баручы эшелон станциягә килеп туктый. Буе кечкенә булганлыктан, әтием пассажир поезды баскычына иң соңгы булып күтәрелә. Әмма, кинәт аягы таеп китә дә, дыңгычлап тутырылган юл капчыгы аска таба тартып, бөтен гәүдәсе белән бетон түшәмәгә егыла. Тәненең авыртуына чыдый алмыйча, сызланып, букчасының

Нәвап һәм Рәйсә Фәттаховлар. Чишмә авылы. 1988 ел

бауларын җыештырып аягына басканчы, поезд китеп тә бара. Нишләргә белмичә аптырап басып торганда, аның янына Актаныш хәрби комиссариаты вәкиле килеп, станция янында көтеп торучы олауларга алып китә. Аны кире Актанышка алып кайтып, халык телендә «бәләкәй төрмә» дип атала торган КПЗга ябып та куялар. Озак та үтми, дезертирлыкта гаепләп, әтиемне Минзәлә төрмәсенә җибәрәләр, ике айдан соң гына Калинин фронтына озаталар. Әтием Нәвап фронтта отделение командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Авыр яралана һәм 1943 елның августында туган ягына кайтып, Чишмә мәчет-мәктәбендә җитәкче, укытучы булып эшли башлый. Ул, район мәгариф бүлегеннән бер тиен дә акча алмыйча, ачлыктан интегүче балаларны мәктәптә ашатуны җайга салып җибәрә, 1948 елда өр-яңа дүртьеллык мәктәп салып чыга.

Әнием Рәйсә дә шактый сикәлтәле тормыш юлы уза. Пучыда алты айлык бухгалтерлар курсын тәмамлап, туган авылы Ахунда эшли башлый. Сталинның «репрессия машинасы» алны-ялны белми эшләгән заман – 1952 елның көзендә кибеткә яңа партия товар китерәләр. Әнием товарны китерүчегә 16 сум акча тапшырырга тиеш була. Ләкин бу көннәрдә товар көтмәгән сатучы әлеге акчаны колхоз кассирына тапшыра, тегесе закон нигезендә кабул итә һәм укырга китеп бара. Ревизия, әлбәттә, 16 сумлык «коточкыч җитмәүчелек»не күреп ала. Нәтиҗәдә, әниемне Актаныш КПЗысына озаталар. Тиздән күчмә суд утырышы үткәрелә һәм әниемне «хөкүмәт милкенә кул сузучы» дигән гаеп белән сигез елга хөкем итәләр дә Минзәлә төрмәсенә озаталар. Ә колхоз рәисе белән бухгалтер-кассирга шул бәхетсез 16 сум өчен унар ел төрмә срогы әләгә...

Бу вакытта әнием йөкле була. Апам Гүзәл төрмәдә дөньяга аваз сала. Алар Сталин вафат булганнан соң, 1953 елның маенда азат ителә.

Әнием белән әтием биш бала тәрбияләп үстерде. Шуларның өчесе әтием һөнәрен сайлады. Хәзерге көндә алар – Татарстан Республикасының атказанган укытучылары. Әтием Нәвап, әнием Рәйсә җырлы-моңлы, бай күңелле кешеләр булды.

«ТЕАТР – ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ»

Районда узган ел гына да татар, башкорт драматургларының 50ләп әсәрен сәхнәгә куйдык. Туфан Миңнуллин әсәрләрен 6 коллектив сәхнәләштерде. Классикларыбыздан Галиәсгар Камал, Аяз Гыйләҗев, Юныс Әминов, Фәнис Яруллин, Гөлшат Зәйнашева пьесалары сәхнәгә менде. Башкортстан драматургы Наил Гаетбаев, якташларыбыз Данил Салихов һәм Ләбиб Лерон әсәрләрен дә тамашачылар яратып карады.

Актаныш халык театры Мансур Гыйләҗевнең «Мин бит сине тапкан идем» драмасын халыкка тәкъдим итте. Сәхнәдә чын тормыш кайнады, бермәлгә чынбарлык белән театр кушылган кебек тоелды. Геройларның хис-кичерешләре залда утыручыларга күчте, тамашачы алар белән бергә тормыш хаксызлыгын кичерде, мәхәббәтнең көченә инанды. Шунысы куанычлы: Актаныш халык театрында сәхнәне нигездә яшьләр тота.

Һәр иҗат коллективы дәүләт театрларында эшләүче режиссер һәм артистлар белән хезмәттәшлек итә. Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Хәкимов берничә ел рәттән Киров халык театры, Татарстанның атказанган артисты Нур Хөсәенов Иске Кормаш, Сәфәр, Теләкәй халык театлары, Татарстанның атказанган артисты Символ Гайнетдин-Агыйделский Пучы халык театры белән эшли. Күҗәкә драма коллективы белән ике ел рәттән райондашыбыз Гөлназ Таһир кызы Фатыйхова эшләде. Профессиональ талантлар авылда яшәүче үзешчән артистларга әйтеп бетергесез сәхнә тәҗрибәсе бирә.

Узган ел Казан шәһәренең XVIII төбәкара «Идел-Йорт» театр коллективлары фестивален дә Сәфәр халык театры ачып җибәргән иде. Быел исә башкалабызда «Актаныш театр көннәре» дә узачак. Иске Кормаш, Киров һәм Актаныш мәдәният хезмәткәрләре тарафыннан Нурихан Фәттахның «Ител суы ака торур» әсәре өч көндә Казан тамашачыларына тәкъдим ителә. Әле бер генә районның да Казан шәһәренә театр көннәре белән килгәне юк.

«ХАЛКЫМ ХӘЗИНӘСЕ» – БӘҺАСЕЗ МИРАС

«Халкым хәзинәсе» – авылдашлар жыены фестиваль-конкурсы районыбыздагы рухи, традицион мәдәниятне саклау өчен оештырыла торган киңкырлы, уникаль проект. Ул милләтебез җырларына, уен коралларына, биюләренә кызыксыну уятуны, нәсел-шәҗәрәләрен булдыруны; туган җирнең тарихын өйрәнүне, риваятьләрне, кулъязмаларны, халык авыз иҗатын барлауны күз уңында тота. Узган ел һәр авылда диярлек төбәк тарихына багышланган этномузейлар эшләде, аш-су осталары барланды, авыл тарихы турында фильм төшерелде, сәнгать коллективлары, гаилә, халык уен кораллары (мандолина, кубыз, хромка, саратов гармуны, курайчылар дуэтлары), вокаль ансамбльләр чыгышы булды. Иң мөһиме – авылдан чыккан легендар кешеләргә игътибар арттырылды, шушы җирлектә туып-үскән авылдашлар белән очрашулар оештырылды. Бу фестивальдә Күҗәкә, Иске Сәфәр, Әтәс, Пучы, Иске Байсар, Киров мәдәният йортлары коллективлары нәтиҗәле катнашкан иде. Ә Иске Кормаш мәдәният йорты гран-при алды.

Әлеге традиция ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан быел тагын да югарырак масштабта дәвам итәчәк. Һәр җирлек үзенең тарихын, танылган якташларын, хезмәт батырларын, осталарын, греф-гадәтләрен, йолаларын, җыр-биюләрен барлап, «Үткәннәрдән киләчәккә таба» дип исемләнгән җыен-фестиваль оештырырга тиеш. Июнь аенда «Иң матур татар авылы урамы», «Иң матур татар өе», «Иң милли йорт

капкасы», «Иң бизәкле тәрәзә кашагасы», «Өй эче иң нурлы булган йорт», «Иң төзек чишмә», «Иң төзек мәчет», «Иң милли Сабан туе» исемле конкурсларга нәтиҗә ясауны планлаштырабыз.

Тарихчы Альберт Борһанов җитәкчелегендә Ык буе авыллары тарихына багышлап узачак конференциягә зур өмет баглыйм. Туган авылым Чишмә иң борынгы хан зираты янында икән бит! Актаныш районы археологик ядкярләргә дә шактый бай. Конференциядә Мәчти авылы буенча аерым секция эшләячәк.

Актанышта быел авыл уеннары фестивале дә узачак. Чуракайдан факел кереп китә, ул һәр көндә бер авылды булып, андагы халыкны кузгатып, соңгы көндә үзәк стадионда тукталачак.

САБАН ТУЕ – ТАТАРЛЫК БЕЛӘН ГОРУРЛАНУ БӘЙРӘМЕ

Ык буе авыллары Сабан туе – Татарстанның Актаныш, Баулы, Минзәлә, Мөслим, Башкортстанның Бәләбәй, Бакалы, Туймазы, Шаран, Ярмәкәй, Оренбургның Абдулла районнары вәкилләре катнашында оештырыла торган милли җыен. Узган ел Азнакай районыннан эстафетаны Актаныш кабул итеп алды.

Без, Сабан туен тагын да миллирәк итеп оештыру өчен, регламентлар тараттык. Сабан туена кунаклар, шул исәптән авыл кешеләре үзләре дә, милли киемнән, һич югы, кәләпүш һәм калфактан килергә тиеш. Һәр мәйданда җирлекнең тарихын чагылдырган милли алан булдыруны да күз уңында тотабыз. Анда милли тарантас, бизәкле көянтәләр, килен чиләкләре, чигелгән сөлге, кулъяулыклар, кул осталарының һәм һөнәрчеләрнең эшләнмәләре, авылга бәйле фотогалереядан торган күчмә күргәзмә ясауны максат итеп куйдык. Сабан туенда Милли татар тарантасларына конкурс аерым оештырылачак.

Сабан туе татарлык белән горурлану бәйрәме булырга тиеш. Ул милли җыр һәм уеннарда гына түгел, ә киемнәрдә дә чагылыш тапсын иде. Мин керәшеннәрнең Питрау бәйрәмендә еш булам. Алар милли киемнән һич кенә дә оялмый! Ниятебез – менә шундый бәйрәмнәр ярдәмендә авылларның чисталык-пөхтәлеген тагын да арттыру, актанышлыларда милли рух һәм горурлык хисен үстерү, тарихи, мәдәни

мираска булган мөнәсәбәтне тамырдан үзгәртү. Ык буе Сабан туена кадәр Сөн буе авыллары Сабан туен да оештырырга уйлыйбыз. Шулай итеп, 2020 елда Актаныштa узачак Бөтенроссия авыл сабан туена халыкны рухи һәм табигый яктан әзерлисе иде.

АКТАНЫШЛЫЛАР – ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА ВАРИСЛАРЫ

Узган елның октябрь аенда Казанның «Пирамида» концертлар залында Әлфия Авзалова исемендәге беренче Халыкара иҗат фестивале үтте. Фестивальдә сәхнә тотучыларның күпчелеген актанышлылар тәшкил итте. 90нан артык райондашыбыз! Актанышның моңлы сандугачы Лилия Хөсәенова, «Әзифә» татар халык җырын башкарып, гран-при яулады.

Гомумән, Актаныш районы элек-электән татар әдәбияты һәм сәнгате әһелләренең яраткан төбәге булды. Сара Садыйкова, Мостафа Ногманнар бирегә килеп, матур җырлар иҗат итте. Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллиннар Актанышка еш кайта иде. Нур Баян, соңрак Гамил Афзал фестивальләре ел саен бирегә язучы-шагыйрьләрне җыйды, яшь талантларны ачыкларга ярдәм итте. Ленар Шәех, Лилия Гыйбадуллина, Эльмира һәм Гөлнара Җәлилова кебек яшь шагыйрьләребез шушы фестивальләрдә канат ныгытты. Хәзер дә мәктәпләрдә бик талантлы укучыларыбыз бар. Шушы традицияләрне киләчәктә дә сүрелдермәскә иде!

ГАРМУНГА БЕРДӘНБЕР ҺӘЙКӘЛ – АКТАНЫШТА!

Узган ел «Актаныш гармуннары» Бөтенроссия фестивален дә традициягә кертеп җибәрдек. Профессиональ гармунчылар парады тантананың иң мавыктыргыч өлеше булгандыр, мөгаен. Актаныштан гына да парадта 120гә якын гармунчы катнашты. Фестиваль вакытында Гармунга тәүге һәйкәл ачылды. Һәйкәлнең авторы – Яңа Әлем авылы егете Азат Сәрвәров.«Актаныш басмалары» скверында урын алган тимер стеланы ачканчы, сәхнәдән «Тальяннарга һәйкәл куяр идем» дип исемләнгән өр-яңа

җыр яңгырады. Бу җырның сүзләрен Уфа шәһәрендә яшәп иҗат итүче Дилә Булгакова язса, көен районлашыбыз, Актаныш композиторы Инсаф Хәбибуллин иҗат итте.

МӘГАРИФ – ИҢ МӨҺИМ ТАРМАК

Мәгариф – иң мөһим тармак. Чөнки яшьләр милләтебезнең, республикабызның киләчәге. Моны Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич та бик яхшы аңлый. Белем, тәрбия мәсьәләсе иң алгы планда торырга тиеш! Мәгариф системасы югары дәрәҗәдә икән, башка юнәлешләрдәге барлык проблемалар да хәл ителә. Сингапурның бернинди файдалы казылма байлыгы, азыгы, хәтта эчәр суы да юк, ә интеллект, белем аркасында, ул иң алдынгы илләрнең берсе булып санала. Таиланд, Көньяк Корея, Кытай һәм Финляндиядә дә шундый ук вазгыять. Бу илләрнең барысында да булып, мәгариф тармагы белән якыннан таныштым.

Бүген безнең педагоглар тарафыннан «Сингапур методикасы» дип өйрәнә торган система инде сугыштан соңгы елларда ук Чишмә башлангыч мәктәбендә эшләп килгән. Әтием Нәвап дәресләрдә беркайчан да баланың ирегең чикләмәде. Аның дәресләрендә балалар сыйныф буйлап йөри, бер-берсе белән аралаша иде. Бу – иҗади башлангычны көчәйтә торган алым. Һәр укучы педагог һәм иптәшләре белән иркен аралаша, сораулар бирә ала. Укытучы үзе дә өстәл артында гына утырмый: һәр укучы янына килеп, биремне ничек башкаруын, теманы ни дәрәҗәдә үзләштерүен тикшерә, кирәк урында күрсәтеп, дөрес чишелешне әйтеп җибәрә. Мондый мөнәсәбәт һәм аралашу алымы укучыларда үз көчләренә ышаныч уята, бер-беренә һәм белемгә хөрмәт тәрбияли. Дөнья мәгарифен өйрәнеп шуны белдем: туган авылым Чишмәдә менә шундый үзенчәлекле «Сингапур» яшәп яткан икән бит!

Әтием соклангыч характерга ия кеше иде. Ул укучыларны беркайчан да тәртип бозган һәм өлгермәүчәнлек өчен ачуланмады. Шул ук вакытта беркемне дә артык мактамады, һәрвакыт алтын урталыкны таба белде, безгә мөнәсәбәттә дә шул кагыйдәне кулланды.

Шөкер, районыбыз мәгариф тармагында да республикада иң алгы сафта. Ул шулай булырга тиеш, чөнки бер генә районның да җитәкчесе элекке Мәгариф һәм фән министры түгел! Актанышның мәгарифе дә бер башка югары булуы – табигый күренеш. ■

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

ДӨНЬЯ БӘҺАСЕ ТОРЫРЛЫК ИНСАН*

Ринат Закиров

Быелгы Кулаткы укуларын беренче мәртәбә Эдуард Әнвәр улыннан башка уздырабыз. Заманында бу укуларны, безнең белән берләшеп, ул башлап җибәргән иде.

2002 елда мин Бөтендөнья татар конгрессына килгәннән соң, алга дин әһелләре белән үзара мөнәсәбәтләрне ничек оештырырбыз икән, дигән проблема килеп басты. Чөнки һәр төбәктә дини оешмалар үзләре аерым, ә Конгресс янә аерым булып, бер-берсеннән читләшеп эш алып бара иде. Менә шушы еллардан безнең дин әһелләре белән хезмәттәшлегебез башланды. Бу эшнең башында Эдуард Әнвәр улы торды, дисәк, дөрес булыр.

Вафатына кадәр ул дин өлкәсендәге шәхесләр, имамнарыбыз белән җылы мөнәсәбәттә булды. Без һәр адымыбызны аның белән киңәшеп башкара идек. Гомумән, халкыбыз дингә бик авырлык белән кайтты: мәчетләр төзү булсынмы, андагы тормышны җайга салу, дисеңме – зур проблема иде. Хәзерге көндә исә халкыбыз иманга килде, дип әйтә алабыз. Россиядә бүген биш меңнән артык мәчет бар, шуның мең ярымы Татарстанда урнашкан. Бу эшләр милләттәшләребезне дөнья, аеруча ислам аренасында зур дәрәҗәгә күтәрде. Хәзерге көндә, һич курыкмыйча, «Татар дөньясы» дип сөйли алабыз. Чыннан да, «Татар дөньясы» – ул безнең барлыгыбыз, хәзерге яшәешебез, дигән сүз. Дөньяның 32 илендә татар оешмасы бар. Россиянең 70тән артык төбәгендә татар милли оешмалары эшли. Милли хәрәкәт булган һәр төбәктә татар халкы дини һәм милли эшләрне бердәм булып алып бара.

Татар халкын берләштерүгә үзеннән саллы өлеш керткән Эдуард әфәнде мәчетләр кору, аларның яшәешен тәэмин итү белән генә чикләнмәде. Ул, милләттәшләрен таныту өчен, Иске Кулаткы районына чын мәгънәсендә хуҗа булып та килде. Мин аннан бервакыт: «Бу сиңа артык күп булмасмы соң инде? Завод белән җитәкчелек итү дә зур җаваплылык таләп итә бит!» – дип сораган идем. Ул: «Ә мин эшләмәсәм, кем эшләсен соң аны? Кем кайгыртыр райондашларымны?» – дигән сорау белән җавап бирде. Күпләргә яхшы мәгълүм: Эдуард Әнвәр улы Иске Кулаткыдагы милли тормышны

*Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе **Ринат Зиннур улы Закиров**ның бу мәкаләсе Эдуард хаҗи Әнвәр улы Ганиевнең якты истәлегенә багышланган «Татар зыялы иганәчеләренең үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән XIX Кулаткы укуларындагы чыгышы нигезендә әзерләнде.

Фото president.tatar.ru сайтыннан алынды

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге делегация Иске Кулаткыда. 2016 ел

күтәрү өчен дә зур көч һәм тырышлык куйды. Ул бүген – Казанда, иртәгә – Мәскәүдә, аннары Сарытауда, Ульяновскида, аның беркайчан да үзенә вакыты булмады. Ул тынгысыз, эшлекле, барысына да өлгерә торган шәхес иде.

Иске Кулаткы – үзенчәлекле район. Илнең кайсы гына төбәгенә барсаң да, кулаткылыларның мәртәбәле урыны бар. Алар – белемле, зыялы халык. Эдуард Әнвәр улы моңа сөенә, якташлары белән горурлана иде. Ул райондагы һәм башка төбәкләрдәге якташ имамнарының ни белән яшәгәнен, куаныч-шатлык, борчу-мәшәкатьләрен яхшы белде. Безгә аның белән бу юнәлештә эшләргә бик җиңел булды. Эдуард Әнвәр улының тырыш хезмәте нәтиҗәсендә, кулаткылылар милләтебезгә динне кайтару өлкәсендә иң алдынгы сафка басты.

Милләтебезнең киләчәге – бердәмлектә. Татар конгрессы җитәкчелегендә ел саен дин әһелләре җыены, «Болгар җыены» кебек зур дини, мәдәни чаралар уза. Эдуард Әнвәр улы бу эшләрнең эченә кереп, мөмкин булган матди ярдәмне күрсәтеп, күп проблемаларны үз өстенә алырга әзер торган кеше булып хәтердә калды. Аның татар халкын берләштерүдә, димәк, аның киләчәген, иминлеген тәэмин итүдә кылган игелекләре дөнья бәһасе тора. Милләтебезне үстерү һәм саклауда һәрберебез шундый җаваплылык тоеп яшәсен иде.

Эдуард Әнвәр улының исемен мәңгеләштерү буенча без кулдан килгәннең барын да эшләячәкбез. Бар гомерен, мал-мөлкәтен милләтенә багышлаган шәхеснең исеме татар дөньясында яшәргә тиеш. Киләсе елларда шушы укулар «Эдуард хаҗи укулары» дип аталуын телим. Ул салган традицияләрне, аның эшләрен дәвам итсәк иде... ■

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

КЕМ УЛ ЭДУАРД ХАҖИ ГАНИЕВ?

Исхак Хәлимов*

Танылган җәмәгать эшлеклесе, Ульяновск һәм Саратов өлкәләре татар милли-мәдәни мохтариятләренең башкарма комитеты әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы әгъзасы, Дан ордены кавалеры Эдуард хаҗи Әнвәр улы Ганиевнең тормыш һәм хезмәт юлы, яшәү рәвеше гыйбрәтле дә, сокланырлык та, бик күпләр өчен үрнәк тә булырлык.

Эдуард хаҗи Әнвәр улы Ганиев 1952 елның 15 гыйнварында Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районындагы Иске Мостяк авылында туа. Гаилә традициясенә тугрылык саклап, педагог һөнәрен сайлый – Ульяновск дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетын тәмамлый. Яңа Кулатка авылы мәктәбендә җиде ел буе директор һәм физика укытучысы булып эшли, аннары Иске Кулатка район башкарма комитетының мәдәният бүлеге мөдире итеп билгеләнә. 1983 елда Сарытау шәһәренә күченеп китә. Бу калада Юл министрлыгына караган электротехника заводында хезмәт юлын кадрлар бүлеге мөдире буларак башлап, директор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 2000-2005 елларда «Автоматика һәм телемеханика» электротехника заводы генераль директоры булып эшли. Ә 2005 елдан вафатына кадәр «ГЭКСАР» дип исемләнгән электротехника заводына җитәкчелек итә. Ул еллар дәвамында, бөтен көчен һәм тырышлыгын куеп, шушы заводны ил күләмендә иң алдынгы урыннарга чыгара. Предприятиедә «Сәламәтлек саклау», «Сугыш һәм хезмәт ветераннары», «Ял итү», «Кадрлар әзерләү» дип аталган инновацияле максатчан программалар гамәлгә кертелә. Бу завод шәһәрнең бердәнбер татар гимназиясенә, Сарытау тимер юл техникумына, Россия дәүләт ачык техник университетының Идел буе филиалына, Сарытау өлкә мөселманнарының Диния нәзарәтенә һәрдаим ярдәм күрсәтә.

Эдуард Әнвәр улы берничә тапкыр Иске Кулатка район Советына депутат итеп сайлана һәм 2013 елдан 2018 елның сентябренә кадәр муниципаль берәмлек башлыгы, Депутатларның район Советы рәисе вазыйфаларын башкара. Ул, Иске Кулатка төбәге иң төзек һәм матур, гүзәл территорияләрнең берсенә әверелсен, илебез киңлекләрендә танылсын өчен, вакытын да, сәламәтлеген дә, хәләл малын да һич кызганмый. Нәкъ менә аның тырышлыгы аркасында, район Бөтенроссия авыл Сабан туеның 35 меңнән артык кунагын һәм «Түгәрәк уен» юбилей Бөтенроссия фестивалендә катнашучы 6500 кешене кабул итә, шулай ук «Кулатка укулары»н һәм «Хансөяров укулары»н, татар милләтен берләштерүгә, төрле халыклар һәм төбәкләр арасындагы дуслыкны ныгытуга юнәлдерелгән күп санлы фестивальләр, конкурсларны үткәрү мәйданчыгына әйләнә. Эдуард хаҗи 2016 елның 8 июлендә Сирия күгендә батырларча һәлак булган Россия

---

* Ульяновск өлкәсендәге «Өмет» татар газетасының баш мөхәррире **Исхак Хәлимов**ның бу мәкаләсе Эдуард хаҗи Әнвәр углы Ганиевнең якты истәлегенә багышланган «Татар зыялы иганәчеләренең үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән XIX Кулатка укуларындагы чыгышы нигезендә әзерләнде.

«Татар телен, милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне саклауда татар матбугатының роле» дип исемләнгән I татар милли матбугаты регионара фестивале. Иске Кулаткы. 2017 ел, апрель

Герое Рәфәгать Хәбибуллинның исемен мәңгеләштерү чарасын да күрә. Эдуард хаҗи Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы әгъзасы, Конгресс каршындагы татар дини оешмаларының Туплау шурасы рәисе урынбасары, Ульяновск өлкәсе мөселманнары төбәк Диния нәзарәтенең Иҗтимагый советы әгъзасы булып сайлана. Ул, сәүдәгәр Акчуриннар традициясен лаеклы рәвештә дәвам итүче меценат буларак, «Түгәрәк уен» журналын нәшер итүгә, «Өмет» өлкә татар газетасын, «Күмәк көч» район газетасын, Казан газета-журналларын халыкка җиткерүгә, Кулаткы район телевидениесен тулы канлы тормыш белән яшәтүгә, өлкә һәм район Сабан туйларын, ифтар мәҗлесләрен югары дәрәҗәдә үткәрүгә, җирле татар язучылары һәм шагыйрьләренең китапларын бастырып чыгаруга бәһасез өлеш кертә.

Эдуард хаҗи Әнвәр улы профессор, техник фәннәр докторы, Халыкара энергомәгълүмати фәннәр академиясенең академигы, Реаль икътисадның халыкара академиясе академигы, Халыкара сыйфат һәм маркетинг академиясенең мактаулы академигы дигән гыйльми дәрәҗәләргә ирешә. Тырыш, намуслы һәм фидакарь хезмәте өчен, «Мактаулы машина төзүче», «Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе» дигән шәрәфле исемнәргә, Дан орденына, Сарытау өлкәсенең «Мәрхәмәтлелек һәм хәйриячелек» мактау билгесенә, татар халкының рухи-әхлакый үсешенә зур өлеш кертүе өчен, Татарстан Республикасы Президентының Мактау грамотасына, Бөек Петр исемендәге дипломга, «Йөзьеллык меценатлары» орденына, ЮНЕСКО халыкара оешмасының «Менеджментта югары профессиональлек өчен» орденына, «Россиянең иң яхшы эш бирүчесе» почет билгесенә һәм хөкүмәтнең башка бик күп бүләкләренә лаек була.

Милли җанлы җитәкче һәм туган илебезнең данлыклы улы, юмарт татар эшмәкәре быелның 8 февралендә 68 нче яшендә фани дөньядан бакыйлыкка күчте. Ул Сарытау шәһәре янындагы Күрдем авылының мөселман зиратына җирләнде. Кеше китә, җыры кала, диләр. Эдуард хаҗи Ганиевтән соң аның хәләл малына сафка бастырылган мәчет һәм мәдрәсәләр, төзекләндерелгән урамнар һәм парклар, мәктәп һәм хастаханәләр, мәдәният учаклары, гасырлар буе халык хәтерендә сакланачак якты истәлекләр, изге эш-гамәлләр калды. ■

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

ЭДУАРД ХАҖИ ГАНИЕВ ЯДКЯРЕ

21 март көнне Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы эшчеләр поселогында ***Эдуард хаҗи Әнвәр углы Ганиевның якты истәлегенә багышланган*** *«Татар зыялы иганәчеләренең үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән* ***XIX Кулаткы укулары*** *булып узды. Әлеге мөһим чарада Татарстан Республикасыннан, Ульяновск шәһәреннән, Сарытау өлкәсеннән, Иске Кулаткы районыннан бихисап дин кардәшләребез килгән иде. Дини мәҗелестә мәрхүмнең хатыны* ***Суфия Әмирхан кызы Ганиева*** *да хөрмәтле кунак булып катнашты.*

Биредә әлеге чарада яңгыраган кайбер чыгышларны кыскартып тәкъдим итәбез.

ИЛЬЯС ХӘЗРӘТ ҖИҺАНШИН[1]:
«Эдуард хаҗиның рухи мирасы дәвамлы булырга тиеш!»

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү галәә хәйри хәлкыйкый Мүхәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗмәгииин.

Татар дөньясында Эдуард хаҗины белмәгән кеше бик сирәк. Ул милләткә чын күңелдән тугры хезмәт итүе, нинди ярдәм сорап барсаң да, аны хәл итү юлларын эзләп таба белүе, киң күңеллеге белән аерылып торды. Кешеләрне, милләттәшләрен, дин кардәшләрен Эдуард әфәнде ихлас яратты, шуңа күрә аның үзен дә бик хөрмәт иттеләр. Эдуард хаҗи Ганиев безнең өчен заманында милләтебезне мәгърифәти югарылыкка күтәргән «ак бай»ларыбызның чын варисы иде.

1905 елгы Беренче рус инкыйлабы уңаеннан Галимҗан әл-Баруди җәнаплары «Казан мөхбире» гәҗитендәге (1905 ел) хөтбәи бәлигаләренең берсендә, татар байларына мөрәҗәгать итеп: *«...И, байлар! Дәүләтегезгә алданмагыз, дәүләтегезнең хакын үтәгез, малның хәвефе бик зур... Хәлегез берлә дин файдасына иҗтиһад итегез. Галим вә мәдрәсәләргә ярдәм итегез. Бу юлда малыгызда өлеш күп булса, шул малдан, Кыяматтә хәер көтелсә, урынлыдыр»,* – дип язды. Әнвәр хаҗи менә шуны аңлап гамәл кылган шәхес иде.

Һәр мәчетнең, мәдрәсәнең, мәхәлләнең, еллар үтсә дә, исемнәре халык күңелендә уелып калган шәхесләре – имам, мөдәррис, мәзин һәм иганәчеләре була. Мәчет-мәдрәсәләрдәге эчке тормышны элек-электән күренекле химаячеләр карап-тикшереп торган. Заманы өчен гыйлемле, шәрәфле һәм булдыклы бу кешеләрне халкыбыз, үз күреп, «ак байлар» дип йөрткән. Безнең Ал мәчет һәм Якупов мәдрәсәсенең

---

[1] **Ильяс хәзрәт Җиһаншин** – Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөдире.

дә язмышы ярыйсы гына бәхетле булган дип санарга мөмкин, чөнки Апанаевлар, Галиевләр, Якуповлар, Галикәевләр, Козловлар кебек иганәчеләрнең исемнәрен атау гына да моңа дәлил булып тора. Мәчет вә мәдрәсәдәге эчке тормышны Муса Апанаев, Мөхәммәтҗан Галиев, Мөхәммәтсадыйк Галикәев кебек шәрәфле затлар карап-тикшереп торган. М.Апанаев хәйриячелеккә зур өлеш керткән: Апанай мәчетен төзеткән, Ал мәчетне салдырган. Мөхәммәтҗан Галиев – сәнәгатьче, хәйрияче, иганәче, Казан мөселман хәйрия җәмгыятен оештыручыларның берсе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен төзетүче. М.Галикәев мәшһүр Мәрҗани хәзрәтләренең күп кенә эшләрендә ярдәмләшеп яшәгән, Ал мәчет бинасын үзгәртеп төзетүче булган.

Милләт, мәхәллә халкы, шәкертләр мәнфәгатьләрен кайтыртып яшәүче, дин ислам өчен көчен, вакытын, малын-акчасын кызганмаучы иманлы бәндәләрнең безнең заманда да барлыгы – шатлыклы хәл. Эдуард хаҗи кебек шәхесләрнең исеме телдән төшмәс, рухларына дога кылыныр, дип ышанабыз.

Соңгы елларда татар яшьләренең күпләп шәһәргә китүе, мәктәпләребездә ана теле дәресләренең кыскартылуы, укытылмавы, балалар аз укыган мәктәпләрнең ябылуы, озак еллар буе ил күләмендә алып барылган атеистик тәрбия, имамнарның аз санда тәрбияләнүе, мәчет-мәдрәсәләрнең тулы канлы эшләмәве берничә буынны диннән, телебездән, мәдәнияттән читләштереп өлгерде. Элек гөрләп торган авылларыбыз бетүгә таба бара, халык бәйрәмнәре, өмәләре үткәрелми, яшьләр мәчеткә йөрми. Милли факторны читкә тибәрү галәмәте башланды. Шуның аркасында, яшьләребездә милли үзаң сүлпәнләнде, туган телдән бизү, милли мәдәнияттән, гореф-гадәтләрдән читләшү, ассимиляция көчәйде. Бу турыда без Эдуард хаҗи белән дә күп сөйләштек һәм уйландык.

Әлеге куркыныч агымга каршы торуның иң көчле чарасы – рухи вә дини тәрбия. Шуның өчен, халкыбызның иң асыл традицияләрен үзенә юлдаш итеп алган рухи тәрбия – милли үзаңыбызны уятуда, гореф-гадәтләрне, мәгариф һәм мәдәниятебезне саклауда, халкыбыз тормышының башка өлкәләрен яңартуда безнең өчен аеруча әһәмиятле, көн кадагында торган мәсьәлә.

Бүген, Аллаһыга шөкер, моның әһәмиятен аңлау бар һәм милләт үсешендә, халыкка аң-белем бирү эшендә яңа чор бара. Беренче булып безгә маякны кулаткылылар белән Эдуард хаҗи күрсәтте. Шундый мәгърифәти агарту чараларына мисал итеп, Кулаткы укуларыннан тыш, Чуашиядәге – Шыгырдан, Чистайдагы – Мөхәммәдзакир Чистави, Тәтеш районындагы – Әтрәч, Чүпрәле районындагы – Мунчәли, Зәйдәге – Таҗетдин Ялчыгол, Кукмарадагы – Мәчкәрә, Чирмешәндәге – «Хөснулла ахун укулары»н китерәсе килә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): *«Кем Исламда күркәм бер эшне башлап җибәрде исә, башлаучысына да, шуны дәвам итүчесенә дә өзлексез әҗерләре булачак»,* – дигән. Укуларны оештыру вакытында һәм аннан соң милли вә дини гореф-гадәтләребезне, мәһшүр галимнәребезнең мирасын вә тормышын өйрәнүгә, төрле төбәкләрдән чыккан тарихи шәхесләребезне, алар яшәгән урыннарны барлауга һәм авылларның тарихын өйрәнүгә игътибар артты.

Инде дистә елдан артык без, бөтен Россия күләмендә танылырга өлгергән «Кулаткы укулары» кысаларында, халкыбызның язмышы, теле-дине турында бергәләп уйланабыз, сөйләшәбез. «Кулаткы укулары» Ульяновск татарларының гына түгел, ә Идел буе мөселманнарының да фикер алышу, гыйлем җыю мәйданчыгына әйләнде. Эдуард хаҗиның башлаган эшләре дәвамлы булды, орлыклар сугарылган җиргә төште, шытымнары да нәтиҗәле булыр, иншаллаһ!

ИЛДАР ХӘЗРӘТ САФИУЛЛИН[2]:
«Эдуард хаҗи истәлегенә музей булыр тиеш»

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Элегрәк: «Эдуард Әнвәр углына хак куймагыз, аның кем икәнлеген вакытлар узгач аңларбыз», – дип әйткәнебез бар. Бу вакытлар уйламаган җирдән килде. Хәйриячетең сезнең өчен, халкы, ватандашлары, дин өчен кылган изгелекләренә киләчәктә тагын да ныграк төшенербез. Эдуард хаҗиның күп гамәлләрен без белеп тә бетермибез, аны Аллаһы Тәгалә үзе генә белә. Мөхтәрәм шәхеснең җомга көнне бакыйлыкка күчүе генә дә аның Аллаһы Тәгалә каршында дәрәҗәле кеше булуы хакында сөйли. Мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын! Аның кылган эш-гамәлләре – бик күпләр өчен дәрес.

Эдуард әфәнденең саулыгы чамалы икәнен белгәннән соң, аңа ике теләгемне җиткердем. Шуның берсе – әлеге чараны «Эдуард хаҗи укулары» дип үзгәртү турында. Без бу традицияне дәвам итәрбез, иншаллаһ. Икенчесе: «Мәдрәсәнең бер бүлмәсендә Сезнең музейны оештырырга телибез. Сез милләт өчен күп эшләр башкардыгыз, аны халкыбыз искә төшереп торырга тиеш», – дидем. Ул да миңа үз гозерен җиткерде. 2011 елда Эдуард Әнвәр углы бер бинаны мәдрәсәгә дип атап салган иде, әмма, төрле каршылыклар булу сәбәпле, анда гыйлем йорты оешмыйча калды. Әнвәр хаҗиның теләге: менә шул бинаны Диния нәзарәтенә тапшырып, анда тулы канлы мәдрәсә оештыру иде. Бу теләк безнең өстебездә олы бурыч булып тора. Киләчәктә бердәмлектә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә яшәргә язсын!

ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ ФАЗЛЫЕВ[3]:
«Эдуард әфәнде байлыкны таба һәм тота белү мәсьәләсендә бөтен дөнья татарларына үрнәк»

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү галәә хәйри хәлкыйкый Мухәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсхәәбиһи әҗемәгииин.

Аллаһы Тәгаләнең Коръән-Кәримдә динсез бер генә кавемне дә тотмыйм, аны башка кавем илә алыштырам, дигән вәгъдәсе бар. Без моның мисалын Көнбатышта яхшы күрәбез. Шуңа күрә, милләтне саклар өчен, иң әүвәл динне сакларга кирәк. Динсез милләт була алмый. Ә динне саклар өчен, мәчетләрнең яхшы эшләве сорала. Аларны кадрлар белән тәэмин итү, матди чыгымнарын күтәрү, эшчәнлеген тәэмин итү актуаль. Эдуард әфәнде, динебез милләтебезгә хезмәт итсен өчен, бөтен көчен куйды. Бездә мәчет төзүчеләр күп, әмма аның киләчәген, эшчәнлеген матди тәэмин итүчеләр сирәк.

Шиһабетдин Мәрҗанинең сүзе бар: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Ул – милли тел, милли гореф һәм милли кием». Һәр милләт үзенең милли үзенчәлеген, гореф-гадәтләрен сакларга тиеш. Кадимчеләрнең дә төп принцибы: «Әгәр без милли үзенчәлекләребезне югалтсак, милләт буларак юкка чыгачакбыз». Бирегә килгәндә

---

[2]**Илдар хәзрәт Сафиуллин** – Ульяновск өлкәсе ахуны.
[3] **Җәлил хәзрәт Фазлыев** – Татарстан мөселманнарының баш казые.

без Сабан туе мәйданын карап киттек. Бу – Эдуард әфәнде эшләтеп калдырган зур мирас. «Түгәрәк уен» фестивальләре... Милли үзенчәлекләрне саклар өчен Эдуард Әнвәр углы кебек тырышкан шәхес, мөгаен, сирәктер. Күпләр милләткә сәнгать, җырбию, дип кенә карый... Милли үзенчәлекләрне саклау – динне саклау, аның киләчәген кайгырту дигән сүз.

Динне, милләтне үстерү белән бергә, без җанны да сакларга тиеш. Демографик проблема – иң актуале. Һәр бала үз ризыгы белән туа – халыкка шуны аңлатыйк. Җан кыюдан сакланырга кирәк. Россиядә көненә 11 мең аборт ясала. Икенчедән, хәрәмнән тыелу да бик мөһим. Аракы һәм тәмәке аркасында Россиядә ел саен 1 миллион 300 мең кеше юкка чыга. Бу – көн саен 3800 кеше дигән сүз. Әлеге саннар безнең милләт өчен дә зур фаҗига.

Милләт яшәсен өчен, үзебезнең нәселебез, тарихыбыз белән горурланып, балаларыбызда милли горурлык хисе тәрбияләргә кирәк. Тарихны, шәҗәрәләрне барлау, китаплар язу буенча да Эдуард хаҗиның милләтебезгә, районгдашларына кылган изгелеге бик зур.

Милләт байлыкны таба да, тота да белергә тиеш. Эдуард әфәнде – байлыкны таба һәм тота белү мәсьәләсендә бөтен дөнья татарларына үрнәк булырлык шәхес. Аның, Кулаткы, Сарытау төбәге мөселманнарына гына түгел, безгә, татарстанлыларга да кылган ярдәме санап бетергесез. Бер елны авылыбыз мәктәбенә кереп, һәр сыйныфын карап, кызыксынып йөргәндә, аннан: «Эдуард хаҗи, Сез ничек мәктәпне шулай яхшы беләсез?» – дип сорадым. Ул: «Нигә белмәскә? Мин бит мәктәп директоры булып эшләгән кеше», – диде. Соңыннан ул мәктәбебезгә матди ярдәмен дә бирде. Югыйсә, Балтач төбәге аның өчен бөтенләй чит җир.

Шәхеснең формалашуында өч кешенең роле бик зур: әти-әнисенеке һәм хатынынныкы. Ошбу сүзләребез мәрхүмнең әти-әнисенә дога булсын. Ә җәмәгате Суфия ханымга олы рәхмәтемне җиткерәм.

Эдуард хаҗи, шундый җыеннар вакытында халык «йоклап китә» башласа, бер мәзәк сөйләп җибәр, әйдә, дия торган иде.

Шулай бервакыт мулла җомгада вәгазь сөйли икән:

– Тиз генә намаз да укый алмассыз, ураза да тота алмассыз, әмма сәдака бирә аласыз. Сәдака биреп булса да изгелек эшләгез! Әмма бер шарт бар – шайтан комачауламасын!

Бер кеше өенә әсәренеп кайткан да, карый: биш кило ярмалары бар, бүтән берни дә юк. «Кара әле, авыл башында ятим балалар яши, бер кило ярманы шуларга илтеп кайтыйм әле», – ди икән.

Шулай итеп, ярманы бер пакетка тутыра һәм ишеккә таба юнәлә. Ишектән хатыны кереп килә:

– Кая барасың? – ди икән.

Тегесе:

– Менә, сәдака илтергә барам...

Хатыны:

– Үзебезгә дә ашарга юк, ни җүнләп хезмәт хакы алып кайтмыйсың, җитмәсә, мулла сүзенә карап, кешеләргә таратасың, кертеп куй кире, – ди икән.

Теге кеше, икенче җомгага килеп, башын иеп кенә:

– Хәзрәтем, шайтан комачаулар, дип әйткән идең, каршыма шайтан үзе очрады, – дип әйткән ди...

Менә шундый «шайтан» комачауласа, Эдуард хаҗи да моның кадәр олы игелекле эшләрне башкара алмас иде. Бик зур рәхмәт җәмәгатенә! Ул бик күп изге гамәлләр кылды. Аның эшләре, кылган гамәлләре турында башкаларга үрнәк итеп сөйләргә

кирәк. Ул – хәйриячелек буенча бөтен дөньядагы эшкуарларга үрнәк. Күп заводлар таралганда, электротехника сәнәгатен югары дәрәҗәгә җиткереп, шуннан килгән табышны милләткә хезмәт иттерү!.. Моны бөтен кеше булдыра да, эшли дә алмый.

Бишенчесе – акылны саклау. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) шундый хәдисе бар: *«Байлыкны хәләл юл белән табып, тиешле урынга тоткан байлар пәйгамбәрләр, шәһидләр һәм изгеләр белән бергә кубарылырлар»*. Бай булу – гөнаһ түгел. Әмма байлык дөрес юл белән табылырга һәм тиешле урынга тотылырга тиеш. Әлбәттә, байлыкны тиешле итеп тоту өчен, акыл һәм зыялы булу кирәк. Без бай, бизнесмен яшьләребезнең акылларын милләтебезгә хезмәт иттерү юнәлешендә дә эшләргә тиеш.

Шушы биш пункт (**динне, җанны, нәселне, малны һәм акылны саклау**) җәен кабул ителәчәк «Татар милләтен саклау стратегиясе»ндә булса, мин аны, һичшиксез, тормышчан булыр, дип уйлыйм. Моңа Эдуард хаҗиның да рухы разый булыр. Ул – шушы биш пунктны гамәлгә ашыру өчен бөтен көч-куәтен куйган кеше.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Һәр яхшы сүз – сәдака», – диде. Әмма Аллаһы Тәгалә каршында безнең дәрәҗәбез монда чыгып матур сүзләр әйтү белән түгел, ә күңелебездәге уйлаганнар белән бәһаләнә. Эдуард хаҗи күңелебездә якты, матур хатирә булып калсын иде. Алга таба барыбыз да гамәлләребезне Эдуард хаҗиның рухы шат булырлык итеп башкарсак, ул башлаган эшләрне дәвам итүгә һәрберебез үзеннән саллы өлеш кертсәк иде.



РӘМИС САФИН[4]:

«Эдуард Ганиев исемендәге премия булдырырга кирәк»

Эдуард Әнвәр улгының вафаты – кулаткылылар өчен генә түгел, ә бөтен татар дөньясы өчен дә зур югалту. Мондый кешеләр йөз елга бер генә туадыр, мөгаен. Чын мәгънәсендә татар, милли җанлы кеше иде ул. Эдуард Әнвәр углы татар милли хәрәкәтен үстерү, динебезне, телебезне саклау өчен үзеннән зур өлеш кертте, башкаларга үрнәк гамәлләр кылды. Ульяновск өлкәсендә татар байлары бик күп. Алар урыс бәйрәмнәренә ярдәм итәргә мөмкин, әмма татарлык өчен гаять сараннар. Безнең Эдуард Әнвәр углы алардан бик күпкә аерылып тора иде. Шуңа да без аны татар дөньясында «ак бай» дип йөрттек. Ул дингә дә, милләткә дә ярдәм итеп яшәде. «Кулаткы укулары»нда да дини тормыш белән дөньявилыкны параллель рәвештә алып барырга өндәде.

Эдуард Әнвәр углының ярдәме белән Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы авылында беренче Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивале узды. Шулай ук татар-мишәр фестивален дә әйтергә кирәк. «Кулаткы укулары»н да ул гадәткә кертеп җибәрде. Моннан берничә ел элек оештырылган Бөтенроссия авыл Сабан туен, Эдуард Әнвәр углының саллы гына матди ярдәме булмаса, өлкә хакимияте башкарып чыга алмас иде. Эдуард хаҗи кешенең ниятенә, диненә, яшенә карап ярдәм итмәде. Ул һәркемгә мөмкин булган кадәр булышырга тырышты. Чуашка чиркәү төзеп бирде, татарга – бихисап мәчет. Берсен дә читкә какмады. Шуңа күрә дә ул Ульяновск өлкәсендә һәр милләт тарафыннан хөрмәткә һәм ихтирамга лаек шәхес булды. Эдуард хаҗиның исемен мәңгеләштерү буенча да бергәләп эшләрбез. Татар бизнес клубы белән аның исемендәге премия булдырып, аны ел саен өлкәдәге берәр милли җанлы татар малтабарына тапшырсак, яхшы булыр иде.

[4] **Рәмис Сафин** – Ульяновск өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе рәисе.

Эдуард Әнвәр углы татар авыллары тарихы буенча китаплар бастырып чыгару эшен дә җайга салды. Шунлыктан, хәзерге вакытта Иске Кулаткы – авыл тарихлары иң яхшы язылган район. Без үзебезгә шундый бурыч куйдык: өлкәдә 67 татар авылы бар, шуларның һәрберсе турында да китап булырга тиеш. Иске Кулаткы районындагы авыллар турында Эдуард хаҗи ярдәме белән дистәдән артыгы чыкты да инде. Алдагы көннәрдә без бу эшне дәвам итәрбез, дип уйлыйм.

Эдуард Әнвәр углы: «Без, татарлар – булдыра торган халык», – диде. Ул безгә берничә ел элек: «Барысы да сезгә кала, сезгә эшлисе, сезгә кала бу дөнья», – дип әйткән иде. Әйтерсең, ул барысын да тойган һәм күңеле белән сизгән. Җәмәгать, әйдәгез, Эдуард Әнвәр углы башлап җибәргән традицияләрне югалтмыйк, хезмәтләрен дәвам итик. Иске Кулаткы районы – безнең горурлыгыбыз. Халкының 93 проценты татар булган район беркайда да юк, хәтта Татарстанда да сирәк. Горурлыгыбыз булган районның дәрәҗәсен төшермик, аның күркәм традицияләрен саклыйк. Милли һәм дини тормышыбызны алга таба да бергәләшеп алып барырга насыйп булсын иде.

ЗӨФӘР ХӘКИМОВ[5]:

«Эдуард хаҗиның татар телен, мәдәниятен сөюе чиксез иде»

Эдуард Әнвәр углы белән без егерме ел дәвамында дусларча аралаштык. Сез бүген аның исемен мәңгеләштерү турында сүз алып барасыз, әмма без бу эшне инде биш ел элек үк эшләдек. Сарытау өлкәсе татар гимназиясендә ул оештырган электротехника юнәлешендәге ике сыйныф мөхтәрәм милләттәшебез исемен йөртә.

Эдуард Әнвәр углы кеше ярата торган инсан иде. Аның үз динен, милләтен, мәдәниятен сөюе чиксез булды. Ул еш кына: «Татар телен оныту – ана-атаңны оныту. Ана-атаны оныткан кеше туган илен дә оныта. Татар, динен белмәсә, көчле рухлы татар түгел инде», – дип әйтә торган иде. Шуңа күрә Эдуард хаҗи мәчетләргә ярдәм итте. Сарытау шәһәрендә ул Камил Әбләзев белән зур җәмигъ мәчет төзеде. «Туган телен укымаган бала татар телен белмәячәк! Татар, укымыйча, бизнес алып бара алмаячак, ә туган телен укымаса, малны милләт өчен сарыф итә алмаячак!» – дип әйтә иде. Шуңа күрә ул мәктәпләрне дә кайгыртты.

Без еш кына аңа: «Эдуард хаҗи, баегыз, баегыз һәм баегыз! Татарларга да бирерсез байлыгыгызны!» – дип әйтә идек. Шуны да искә алып булса кирәк, ул беркайчан да саран бай булмады. Минем теләгем: Иске Кулаткының берәр урамы һәм мәктәбе Эдуард Әнвәр углы Ганиев исемен йөртсен иде. Ул моңа лаек шәхес. Аны хәтерләү, зурлау безгә – исәннәргә мөһим.

РӘФЫЙКЪ МӨХӘММӘТШИН[6]:

«Эдурд Әнвәр углы – юмартлыкны милләтнең проблемаларын хәл итүгә юнәлдергән шәхес»

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Без Эдуард әфәнденең татар мәдәниятен, динен

[5] **Зөфәр Хәкимов** – Сарытау өлкәсе татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары.

[6] **Рәфыйкъ Мөхәммәтшин** – Россия ислам институты ректоры, галим.

үстерүдә тоткан урынын бик яхшы аңлыйбыз. Аның кебек хәйриячеләр күбрәк булса, халкыбыз күпкә алга китеп, шактый проблемалар хәл ителер иде. Иганәчелек, ярдәмчеллек, юмартлык кебек сыйфатлар киң күңеллелек галәмәте генә түгел. Әдуард Әнвәр углы мисалына килгәндә, без аның юмартлыкны милләтнең проблемаларын хәл итүгә юнәлдергән икәненә төшенәбез. Ул татар иганәчеләре, хәйриячеләре эшен, алар салган традицияләрне дәвам итүчеләрнең берсе булды. Ә андый кешеләр безгә бик кирәк.

1990 нчы елларда динебезне, мәдәниятебезне торгызырга тырыштык, чор тудырган мөмкинлекне файдаландык. Әмма, рухи яңарыш өчен матди, финанс мөмкинлекләре үзебездә булмау сәбәпле, аларны башка җирдән табарга мәҗбүр идек. Төрле фондлар оешты, гарәпләр үз акчаларына мәдрәсәләр ачып, балаларыбызны укытып, төрле традицияләр үтеп керүгә сәбәпче булды. 1990 нчы еллардагы проблемалар әле дә күренгәли. Шул вакытта ук татар хәйриячеләре уянып, әйдәгез, милләт үсеше өчен үз өлешебезне дә кертик, дип эшкә тотынган булса, милли, дини яңарыш өлкәсендә бик күпкә алга киткән булыр идек. Татар байлары бу процесска бераз соңрак кушылып киттеләр, дип әйтер идем.

Эдуард Әнвәр углы – иганәчелекнең бик мөһим икәнен, яңарышны милли җирлеккә кайтару актуальлеген аңлап эш алып барган шәхес. Ул биредәге традицияләрне барлау, аларны яңарту, татар авыллары тарихын өйрәнү белән шөгыльләнде, үзенең төпле фикерләрен әйтте. Татар милләте алдында торган проблемаларны тирәнтен аңлап, милләт үсеше өчен чиксез өлеш кертте.

Татар тарихын алсак, XVI гасырдан башлап ул татарлыкны саклап калу, динне, мәдәниятне торгызуга юнәлтелгән. Ә бу исә, иң беренче чиратта, татар байларының эшчәнлеге белән бәйле. Татар мәдәнияте үскән төбәкләрдә мәчет-мәдрәсәләр салу, мәхәллә тормышы формалашуда байларның, иганәчеләрнең ярдәме зур. Алар милләтне саклап калу һәм үстерүнең әһәмиятле проблема икәнен аңлап эш алып барган. Мәсәлән, Оренбургтагы татар мәдәнияте үсешен Әхмәт, Мәхмүт һәм Гани бай Хөсәеневләр ярдәменнән башка күз алдына китереп булмый. Алар нигез салган «Хөсәения» мәдрәсәсе – бөтен татар халкына гыйлем биргән алдынгы уку йорты. Мәдрәсә ун ел эчендә 900дән артык шәкерт чыгарырга өлгереп, алдынгы татар зыялыларын формалаштыруга зур өлеш керткән. Бу – бертуган Хөсәеневләрнең хәләл акчасына оештырылган милләт өчен бәһасез хезмәт. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе Садри Назыйпов һәм Тәфкилевләр киленнәре Суфия Җантурина-Тәфкилева акчасына салына. Аның алыштыргысыз мөдәррисе Зыя Камали җитәкчелегендә милләтебезгә меңнән артык татар зыялысы тәрбияләнгән. Революциягә кадәрге нинди генә мәдәният учагын алмыйк, татар иганәчеләренең ярдәме булмаса, аларның берсе дә милләткә хезмәт итә алмас иде. Байларыбыз татар милләтенең язмышын төптән, тирәнтен аңлап, мал-мөлкәтен туган халкы өчен кызганмаган. Нәтиҗәдә, XIX гасыр-XX йөз башында татар халкы Россиядә иң белемле, иң акыллы һәм мәгърифәтле милләт дәрәҗәсенә үсә.

Эдуард Әнвәр углын без менә шушы традицияләрне торгызучы буларак күрәбез. Ул – татар милләтен саклап калу һәм үстерү өчен нинди юнәлештә ярдәм итәргә,ниләр башкарырга, кайсы өлкәдә эшләргә кирәклеген аңлап гамәл кылган шәхесләребезнең иң олысы. Эдуард хаҗи – уникаль шәхес. Аның кебек барлык проблемаларга да киң караган кешеләребез, кызганыч, бик аз. Аның дәвамчылары күбрәк булса, милли стратегиябезне гамәлгә ашыру өчен матди җирлегебез дә нык булыр иде.

ФӘРИТ УРАЗАЕВ[7]:
«Совет чорында дин бетмәгән булса, Эдуард хаҗи имам булыр иде»

Эдуард Әнвәр углы үзенең туган ягын яратучы, үз милләтен сөюче шәхес иде. Ул бабаларыбыздан калган динебез, аның традицияләрен пропагандалаучы булды. Без аны татар дөньясында эшкуар буларак белдек, әмма ул фикер йөртүе белән гуманитар кеше. Совет чорында дин бетмәгән булса, Эдуард хаҗи тәгаен имам булыр иде. Татар эшкуарлары дөньясында бик бәрәкәтле гамәлләре белән мәшһүр булды. Аның рухы киләчәктә дә милләтебезгә хезмәт итсен. Кеше китә – җыры кала. Эдуард Әнвәр углы безгә бик күп башлангычлар калдырды.

ЛӘБИБ ЛЕРОН[8]:
«Эдуард Ганиев укулары»нда Кулаткы исеме дә сакланырга тиеш!»

Эдуард Әнвәр углы «Безнең мирас» журналын Иске Кулаткы төбәгендә тарату эшендә зур ярдәм (һәр айны 100 данә алдырды!) итеп, башка районнарның хакимият җитәкчеләренә үрнәк булырлык хезмәт күрсәтте. Без дә, үз чиратыбызда, аның үтенечен истә тотып, журналыбыз сәхифәләрендә район җирлегеннән чыккан шәхесләр – атаклы ишаннар, Сәгыйть Сүнчәләй, Вафа Бәхтияров, Кәшшаф Патии, дәүләт эшлеклеләре һ.б турында кызыклы язмалар бастырдык. Ул Кулаткы төбәгеннән чыккан шәхесләр белән горурлана иде. «Безнең мирас»та Эдуард Әнвәр углы белән ике әңгәмә, аның берничә чыгышы басылып чыкты. Очрашу-әңгәмәләрдә сүз динебез, телебез һәм, әлбәттә, Кулаткы турында барды. Соңгы очрашуыбызда төнге уникегә кадәр сөйләшеп утырдык. Шул вакытта Эдуард хаҗи Иске Мостяк авылындагы Сөнчәләй бай йортында музей ачу турында уйлавын әйтте. Без аңа музейны «Тукай һәм аның замандашлары» итеп оештырып булмасмы икән, дигән идек. Тукай даирәсендә алты Кулаткы кешесе булган! Бу музей Кулаткы төбәге өчен бер дәрәҗә булыр иде. Шулай ук, районның бренды булырлык «Балачак музее»н оештыру турында да хыялланып алдык. Эдуард хаҗи үзе дә балаларча саф күңелле, эчкерсез, кайгыртучан инсан иде.

Соңгы елларда татарның игелекле иганәчеләре сафына мин «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин**ны да кертер идем. Аның да атаклы шәхесләрне, Мәрҗани, Курсавиларны пропагандалауга, туган районы Арчадагы һәм башка төбәкләрдәге тарихи-мәдәни, табигый объектларны төзекләндерүгә, мәчетләр төзүгә керткән өлеше бик зур.

Киләчәктә булачак укулар исемендә данлыклы Иске Кулаткы атамасының да сакланып калуын телим. Чыннан да бу төбәк, бу туфрак гади генә җир түгел. **«Эдуард хаҗи Ганиев исемендәге XX Кулаткы укулары»,** атаклы иганәченең исемен яд итү белән бергә, төбәкне дә пропагандалау, аны киң масштабта таныту булыр иде. Кулаткы – татар-мишәр дөньясының бер үзәге. Бу җирләрнең бәрәкәтле туфрагы киләчәктә дә күркәм җимешләрен бирер, дип уйлыйм мин. ■

[7] **Фәрит Уразаев** – Татар конгрессының эшмәкәрләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе.
[8] **Ләбиб Лерон** – «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, язучы.

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ ТАРИХЫ

Иршат хәзрәт Сафин*

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

Пәйгамбәребез (с.г.в.): *«Үлгәннәрегезнең яхшы якларын гына искә алыгыз, начар сыйфатларын читләтеп узыгыз, күрмәгез»,* — ди. Эдуард әфәнденең исә килешмәгән сыйфатлары булмагандыр да, дип уйлыйм.

Без аның белән беренче мәртәбә 2004 елның көзендә таныштык. Ул вакытта мин туган авылым Яңа Зимничәдә яшәп, дин һәм милли мәгариф өлкәсендә зур хезмәтләр күрсәткән Хәбибулла ишан Хансөяровның тууына 200 ел тулуын ничек тә булса киң җәмәгатьчелеккә белгертү нияте белән йөри идем. Эдуард Әнвәр улы мине кабул итте, җентекләп сөйләгәннәремне тыңлады, бу вакыйганы зурлап уздырырга кирәклеген әйтте. Аның ярдәме белән, Уфа шәһәрендәге архивларда да хезмәт куеп, Хәбибулла ишан турында китап чыгардым. Ринат әфәнде Закиров әйтмешли: «Эдуар Әнвәрович бөтен эшне эченә кереп, үз йөрәге аша үткәреп башкара иде».

2005 елның язы һәм җәенең яртысы бу вакыйгага хәзерлектә, еш узган «оргкомитет» җыелышларында үтте. Һәм, нәтиҗә буларак, шул елның августында аны илебезнең төрле төбәкләреннән җыелган 10 меңнән артык халык катнашында зур җыен ясап уздырдык. Кайчандыр 7 мәчете булган Зимничә авылы бүген күпкә кечкенәрәк булса да шушы хәтле кешене кабул итә алуы, районның шундый зур чарага өй хуҗасы булуы Эдуард абыйны дәртләндерде. Беренче мәртәбә узган шундый зур милли һәм дини җыенны соңыннан район җирлегендә үтәчәк бөтен чараларга башлангыч буларак кабул итеп була. Нәкъ шул чарадан соң, Эдуард әфәнденең башына зур планнар килгәндер, дип уйларга урын бар. Әйе, ул да, без дә бу җыеннан соң җанландык, яңа эшләргә дәртләндек. Районда һәр ел квартал саен «Кулаткы укулары», елына бер мәртәбә «Хансөяров укулары», Казаннан килгән күп санлы сәнгать коллективлары һәм танылган җырчылар катнашында һәр елны Сабан туйлары гына түгел, ике мәртәбә «Түгәрәк уен» фестивале һәм Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе кебек дәүләткүләм чаралар шул 2005 елгы җыен бәрәкәте кысаларында узды, дияргә була.

Эдуар Әнвәр углы мондый чара һәм җыеннарның халыкны уята, аның үзаңын күтәрә, аны рухи яктан көчләләндерә икәнлеген сизеп алды һәм моннан соң Иске Кулаткы җирлегендә мөмкин булган һәр чараны уздырырга тырышты.

---

* Самара шәһәре җәмигъ мәчете имамы **Иршат хәзрәт Сафинн**ың бу мәкаләсе Эдуард хаҗи Әнвәр углы Ганиевнең якты истәлегенә багышланган «Татар зыялы иганәчеләренең үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән XIX Кулаткы укуларындагы чыгышы нигезендә әзерләнде.

Дин һәм дәүләт эшлеклеләре Иске Кулаткыдагы «Әнвәр» мәчетендә

Бала күңелле, эчкерсез, ихлас шәхес иде ул. Туган авылын, туган ягын бик яратты һәм бөтен көчен аның данын күтәрүгә куйды. Эдуард хаҗи, татар халкының бер улы буларак, милләттәшләренең, алар кайда гына булмасыннар, абруен күтәрүгә көч куя иде. Аның кулы, матди өлеше тимәгән чараның татар дөньясында булмаганын без алдагы чыгыш ясаучылардан ишеттек.

Ул Хәбибулла ишан Хансөяровны зурлады, аны бөтен Россиягә, Татар дөньясына танытырга тырышты. Районга килгән мөхтәрәм кешеләрне дә, кем булуларына карамастан, аның кабере янына алып килеп, дога кылдырды. Эдуард әфәнде: «Ишан хәзрәтләренең зурлыгын әле кешеләр белеп бетерми. Монда килеп дога кылу, бу җирне зиярәт итү, зиярәтченең нинди генә вазыйфада булуына карамастан, файдалы. Дөнья белән бик бәйләнгән кешеләр, бигрәк тә без — хуҗалар мәшәкать эчендә күп нәрсәне онытабыз, кирәкмәгән күп нәрсәгә буялабыз... Вакыт җитеп Аллаһ каршына баргач, монда килүләрнең файдалы булганын аңларбыз», — дип әйтә иде, мәрхүм.

Эдуард абый безгә теләк һәм бердәмлек булганда кечкенә генә татар җирлеге дә зур мәдәни чараларга мәйдан була ала икәнлеген төшендерде. Ул Иске Кулаткы районының исемен дә, искекулаткылыларның уңышларын да бөтен илгә, Татар дөньясына танытырга тырышты. Кулаткы төбәгеннән чыккан азмы-күпме танылган һәр кеше белән горурлана иде Эдуард Әнвәр улы. Дәүләт күләмендә, Татар дөньясында танылган шәхесләрне тудырып үстергән Кулаткы җирлеген ул хәзер яңа шартларда берләштерүче бер үзәк итеп файдаланырга тырышты. Ул туган төбәге Иске Кулаткы районын илдәге татарларны, аеруча, Кулаткы җирлеге белән тыгыз бәйләнеше булган тирә-як төбәкләрдәге татар-мишәрләрне үзенә сыендыручы, берләштерүче бер почмак итеп ясарга тырышты һәм бу юлда морадына ирешә дә.

Әгәр аның якты истәлегенә, аның максатларына, аның эшләренә тугрылыклы

каласыбыз килсә, бу районны, бу авылны, рәдэка (РДК) бинасын (кулаткылылар мәдәният йортын шулай йөртә. — ***Ред.***) мәрхүм Эдуард әфәнде теләгән максатларда кулланырга тырышырга тиешлебез. Әйтик, Эдуард хаҗи башлап җибәргән «Хансөяров укулары»н суфыйчылык темасына багышланган чарага нигез, мәйдан буларак файдаланып була. Дөрес, ил буенча, Татарстанда бу юнәлештәге чаралар аз түгел. Чистайда, Конгрессның Казан шәһәр бүлекчәсе рәисе Фәрит Фәез улы Мифтахов башлангычы белән, «Закир ишан Камалов укулары», Татарстанның төрле җирләрендә «Әхмәтзәки хәзрәт укулары» оештырыла.

Яшерен-батырын түгел, Иске Кулаткы районындагы күп кенә оешмалар тирә-яктагы рус район үзәкләренә күчерелде, авылларда яшәүчеләр саны да кими бара. Оптимизация, дип, районыбызны да бетерүләре бик мөмкин. Әмма Конгресс бу җирлектә дәвамлы берәр чара уздырса, район, административ берәмлек булмаса да, милләттәшләребезнең бер татар утравы булып яшәвенә ярдәм итәр иде. Кулаткы районы зур төбәкнең уртасында урнашкан. Көньяк-көнчыгышка таба күрше Радищево, Новоспасское район үзәкләрендә яшәүче милләттәшләребезнең нәсел-тамырлары безнең Кулакты районы авылларына тоташа. Көньяк-көнбатыштагы Николаевка һәм Павловка районнарындагы алты татар авылындагы милләттәшләребезнең күзләре дә — Кулаткыда. Шуңа өстәмә буларак, күрше Пенза өлкәсенең Кузнецк һәм Неверкино районнарындагы татар авылларының халкы да безнең район белән бик тыгыз элемтәдә. Самара өлкәсендәге Сызрань шәһәре татарларының 80-90 проценты — безнең районнан чыккан кешеләр. Сарытау өлкәсендә бездән 35-40 чакрымдагы Хвалынск шәһәрендә яшәүче милләттәшләребезнең барысы да диярлек Кулаткыдан чыккан. Әлеге өлкәләрдәге татар милли-мәдәни автономияләренең мәйданына керәсем килми, алар үз урыннарында зур хезмәт башкарып килә. Тик бу әйтеп үтелгән җирләрдәге милләттәшләребез рухи һәм гаиләви-көнкүреш ягыннан Иске Кулаткы районы җирлегенә ныграк бәйләнгәннәр. Ягъни Кулаткы җирлеге тирә-яктагы бик күп татар-мишәрләрнең бергә җыелу урыны була ала.

Эдуард Әнвәр улы белән Кулаткы районы гына түгел, «хвалын-кузнецк мишәрләре» дигән этнографик төркемне тәшкил иткән шушы Ульяновск өлкәсенең берничә көньяк районы, күрше Пенза өлкәсенең бер-ике районы зиратларындагы иске язулы кабер ташларының тасвирламасын һәм бу зур төбәктәге танылган дин һәм милләт әйдәманнары хакында җыентык бастыру турында зур планнар корган идек. Алай гына да түгел, Хәбибулла ишан Хансөяров хакында китап язгач, мин, суфичылык белән кызыксынып китеп, Самара төбәгендәге, Татарстанның Кизләү авылындагы ишаннар турындагы фәнни хезмәтләремне бастырыйк әле, дигәч, ул фикеремне күтәреп алган иде. Безнең, сирәк кенә булса да, төнге уникеләргә хәтле вакытны күп нәрсәләр хакында сөйләшеп уздырганыбыз бар. Кызганыч, әлеге планнар фикердә генә калды.

Милләтебезнең бу яклардагы терәге булган шушы олы шәхесебезнең арабыздан китүенә карамастан, Кулаткы җирләрен алга таба да дини һәм милли чаралар уздыру өчен нигез итеп алсак иде. Эдуард хаҗи безгә бу җирләрнең бөек, дәрәҗәле икәнен аңлатып китте. Без дә аның хәерле юлында хәерле гамәлләр кылсак иде. Амин! ■

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

АПАНАЙ МӘЧЕТЕ: тарихы һәм хәзерге заман

Нияз хәзрәт Сабиров*

Иске Татар бистәсендәге Апанай мәчете Әби патша фәрманы белән 1768-1769 елларда Ягъкуб бине Солтангали акчасына төзелгән. Иганәче, чыгышы белән, Түбән Новгород губернасындагы Камка дигән татар авылыннан. Ягъкуб бине Солтангали тарихка Казан Шәһәр Ратушасының беренче башлыгы буларак кереп калган, ягъни дүрт ел дәвамында (1784-1788) Казанның татар өлешендә беренче «мэр» булып торган. Нәкъ менә ул җитәкчелек иткән елларда Казан Ратушасы татар дөньясының икътисади-мәдәни үзәгенә әверелә башлый да инде.

Апанай мәчете

Озак еллар дәвамында мәчетне мәшһүр сәүдәгәрләр, иганәчеләр Апанаевлар карап торган, шуңа күрә аңа «Апанай» мәчете дигән исем бирелгән.

Апанай мәчетендә Салих Сәгыйтов, Исхак Сәгыйтов, Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимов, Габделгалләм Салихов һәм Мөхәммәткасыйм Салихов кебек күренекле дин әһелләре имам-хатыйп булып хезмәт иткән, мәдрәсәсендә дәрес биргән.

1930 елда Апанай мәчете Татарстан Үзәк башкарма комитеты Президиумының карары нигезендә ябыла. Совет чорында манарасы, мәчет залларының гөмбәзләре җимерелә, ә эчке як өч катка бүленә. Декоратив элементларның күбесе юк ителә. Бина балалар бакчасы буларак файдаланыла башлый.

---

* Апанай мәчетенең имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты **Нияз хәзрәт Сабиров**ның бу мәкаләсе Эдуард хаҗи Әнвәр углы Ганиевнең якты истәлегенә багышланган «Татар зыялы иганәчеләренең үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән XIX Кулаткы укуларындагы чыгышы нигезендә әзерләнде.

1995 елда мәчетне мөселман мәхәлләсенә кайтаралар. Шул вакыттан алып, фаҗигале төстә вафат булган көненә кадәр, мәчетнең имамы мәшһүр дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов (1963-2012) була. Аның тырышлыгы белән, 1997-2011 нче елларда Апанай мәчетендә комплекслы төзекләндерү эшләре үткәрелде, манара, михраб, эчке яктагы ике каты торгызылды. Мәчет федераль әһәмияткә ия һәйкәлләр исемлегенә кертелү сәбәпле, реставрация вакытында барлык эшләр сакланып калган архив документларына нигезләнеп башкарылды. Рәссам-декораторлар дивардагы бизәкләрне элеккеләре белән чагыштырып, бөтен ваклыкларын исәпкә алып, төгәллек белән яңадан ясарга тырышты. Аллаһның рәхмәте белән, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның булышлыгы аркасында, Апанай мәчетендәге реставрация эшләре 2011 елның кышында тәмамланды. 2011 елның 2 декабрендә ул рәсми төстә ачылды.

Апанай мәчетенең беренче катында Вәлиулла хәзрәт Якуповка багышланган музей урнашкан. Әлеге музей 2018 елда яңартып эшләнде.

АПАНАЙ МӘДРӘСӘСЕ

Казанның борынгы уку йортларының берсе булган Апанай мәдрәсәсе XVIII гасырның 70 нче елларында эшли башлый. Хәзерге вакытта ул Ш.Мәрҗани урамындагы 28 нче йортта урнашкан. Мәдрәсә бинасы 1877 елда архитектор П.И.Романов проекты буенча киңәйтелгән.

«Апанай» мәдрәсәсе төрле елларда төрле исемнәрдә атала. Мәдрәсәнең төп фасады Кабан күленә чыкканлыктан, ул «Күл буе» мәдрәсәсе дип тә; 1899 елдан мәдрәсә белән Апанай мәчетенең указлы имамы Мөхәммәткасыйм Габделгаллям улы Салихов җитәкчелек иткәнлектән, «Касыймия» мәдрәсәсе дип тә йөртелә. Мөхәммәткасыйм хәзрәт Салихов 1954 елда вафат булган.

Апанай мәдрәсәсе XIX гасырда Россия мөселманнары арасында иң абруйлы уку йортларының берсе булып санала. Бу мәдрәсәдә күренекле ислам дине тәгълиматчысы, җәмәгать эшлеклесе, педагог, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салучы, Русия Диния

Апанай мәдрәсәсе

Апанай мәчетендә Вәлиулла хәзрәт Якупов истәлегенә ачылган музей-бүлмә күренеше

нәзарәте рәисе **Галимҗан Баруди** (1857-1921); тел белгече, педагог, мөхәррир, җәмәгать һәм дин эшлеклесе **Әхмәдһади Максуди** (1868-1941); ислам дине тәгълиматчысы **Муса Бигиев** (1873-1949); җәмәгать эшлеклесе, педагог, тарихчы **Хөсәен Фәезханов** (1823-1866); язучы, драматург, мөхәррир, нашир һәм журналист **Гаяз Исхакый** (1878-1954); дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, юрист **Садри Максуди** (1878-1957); күренекле драматург **Галиәскар Камал** (1879-1933) һәм башка мәшһүрләребез белем алган.

1917 елгы октябрь инкыйлабыннан соң, башка дини уку йортлары кебек үк, «Апанай» мәдрәсәсе дә ябыла.

Апанай мәчете мәхәлләсе һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары тырышлыгы нәтиҗәсендә, 2010 елда мәдрәсә бинасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә, мөселманнарга кире кайтарылды.

АПАНАЙ МӘЧЕТЕ КАРШЫНДАГЫ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ-МӘГЪРИФӘТ ҮЗӘГЕ

Апанай мәчете татар осталары, һөнәрчеләре һәм сәүдәгәрләре яшәгән Иске Татар бистәсенең үзәгендә урнашкан. Биредә һөнәр остаханәләре күп булган, аерым алганда алар тире, күн эшкәртү белән шөгыльләнгән. Шул тирәдәге Күнче һәм Сафьян урамы атамалары да моңа дәлил.

Милли традицияләрне киләсе буынга тапшыру, яшьләребезгә өйрәтү эше көннән-көн актуальләшә. Борынгы һөнәрчелекне, технологияләрне белүче осталар бар әле, әмма аларга белгәнне башкаларга өйрәтү өчен мәйданчык җитәрлек түгел. Менә шуны исәпкә алып, без Апанай мәчете каршында Милли мәдәният-мәгърифәт үзәге оештырдык. Үзәк эшчәнлеге мондый юнәлешләрдә алып барыла:

1. Милли кием-салым:

– мөселман һәм милли традицияләргә туры килгән кием дизайны булдыру һәм аны тегәргә өйрәтү;

– киемнең милли үзенчәлекләренә өстәмә аксессуарлар әзерләргә өйрәтү;

– милли баш киемнәрен әзерләргә өйрәтү.

Апанай мәчетендә Вәлиулла хәзрәт Якупов истәлегенә ачылган музей-бүлмә

2. Күн мозаика:

– күн эшкәртүнең милли үзенчәлекләренә, шулай ук милли читекләр кебек күн эшләнмәләр һәм күннән милли аксессуарлар ясарга өйрәтү;

3. Сәнгать юнәлеше:

– төрле материалларга (кәгазь, керамика, күн, тукымага һ.б.) милли мотивларда бизәк төшерергә өйрәтү;

– рәсем сәнгате – бу төр сәнгатьнең батик, чигүле рәсем ясау кебек төрле креатив ысулларына өйрәтү;

– каллиграфия: милли гарәп каллиграфиясен торгызу һәм өйрәтү.

АПАНАЙ МӘЧЕТЕ КАРШЫНДАГЫ «ИМАН» НӘШРИЯТЫ

1990 елда Вәлиулла хәзрәт Якупов оештырган «Иман» нәшрияты укучыларны татар халкының бай мирасы, аның күпгасырлык тарихы, элекке һәм бүгенге чорның күренекле дин галимнәре хезмәтләре белән таныштыра. Моннан тыш, ул дистә еллар дәвамында Россиядә дини вакытлы матбугат чыгаручы беренче мөселман нәшрияты булып торды. 1992 елның августында гарәп графикасында, иске имляда кушымтасы булган татарча «Иман» газетасы теркәлде. 1993 елның октябреннән рус телендә «Вера» газетасы һәм татар телендә «Иман нуры» журналы чыга башлады. 1998 елда «Мусульманский мир» журналы теркәлде. 1994 елдан татар телендә еллык «Мөселман календаре» чыгып килә. «Иман» нәшриятында, рус һәм татар телләренә тәрҗемә ителеп, хәнәфи мәзһәбе галимнәренең дә байтак китаплары дөнья күрде.

1993 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе үз ишекләрен кабат ачты. Шәкертләргә белем алу өчен дәреслекләр, уку ярдәмлекләре кирәк иде. «Иман» нәшрияты мәдрәсәдә уку процессын оештырып җибәрүдә дә мөһим роль уйнады. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең Галимнәр шурасы карары белән, гарәп теле, фикъһ, гакыйдә, сира, тәфсир, иске татар теле һ.б. буенча уку ярдәмлекләре әзерләнеп бастырылды, белешмәлекләр һәм сүзлекләр чыгарылды. Татарстан районнарында һәм Россиянең байтак төбәкләрендә әле бүген дә «Иман» нәшриятында басылып чыккан китапларны укыйлар. ■

Бөркет биектән курыкмас

Фәнзилә Җәүһәрова

Бүгенге язма гомерен бөркет кебек биеклектә кичергән, күкләр киңлеген үзенең нык кулы, ихлас, саф күңеле белән иркен тоткан, тәвәккәл, игелекле ир-ат – Эдуард Әнвәр улы Ганиев турында барыр. Татар дөньясы аны ачык йөзле, төпле сүзле, әйткән җөмләсенең бер кәлимәсен дә җилгә чәчмичә, сүзендә нык торучы, киң күңелле, чиксез юмарт, шул ук вакытта искиткеч гади кеше буларак хәтерли. Мин исә, бу язмаистәлегемдә аның белән 11 ел дәвамында якыннан диярлек аралашуымның, бүгенге көнем каланчасыннан торып бәяләгәндә, язмышыма бер бүләк булган икәнлеген аңлаган гади бер татар хатыны кичергән мизгелләргә тукталырмын.

Эдуард Әнвәр улы белән беренче очрашу минем өчен бөтенләй көтелмәгән һәм планлаштырылмаган гамәл булды. 2007 елның шактый салкын октябрь башы көннәрендә без – Татар дәүләт фольклор үзәге галимнәреннән торган экспедиция төркеме Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына планлаштырылган сәфәргә киттек. Сәяхәтебезнең максаты Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдованың «Татары мишари» китабының яңа басмасына өстәмә материаллар туплауга һәм мишәр татарларының ураза аена бәйле гамәлләрен, йола-гадәтләрен барлауга юнәлтелгән иде. Юл озын һәм таныш булмау сәбәпле, Иске Кулаткы җиренә көн тәмам кичкә авышып беткәч кенә аяк баса алдык. Безне бик мөлаем йөзле, кулаткыларча йомшак мишәр сөйләшендә көйләп гәпләшүче Таһир Сәләев (ул вакытлардагы район җитәкчесенең ярдәмчесе) каршы алды. Гыйльми сәфәребезгә әзерлек барышында аның белән телефон аркылы берничә тапкыр сөйләшкән булсак та нарат кебек төз,

баһадир гәүдәле ир-атны күреп сокланып куйдык. Шул арада күңелгә әбиләребез телендә гәүдәле ир-атларга карата еш әйтелә торган «гөрнәдир ир» эпитеты килде. Төн җитү сәбәпле, район үзәгендә кайчандыр колхозчылар йорты буларак салынган, хәзер исә «кунакханә» ролен үтәп килүче бик җыйнак кына ике катлы бинага урнаштык. Сәфәр планы буенча, иртәнге эш сәгатем, фәнни җитәкче буларак, район хакиме бүлмәсендә башланырга тиеш. Чөнки әлеге очрашуда кузгалган сүзнең җитдилеге асылында сәфәребезнең районда яшәүче татарларга нинди кыйммәте барлыгын тәгаенләп аңлату, экспедициянең нәтиҗәле эшен тәэмин итү ята иде. Ни дисәң дә, безне авылдан-авылга йөртүче кураторны билгеләү, вакытында әзер ризыкны тәгамләп, эш планнарыбызны уйланган дәрәҗәдә үтәү – район җитәкчесенең тиешле кешеләргә төгәл бирелгән күрсәтмәсенең җиренә җиткереп үтәлүенә бик тә бәйле. Әйтергә кирәк, районның ул вакыттагы җитәкчесе Рәхимҗан әфәнде Бекеров белән очрашу бик җылы, бер-беребезне аңлап, хөрмәт һәм ихтирамлы аралашу буларак үтте. Тиз арада киңәшмә җыелды, кураторлар билгеләнде һәм без, үзебезнең хезмәтебезнең кызыклы гына түгел, җирле халыкка да кирәкле икәненә кабат инанып, эшкә керештек. Һәркөнне таң белән чыгып китәбез дә, көн кичкә авышкач кына кунакханәбезнең шактый салкын бүлмәләренә кайтып, төне буе язмаларыбызны паспортлыйбыз, табышларыбызны сөенешә-сөенешә уртаклашабыз, күңелләребездә җирле халыкка карата туган беренче хисләрбезне бер-беребезгә җиткерәбез.

Шулай мәш килеп Зимничә мәктәбендә эшләп яткан көннәрнең берендә мәктәп ишегалдына совет заманында бик зур түрәләрдә яки директорларда гына булырга мөмкин булган кара «Волга» машинасы килеп туктый. Ә аннан без үз итеп өлгергән Таһир Сәләев чыга. Аны мәктәп директоры каршы алган, күрәсең. Болар, бик ашыгып, минем янга керәләр һәм Таһир кабалана-кабалана миңа бик тиз арада Кулаткыга кем беләндер очрашуга кайтырга кирәген аңлата башлый. Мин аңа аптыраган хәлдә: «Нигә? Кем белән очрашырга? Нигә шулай ашыгыч?» – дигән сорауларымны яудырам. Бер минут чамасы торараш кебек каткан хәлдә торганнан соң, төркемдәшләремә бу авылда эшләү вакытында тагын нәрсәләргә игътибар юнәлтергә кирәклекне аңлатам да кулыма кесә телефоным һәм өс киемемне генә алып, кара «Волга»га кереп утырам да Кулаткыга таба «очабыз».

Юлда кем янына баруыбызны тәгаенлим: Таһирның сүзләреннән бик зур кеше, районда гына түгел, бөтен Россиядә, хәтта чит илләрдә дә танылган Электромеханика заводының хуҗасына баруыбызны, аның мине күрергә теләге барлыгын аңлыйм. Башыма бу кара «Волга» аныкыдыр инде, дигән уй килеп, соравымны Таһирның үзенә үк бирәм. Таһир зур горурлык белән машинаның чыннан да завод хуҗасыныкы булуын, аны районга бүләк иткәнен бик теләп сөйләп тә бирә.

Күп тә үтми, Кулаткының бер техник зонасына киләбез, җыйнак кына йорт каршына туктап, анда керәбез. Без кергәндә агач белән тышланган шактый иркен генә бүлмәдә алтылап ир-ат утыра, алар арасыннан район җитәкчесе Рәхимҗан Бекеровны танып алам, күзем уртадагы басынкы гына калын гәүдәле бер ир-атка төшә. Һәр сүзен кабаланмый, үлчәп әйтүенә, үзен иркен һәм шактый кырыс тотуына карап, мине чакырган «зур хуҗа» шушы икән, дигән фикергә киләм. Мин, кая барып утырырга белми торган мәлдә: «Бире килегез!» – дигән әмер ишетәм һәм карусыз гына аның янына барып утырам. Гел ир-атлардан гына торган компанияләрдә моңа кадәр утырырга еш туры килмәсә дә, үземне шактый иркен хис иткәнемне аңлап: «Тыңлыйм Сезне, ни гозерегез бар иде?» – дигән соравымны җиткерәм. Миңа җавап биргәндә «зур хуҗа»ның тавышы шактый йомшарып, беркадәр дустанә тонга күчә. Аның сүзләреннән акрынлап ситуациягә керә барам һәм үземнән нәрсә көтелгәнлекне төшенә башлыйм. Ми-

нем белән сөйләшү, җитез һәм эшлекле рәвештә, якынча 7-8 минут чамасы гына бара. «Зур хуҗа» сүзен, аңа бер карусыз баш иеп карап утырган ир-атлар булуына карамастан: «Мин Сездән соранам», – дип бетерә. Мишәр ир-атлары теленнән бик сирәк кенә ишетергә мөмкин булган «соранам» (безнеңчә үтенәм була инде) сүзеннән соң, мин дә бүлмәдәге бар кешегә ияреп торып басам һәм Рәхимҗан Бекеров машинасы белән Зелунай авылына китеп барганымны сизми дә калам. Шушы мизгелдә минем экспедициям бөтенләй башкача – Эдуард Әнвәр улы төзегән план белән үтә башлый. Аның асылында 2007 елның декабрендә узачак Россия Дәүләт Думасына депутатлар сайлауга бәйле халык белән очрашулар ята.

Ни хикмәт, әлеге үзенчәлекле сәяхәтнең бик күп мизгелләре хәтеремдә уелып калган. Бу вакыйгадан соң халкы белән очрашуда катнашып, барлыгы 20гә якын авылда (көненә ким дигәндә 4әр авыл) булырга туры килде. Шунда гына мин мишәрләрдәге әзи атамасының асыл мәгънәсенә төшендем. Безнең казан татарлары күз алдына да китерә алмый торган искиткеч демократик рухлы булды ул очрашулар. Әлеге җыенда дилбегә авыл әзиләре кулында: алар башта сабырлык белән район җитәкчесен тыңлый, аннан инде саллы гына сорауларын, тәкъдимнәрен яудыра башлый. Боларда ир-атларның үзара аралашу рәвеше җирле мишәр традициясенә корылган. Алгы рәттә авыл агайлары – әзиләр утыра, алар артында урта буын ир-атлары, иң арткы рәтләрдә – бик аз санда гына шәл бөркәнгән апалар, уртача яшьләрдәге хатын-кызлар. Әзиләр һәр сүзне «зур хуҗага» төбиләр, мин моннан бу як халкы өчен иң әһәмиятле кешенең, район җитәкчесеннән бигрәк, Эдуард Әнвәр улы икәнен төшенәм. Әзиләр дә аңа үз итеп: «Әнвәреч», – дип кенә эндәшә. Мин тагын бер язылмаган канунны аңлыйм: Әнвәреч – аларның үзләренеке, алар белгән, алар белән гомер сөргән мәктәп директоры, гадел һәм таләпчән булуы белән танылган шәхес – Әнвәр әзинең һәм укытучы исемен горур, тиешле дәрәҗәдә тоткан Суфия апаның улы икән дә әле! Эдуард Ганиев – нинди генә үрләр яулаган булуына карамастан, халык өчен барыбер күз алдында тәгәрәп үскән гади авыл малае. Сүз җитдиләнә төшә: әзиләр авызыннан еш кына «соранабыз» сүзләре ишетелә. Аларга Әнвәреч: «Фәлән әзи, мин бирегә зур машина белән килдем. Анда сезнең авыл ФАПына суыткыч, кушетка, тагын бик күп кирәк-яраклар китердем, хәзер бер бригада аларны тиешле урыннарга урнаштырып бетереп килә. Әле ФАП каршына асфальт та җәеп китәрләр. Була, әзи, була... Ә сезнең авылны сулы итү проекты инде расланды, проект сметалары төзелде, подрядчик табып эшкә керешәсебез генә калды. Кышка ныклап кергәнче, бу эш тә төгәлләнер», – кебек җаваплар биреп тора. Әзинең бу эшләрне үз акчасына башкарганы һәркемгә аңлашыла булыр. Гозерләр арасында районны газлаштыру, мәктәпләрдә татар телен, әдәбиятын сыйфатлы укытуга бәйле дәреслекләр, клуб түбәләре, ташланган фермаларга фермерлар кертү, авыллардагы эшсезлекне киметү, гаиләсен туйдыру өчен чит җирләрдә эш эзләп йөрергә мәҗбүр булган ир-атларны авылларга кире кайтарып, гаиләләрен саклап калу кебек ил күләмендә дә хәл ителмәслекләре дә күп булды. Мин исә, бу аралашулардан акылымны яңа күренешләр белән баетып, күңелемне соклану һәм аптырау катыш яңа хисләргә күмеп, җыелган кешеләргә халык иҗаты, күңел матурлыгы турындагы фикерләремне үзем аңлаган дәрәҗәдә җиткерә бардым. Әлеге җыеннарның ахырына куелган чыгышым шактый дулкынланган халыкны бераз тынычландыру өчен махсус оештырылган булган, күрәсең. Һәр очрашудан мин: «Боларның нинди терәкләре, иминлек сакчылары, киң күңелле кешеләре бар. Аларны ташламаганнар, кайгыртып торалар бит! Болар бик бәхетле инде!» – дигән фикергә торган саен ныграк инана барам. Шул ук вакытта: «Бу адәм ни өчен шуның кадәр акчасын, затлы табигатьле диңгез утрауларындагы виллаларны сатып алып, үз

ТР мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Ульяновск өлкәсе хакимияте башлыгы Эдуард Ганиев, Ульяновск өлкәсе губернаторы Сергей Морозов һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Иске Кулаткы Сабан туенда яшь гаиләне котлый

рәхәтенә тотмый икән?» – дигән соравым да куәтләнеп килә. Аңа җавапны мин шактый вакытлар узгач кына табачакмын.

2008 елда күренекле этнограф Рәмзия Гыйният кызы Мөхәммәдова белән «Татары мишари» дип аталган фәнни этнографик очеркның яңа басмасын әзерләдек. Әлбәттә, китапны затлы тышлык, төсле фоторәсемнәр белән һәм кирәкле дип исәпләнгән санда чыгару чыгымнарын күтәрүчебез Эдуард Әнвәр улы Ганиев булды. Шул ук елның май аенда аның белән без Казанда кабат күрештек. Очрашуыбыз соңында җөмләбез янәдән «соранам» сүзе белән тәмамланды... Бу юлы ул Иске Кулаткы районы оешуга 80 ел тулуын тәгаенләп, район халкын бер кат дәртләндерү, киләчәккә өметләрен кузгату максатыннан фольклор фестивале үткәрү турында соранды. Казанда башланган сүз, озак та үтми, 2008 елның октябрь аенда Иске Кулаткы җирендә башланып киткән «Бөтенроссия татар фольклоры фестивале – «Түгәрәк уен» буларак илкүләм танылып, зур хәрәкәткә әверелде. Ул вакытлар әле дә булса хәтердә: илебезнең 13 төбәгеннән килгән 400ләп милләттәшебез район авылларында концертлар бирде. Әллә никадәр очрашулар, күрешеп-елашуларга төрелгән өч кич, дүрт көн буе Кулаткы урамнарында татар җыры, моңы яңгырады. Күңелләребез милли рух, бердәмлек хисләре белән тулды. Безгә рәхәтләнеп аралашыр өчен бар шартлар да тудырылган, берсеннән-берсе тәмлерәк ризыклар әзерләнгән, ачык йөзле, кунакчыл оештыручыларга төгәл бурычлар куелган иде. Әлбәттә, боларның барысы артында да үзенең үткер күңел күзе белән барлап, булдырып, карап торучы, киң канатлы бөркеттәй затыбыз Эдуард Әнвәр улы Ганиев торды. Фестиваль алга таба, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты белән Татарстан Мәдәният министрлыгы канаты астында, Төмән, Екатеринбург, Пермь, Самара, Казан, Болгар, Йошкар-Ола, Кырымның Бахчасарай шәһәрләрендә узды. Ничек булдыра алгандыр, анысы миңа

мәгълүм түгел, ләкин «Түгәрәк уен»ның кайсы шәһәрдә үтүенә карамастан, Эдуард Әнвәр улы фестивальчеләрне һәрвакыт үзе сәламләп, хәл-әхвәлләрен сорашып, лаеклыларга бүләкләрен тапшырмый калмады. Бу да аның бөркетлеге, канына сеңгән җаваплылыгы билгесе булгандыр. Катнашучылар тора-бара 22 төбәктән килеп, саннары 600 кешегә җитте, ә фестивальчеләр исә Эдуард әзине «Түгәрәк уенның атасы» дигән җаваплы да, мәртәбәле дә исем-сүзтезмә белән атый башлады. Ул бу исемне бик тыйнак елмаю белән, күзләреннән җылы нур балкытып кабул итә иде.

Фестиваль үсә, зур хәрәкәткә әверелә барган мәлләрнең берендә безнең – оештыручыларның акылында «Түгәрәк уен» дип аталган журнал булдыру фикере туды. Фикер формалашып бетәр-бетмәстән үк, булачак журнал өстенә үзенең көчле рухлы ярдәм канатын Эдуард Әнвәр улы җәйгән иде инде. Үз укучысын ыклап тапканчы, журналыбызның шактый саннары аның иганәсе белән дөнья күрде. Үзе дә күңеле белән бик нык береккән кулаткылылар хакындагы, аларга хас гореф-гадәтләр турындагы язмаларны сөенеп кабул итә иде. Без исә аның белән аралашуны зур мәртәбә, тормышның олы тәҗрибәсе дип санадык. Кайчандыр шактый ерак тоелган Иске Кулаткы төбәге, бик якын кешебезнең туган ягы буларак, күңелләребезгә хуш килгән асыл җиргә әверелде.

Әнвәречнең бөтен күңелен биреп башта ишан Хансөяров, аннан «Иске Кулаткы укулары» буларак үткәргән чараларының, бар өлкәне шаулаткан мәдәни бәйрәм һәм фестивальләренең, Иске Кулаткы Сабан туйларының милли рухлы көннәре, аларның һәр мизгеле дә истә. Аның сабыр елмаюы, мул табын артында якын туганы белән аралашкан кебек җылы сөйләшүе, көннең, төннең кай сәгате булуына карамастан каршы алып, озатып калулары – барысы да күңел түренә уелган затлы, сагынып искә алырлык хатирәләр. Иске Кулаткыдагы Флаг мәйданы, XX гасыр авыл хуҗалыгы техникасы паркы, район геройлары һәм данлы шәхесләре аллеясы, хоккей тартмасы, Сабан туе мәйданы, төзекләндерелгән район музее, мәктәпләр, ФАПлар, ниһаять, газ яндырып җылыту бәхетенә ирешкән әллә ничә авылның меңәрләгән халкы, спорт мәйданнары, дистәләгән парлар өчен тегелгән милли сәхнә киемнәре, сатып алынган музыка уен кораллары, яңабаштан төзелгән мәчетләр, мәдрәсә һәм авыл имамнарына эшләрен җайлы итеп, үзара аралашып алып бару максатыннан бүләк ителгән әллә никадәр җиңел машиналар... Боларга гаиләсе авыр хәлдә калган мохтаҗларга милләтенең нинди булуына карамастан күрсәтелгән матди ярдәмне дә кушсаң, Эдуард Әнвәр улының нинди олы йөрәкле шәхес икәнлеген күзаллавы авыр булмас!..

Тагын шунысы да бар: күпләргә аңлашылып та бетмәгән киң күңеллелеге турында сүз кузгатканны ул бер дә өнәми иде, таләпчәнрәк сораганнарга җавабы: «Әниемнең миңа: «Улым, каршыңа нинди гозер белән кем генә килеп басса да, аңа мөмкинлегең булган кадәр ярдәм итә күр!» – дигән әманәтен генә үтим», – иде.

Ни кызганыч, безгә бүген бу хәлләрне үткән заманнарның якты истәлеге буларак кына сөйләргә калды. Әлбәттә, Эдуард әзи турында сөйләр сүзләр бик күп, тик аны бер мәкаләгә генә сыйдырып булмый. Ул, һичшиксез, XX гасыр башында тарих битләренә милләткә хезмәтләре белән кереп калган татар байлары Закир һәм Шакир Рәмиевләр, Акчуриннар, Апанаевлар белән беррәттән лаеклы басып торган затлы шәхесебез. Аның игелекле гамәлләре, аксакалларча алдан күрүчәнлеге, тормыш тәмен-ямен тоеп, башкаларны да сөендереп, яшәү мәгънәсен хезмәттә тапкан изге хатирәсе күңелләрдән һич җуелмас. Бу олпат шәхес күпләргә үрнәк, кемгәдер гыйбрәт, ә кайберәүләргә исә юаныч булыр... ■

Безнең мирас №5 май 2019

Хатыйп Миңнегулов: галим һәм остаз

Таһир Гыйлаҗев

Күп кенә остазлары, чордашлары, хезмәттәш-коллегалары кебек, Хатыйп Йосыф углы да төрле урыннарда эшләгән. Татар гаиләсе, татар авылы, татар мәктәбе, милли мохит булачак профессорны халкыбызның телен, моңын, гореф-гадәтләрен, рухын белгән, кавемебезнең тырышлык, үҗәтлек кебек сыйфатларын үзләштергән чын татар кешесе итеп тәрбияләгән.

Төрле өлкәдә эшләп чыныгу алган яшь егет урта белем белән генә канәгатьләнми: атаклы Казан дәүләт университетына укырга керә, анда белем ала. Университетны тәмамлагач, дәрәҗәле урыннар тәкъдим ителүгә карамастан, Хатыйп Йосыф углы үзенең туган, урта белем алган тарафларына эшкә китә: Сарман районының Чукмарлы авылында ике ел мәктәп директоры, колхозның партоешма секретаре булып эшли, балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә белем һәм тәрбия бирә. Шушы вакытта гаилә дә корып җибәрә. Үсмер чактан әдәбиятны яраткан, шигырьләр язу белән дә мавыккан, студент елларында «яшь тәнкыйтьче» буларак танылган Хатыйп Йосыф углын Казан каласы янә үзенә тарта.

Университетта ярты гасырдан артык эшләү чорында, мөгаен, Х.Миңнегулов (ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор сыйфатында) әдәбият тарихының төрле чорларыннан, «Әдәбиятны укыту методикасы», Шәрык халыклары сүз сәнгате, әдәбият теориясе, махсус (әдәби бәйләнешләр, «Диплом язу һәм фәнни эшләр методикасы», «Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты», «Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» һ. б.) һәм сайлау курсларыннан лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара. Шулай да аның төп һәм даими курсы «Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты» булды. Галимгә, татар филологиясе шөгъбәсеннән тыш, журналистика, урыс бүлеге студентларына да аерым елларда лекцияләр укырга туры килә. Х.Миңнегулов шулай ук Казан, Алабуга педагогия, Әлмәт, Түбән Кама муниципаль институтларында, Милли университетта да дәресләр алып барды. Озак еллар буе Татарстан Республикасының гына түгел, ә Россия Федерациясе төбәкләренең (Төмән, Түбән Новгород, Пенза, Мордовия, Чуашстан, Ульяновск, Пермь һ.б.) югары мәктәпләре белән тыгыз бәйләнештә тора; мөгаллимнәргә ярдәм күрсәтә. Ул Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Дүшәнбе, Хельсинки калаларында берничә мәртәбә гыйльми стажировка уза, доклад-чыгышлар ясый. Фәнни эзләнүләр мәйданы киң булган галим Төркестан, Астана, Костанай, Семей, Дүшәнбе университетларына лекцияләр укырга чакырыла, яшь гыйльми кадрлар әзерләүдә катнаша.

Х.Миңнегулов университетта эшләү елларында күп мәртәбәләр вакытлыча кафедра мөдире, декан вазыйфаларын башкарды, 1984-1989 елларда факультетның (ул вакытта әле журналистлар, урыс һәм татар филологлары бергә иде) читтән торып уку һәм кичке бүлекләрен җитәкләде. 1999-2009 елларда ул татар әдәбияты кафедрасы мөдире булды.

Х.Миңнегулов укыту-тәрбия, җәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләнештә, фән өлкәсендә инде ярты гасырдан артык нәтиҗәле генә эшләп килә. Бу шөгылен ул студент елларында ук башласа да, чын мәгънәсендә университетта эшли башлагач, төгәлрәге 1960 елның ахырларында гына керешә. XIV гасыр әдибе Сәйф Сараи иҗатын комплекслы өйрәнеп язылган хезмәт рәсми оппонентлар, рецензентлар (Г.Таһирҗанов, Ш.Абилов, Низами исемендәге әдәбият институты) тарафыннан югары бәяләнә. Бераздан галимнең Котб, Әхмәд Үргәнчи, Хисам Кятиб, Мәхмүд Болгари кебек 14 нче йөз әдипләре хакындагы хезмәтләре языла. Гомумән, Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбияты, аның традицияләре Х.Миңнегуловның гыйльми эшчәнлегендә бик тә мөһим урынны били.

Болгар-татар чоры сүз сәнгатенең йөзек кашы булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Казан ханлыгының бөек шагыйре Мөхәммәдьяр, хикмәтләр язу остасы Мәүла Колый (XVII гасыр), энциклопедик шәхес Г.Утыз-Имәни (1754-1834) эшчәнлеге дә галим игътибарыннан читтә калмый: болар хакында аның җитди язмалары бар. Хатыйп Йосыф углы – 19 нчы йөз татар әдәбиятына, аның төп вәкилләренә (Ш.Зәки, С.Кукляшев, К.Насыйри, Г.Кандалый, Ш.Мәрҗани һ.б.) багышланган монографик

Миргалим һәм Хатыйп Миңнегуловлар. Уртада - Хатыйп аганың булачак хатыны Рәмзия ханым. 1963 ел

мәкаләләр авторы. Аның Ш.Садретдинов белән берлектә архив материалларына, кулъязма чыганакларга нигезләнеп язылган «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (1982), «XIX йөз татар хрестоматияләре» (1982) исемле монографияләре гыйльми-мәдәни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде.

Х.Миңнегулов – XX гасыр башы әдәбиятын өйрәнүгә, аеруча Г.Ибраһимов, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, М.Гафури, Ш.Бабич иҗатларын тикшерүгә дә үзеннән саллы гына өлеш керткән галим. Аның игътибарыннан совет чоры һәм хәзерге татар әдәбияты фәненең үсеш-үзгәреш закончалыклары, яңа әдәби күренешләре дә читтә калмый. Х.Миңнегулов – милли сүз сәнгатенең күренекле әдипләре һәм әдәбият белеменең аерым вәкилләре (К.Нәҗми, М.Җәлил, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, Р.Гаташ, К.Булатова, Ә.Синегулов, М.Әмирханов; Х.Госман, И.Нуруллин, Г.Таһирҗанов, Ш.Абилов, Н.Юзиев, А.Әхмәдуллин, Р.Ганиева, Ш.Садретдинов, Э.Галиева, Д.Заһидуллина һ.б.) хакында да үз сүзен әйткән галим. Гомумән, ул татар сүз сәнгатен буеннан-буена, борынгы чордан алып хәзергәчә тикшерә. Аның нәтиҗәләре аерым мәкаләләрдә генә түгел, ә дәреслекләрдә, «Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур» (2014), аеруча «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» (2017) монографияләрендә шактый тулы гәүдәләнеш таба.

Галимнең татар сүз сәнгатен башка кавемнәрнең һәм мәмләкәтләрнең, бигрәк тә Шәрык халыкларының әдәбиятлары контекстында шәрехләгән «Татарская литература и Восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики» дигән докторлык диссертациясе уңышлы яклана (1991). Бу хезмәт 1993 елда аерым монография рәвешендә басылып чыга һәм ике елдан соң Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Х.Миңнегулов тикшеренүләрендә татар сүз сәнгатенең гарәп, фарсы, төрки классик әдәбиятлары белән бәйләнешләрендәге тарихи һәм мәдәни алшартлар, төп факторлар яктыртыла, багланыш төрләре ачыклана, бу әдәбиятларның үзләре, төп вәкилләре (Әл-Мөтәннәби, Әл-Мәгарри, Рудәки, Фирдәүси, Сәгъди, Низами, Гомәр

Хәйям, Гаттар, Җәләледдин Руми, Хафиз, Җами...) хакында да күптөрле мәгълүматлар бирелә, фикер-күзәтүләр бәян ителә. Профессорның татар мәдәни, этник призмасы аша антик Греция, борынгы Рим, Көнбатыш Европа, урыс әдәбиятларын яктырткан монографияләре дә [(«Этапы развития тюрко-татарской античной и русской литератур» (2014. – 288 с.), «Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей» (2017. – 360 с.), «Записи разных лет (Татарская литература: история. Поэтика и взаимосвязи» (К., 2010. – 407 с.) һ. б.] күптөрле фикер-күзәтүләргә, саллы гына ачышларга бай.

Әдәби бәйләнешләр өлкәсендә Хатыйп Йосыф углының игътибары аеруча төрки әдәбиятларга зур. Аның, мәсәлән, «Тюркское словесное искусство» китабында (2014) бу кардәш кавемнәрнең борынгыдан алып хәзергәчә булган сүз сәнгате үзара тыгыз бәйләнештә, бер система рәвешендә карала. Х.Миңнегуловның татар-төрек багланышлары, госманлы шагыйрьләре (Гашыйк-паша (1271-1332), Әхмәди (1329-1413), Мөхәммәд Чәләби (1358-1451) һәм башкалар турындагы язмалары да билгеле. Галимнең берничә мәкаләсендә татар-үзбәк, татар-төрекмән мәдәни бәйләнешләре тикшерелә, Нәваи, Лотфый, Мәхтүмколый кебек шагыйрьләрнең иҗатлары яктыртыла.

Хатыйп Йосыф углы соңгы ике дистә елда Казакъстан белән әдәби-мәдәни һәм фәнни бәйләнешләрне аеруча көчәйтте һәм шуның нәтиҗәсе буларак, аның казакъ-татар бәйләнешләре, бу кавемнең Абай, Мохтар Ауэзов, Зәки Әхмәтов, Күлбәк Эргобәк һәм кайбер башка каләм әһелләре турында дистәләгән мәкаләсе дөнья күрде. Х.Миңнегулов Казакъстанда төрки телләрдә нәшер ителгән берничә җитди хезмәтнең автордашы да [Turkic up bringing – Түрк тәрбие... Антология о тюркском воспитании... На восьми (в том числе и на английском) языках (Алма-Ата. 2013, – 1004с.) и др.]. Дөньякүләм мәшһүр язучы Чыңгыз Айтматов темасы Х.Миңнегуловның бу юнәлештәге гыйльми эшчәнлегенең бер тармагы булып тора.

Хатыйп Миңнегулов - Пенза өлкәсенең Качкару мәктәбе мөгаллиме. 1962 ел

Хатыйп Йосыф углының күпчелек хезмәтләре ориенталистика (шәрыкшенаслык) һәм тюркология белән бәйле. Аның «Казанско-татарская тюркологическая школа» дигән махсус монографиясе бар. 2016 елда Алматыда өч китап булып урыс, казакъ, инглиз телләрендә дөнья күргән «Тюркология: История всемирной тюркологии» дигән күмәк монографиянең дә бер бүлеге Казан профессоры тарафыннан язылган. Галимнең «Идея государственности в тюрко-татарской литературе VII-XVI вв.» монографиясе (2016) төрки дөньяда зур кызыксыну тудырды. Аның аерым өлешләре төрле халыкара басмаларда да (шул исәптән Казакъстанда да) нәшер ителде.

Гаяз Исхакый (1878-1954) – классик язучы, сәясәтче, журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе. Х.Миңнегулов – бу бөек шәхеснең мирасын кайтаруда, аның күпкырлы эшчәнлеген (бигрәк тә мөһаҗирлектәге әсәрләрен) өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхес. Әдип хакында аның «Исхакый мөһаҗирлектә» (1999), «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» (2004. – 368 б.) исемле монографияләре, 60тан артык мәкалә-публикациясе бар. Галим Г.Исхакыйның күп кенә язмаларын, шул исәптән аның атаклы «Ислам мәмләкәтләрендә» исемле сәяхәтнамәсен дә тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш сүз белән бастырып чыгарды.

Хатыйп Йосыф углы – Г.Исхакый эшчәнлеген тикшерү белән тыгыз мөнәсәбәттә, татар мөһаҗирлек әдәбиятын һәм матбугатын да җитди өйрәнгән галим. Аның «Kazan», «Яңа милли юл», «Яңа япун мөхбире», «Азат Ватан» журналлары, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Сания Гыйффәт, Минһаҗ Исмәгыйли, Әкъдәс Нигъмәт Курат һәм мөһаҗирлектә яшәп иҗат иткән кайбер башка татар әдипләре хакындагы язмалары татар, төрек, урыс телле укучыларга яхшы таныш. Х.Миңнегуловның «Чит илләрдәге татар әдәбияты» исемле китабы (2007. – 399 б.) уку-укыту процессында да бик теләп файдаланыла. Профессор киң җәмәгатьчелеккә дәреслекләр [(«Туган тел китабы: 5 нче сыйныф өчен дәреслек» (Б.Мифтахов, Н.Садриев белән берлектә язылган); «Әдәбият» 9 нчы сыйныф өчен дәреслек (Ш.Садретдинов белән берлектә язылган)] авторы буларак та билгеле.

Х.Миңнегулов – әдәбиятның теоретик һәм методологик мәсьәләләрен өйрәнүгә дә зур өлеш керткән галим. Ул, мәсәлән, фәндә беренчеләрдән булып, кысалы кыйсса жанрын өйрәнде. Аның «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» монографиясе (1988. – 198б.) тюркологик тикшеренүләрдә еш телгә алына. Галимнең, төрки-татар, Шәрык, антик Греция, Рим, Европа, урыс әдәбиятларына нигезләнеп, сүз сәнгате тарихын чорларга бүлү турындагы карашлары да кызыклы. Аның бу хактагы фикер-күзәтүләре профессорның «Этапы развития...» монографиясендә шактый тулы чагылыш тапкан.

Озак гасырлар буе колониаль изелү, хокуксызлык, тарихның бәла-афәтләре аркасында, татарның күп кенә язма истәлекләре, рухи ядкярләре юкка чыккан яисә тиешенчә барланмыйча, тикшерелмичә ята. Аларны эзләү, табу, өйрәнү, зарури шәрех-аңлатмалар биреп хәзерге укучыларга җиткерү дә – галимнәрнең, шул исәптән әдәбиятчыларның да мөһим бурычы. Шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлап, Х.Миңнегулов та бу юнәлештә шактый гына эш-гамәлләр кылып килә. Ул илебезнең татарлар яши торган күп кенә төбәкләренә оештырылган археографик, фольклор экспедицияләре вакытында ук күп кенә кулъязма һәм басма китаплар, халык авыз иҗаты әсәрләре табып, аларны китапханә-музейларга тапшырды, гыйльми-мәдәни әйләнешкә кертте. Галим шулай ук илебездәге һәм чит мәмләкәтләрдәге (аеруча Финляндиядәге, Төркиядәге) архивлардан, дәүләти һәм шәхси китапханәләрдән дә шактый гына язма истәлекләр табуга, аларны гавамга җиткерүгә иреште. Хатыйп Йосыф углының текстологик тикшеренүләренең нәтиҗәсе буларак, Сәйф Сараиның «Гөлестан. Лирика. Дастан»

Самара университеты студентлары белән

(1999), Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (2001, 2014), Шәмседдин Зәки һәм Салихҗан Кукляшев мираслары (1982), Әхмәд Үргәнчи, Котб, Хәсән Хәмидулла [«Яңапар тарихы» (2008), шигырьләре], Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Минһаҗ Исмәгыйли һ. б.ларның әсәрләре, аерым китап-басмалар рәвешендә, киң катлам укучыларга җиткерелде. Галим Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге публицистик мирасын халыкка кабат кайтаруда да нәтиҗәле эшләр башкарды.

Х.Миңнегулов академик басмаларны әзерләүдә һәм чыгаруда да актив катнашып килә. Мәсәлән, 8 томлык татар әдәбияты тарихының тәүге өч китабындагы дистәләгән бүлек аның тарафыннан язылган. Җиде томлык «Татар тарихы»ның Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятына кагылышлы бүлекләренең дә авторы ул. Чит илләрдә, инглиз, төрек, казакъ телләрендә нәшер ителгән академик басмаларда да аның язмалары очрап тора [Мәсәлән, 33 томлык төрки әдәбиятлары тарихында (Анкара), «Tatar History and Givilisation» (Istanbul, 2012. – S.303-311) һ.б.]. Элеккеге рухи мирас әдәбият тарихы, ислам дине, суфыйчылык белән тыгыз бәйләнешле. Шуны күздә тотып, Х.Миңнегулов бу юнәлештә дә билгеле бер эшләр башкара. Галимнең «Коръән һәм татар әдәбияты», «Татарларда ислам дине» [(ул хәтта 2018 елгы «Татар мөселман календаре»на да кертелгән. – 186-204б.)] , «Ислам вә Татарстан» [«Mesag» журналы. 1977. – № 294. – 36-42s. (төрек телендә)], «Татарлык ислам белән көчле» һәм кайбер башка язмалары да укучыларга яхшы билгеле. 2004 елда нәшер ителгән «Ислам на Европейском Востоке» исемле «Энциклопедик сүзлек»тә профессорның дистәләгән мәкаләсе урнаштырылган.

Х.Миңнегуловның тормыш юлы, күпкырлы эшчәнлеге хакында 600гә якын мәкалә-язма дөнья күргән. Алар галимнең остазлары (Габдрахман Таһирҗанов, Шакир Абилов, Мансур Хәсәнов, Резеда Ганиева...), хезмәттәш-коллегалары (Гомәр Саттаров, Фоат Галимуллин, Марсель Бакиров, Хәләф Курбатов, Әнвәр Шәрипов, Флюра Сафиуллина, Флорид Әгъзәмов, Марсель Әхмәтҗанов, Рифгать Әхмәтҗанов, Әлфинә Сибгатуллина, Мидхәт Гайнуллин, Ханисә Алишина, Муса Мөлеков, Дамир Гарифуллин, Әлфәт Закирҗанов...), күп санлы шәкертләре (Таһир Гыйлаҗев, Фәнүзә

Нуриева, Рәшит Минһаҗ, Ләйсән Бәдретдинова, Фәридә Габидуллина, Рәҗәп Бәдретдинов...), әдип-шагыйрьләр (Рәдиф Гаташ, Батулла, Тәлгать Нәҗмиев, Ркаил Зәйдулла...), тарихчылар (Равил Әмирханов, Гамирҗан Дәүләтшин...), мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләре (Мөҗип Низамиев, Ландыш Шәйдуллина...), шулай ук башка мәмләкәт галимнәре (Бегали Косимов (Үзбәкстан), Күлбәк Ергобәк, Д.Кыдырали, Каербәк Кеменгер (Казакъстан), Сергей Исаков (Эстония), Окан Таһир (Финляндия), Чулпан Зариф (Төркия), Мортаза Зәйнетдинов (Таҗикстан) һәм башка билгеле затлар тарафыннан язылган.

Гомумән, профессор Х.Миңнегуловның эшчәнлеге күпкырлы, бай. Аның 1600гә якын язма-публикациянең авторы булуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Алар арасында 60ка якын китап (монография, дәреслек-әсбаплар...) бар. Әлеге хезмәтләр тематикалары белән гаять төрле. Бу кыска язма-белешмәдә галим эшчәнлегенең төп юнәлешләре, аерым тармаклары гына телгә алынды.

Хатыйп Йосыф углы күп санлы гыйльми дәрәҗәләргә, мактаулы исемнәргә ия. Ул – филология фәннәре докторы (1991), профессор (1992), Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе (1994, 2005), Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы (1996), Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1995)), «Халыкара ел кешесе» (Кембридж, 1998), Казан университетының «Атказанган профессоры» (2009), Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1996), Кол Гали (1998), Гаяз Исхакый (2005), Җәмал Вәлиди (2013), Сөббух Рәфыйков (2015), Һади Атласи (2017), Шиһабетдин Мәрҗани (2018) һәм кайбер башка төр премияләр лауреаты.

Редакциядән:

Журналыбызның могтәбәр авторы һәм хөрмәтле остазыбыз Хатыйп Йосыф углы Миңнегуловның 12 майда гомер бәйрәме – 80 яшь тула. Күренекле галимне олуг юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле хезмәтендә уңышлар теләп калабыз! ■

«ТАТМЕДИА» республика матбугат
һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
Татарстан китап нәшрияты,
«Безнең мирас» журналы редакциясе

ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

Конкурс **2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә.

Конкурска үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

Конкурста катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

Конкурска юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

ЯШЕЛ КАМИН ЯКТЫСЫ

5 апрельдә Татарстан Язучылар берлегенең мәшһүр яшел камины янында үзенчәлекле теле-видео тапшыру язылды. Шул рәвешле, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлеге «Яшел камин янында. Шәхесләребез» дип аталган уртак әдәби-мәгърифәти проект башлап җибәрде. Әлеге тапшырулар шәлкеме ТАССР төзелүгә – 100 һәм ТР Язучылар берлеге оешуга 85 ел тулу уңаеннан оештырыла.

Беренче тапшыру күренекле мәгърифәтче, галим, әдип, абруйлы дин әһеле вә җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддингә багышланды. Быел аның туувына – 160 ел. Килгән кунаклар бөек шәхеснең мирасын барлау, аны бүгенге көндә ни рәвешле киң җәмәгатьчелеккә җиткерү юллары хакында фикер алыштылар. Әңгәмәдә ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Хәзинә» газетасы баш мөхәррире Илшат Миңгәрәев, «Татнефть» карамагындагы «Рухият» хәйрия фонды нәшриятының җаваплы мөхәррире Рамил Миңнуллин, Әлмәт районының Кичүчат авылындагы Р.Фәхреддин музее мөдире, филология фәннәре кандидаты Диләрә Гыймранова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты.

12 апрельдә «Яшел камин янында. Шәхесләребез» тапшыруының икенче чыгарылышы язылды. Ул олуг шагыйрь һәм милләт иганәчесе Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев)

Автор фотолары

туунына 160 ел тулуга багышланды. Анда танылган язучы, гомере буе шагыйрьнең тормыш вә иҗат юлын өйрәнүче Лерон Хәмидуллин, күренекле шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Газинур Морат һәм Ркаил Зәйдулла катнашты.

Әлеге ике тапшыруда яңгыраган кайбер фикерләр:

Данил САЛИХОВ:

«Яшел каминга ут кабызмагансыз, дип бер дә аптырамагыз. Милли гамь утын-яктылыгын татар күңеленә салган бөек шәхесләребезне онытмау, барлау-олылау – ошбу очрашуларыбызның төп асыл мәгънәсе әнә шунда!»

Ләбиб ЛЕРОН:

«Тарихи шәхесләребез турында әдәби-документаль әсәрләр язуны көн тәртибенә кертәсе иде».

Диләрә ГЫЙМРАНОВА:

«Ризаэддин Фәхреддиннең мирасына баглы чараларны бер Әлмәттә яисә Казанда гына түгел, ә бәлки милләттәшләребез яшәгән һәр төбәктә үткәрү зарур. Татар өчен дә, һәммә төрки халыклар өчен дә, мөселман өммәтендәге һәркемгә дә газиз, мөхтәрәм булырлык затлы шәхес ул!»

Газинур МОРАТ:

«Башкалабыз Казанда Дәрдемәндкә һәйкәл булырга тиеш һәм аның да теләсә-нинди түгел, нәкъ менә Бакый Урманче ясап калдырганы булырга тиеш!»

Күренекле шәхесләребезгә багышланган тапшыруларны язу киләчәктә дә дәвам итәчәк һәм алар телевидение, социаль челтәрләр аша халыкка барып ирешәчәк. Тапшыруларның авторы һәм алып баручысы – шагыйрь һәм прозаик, ТР Язучылар берлегенең әдәби консультанты Марат Закир.

Аяз Закир

Безнең мирас №5 май 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



Владивосток шәһәре

КЫТАЙЛАРНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ТУРЫНДА

Шәһәрдә шул рәвешле бераз йөрдек. Сүз арасында Гомбо-Жаб кытайларның киләчәге турында болай диде: «Бүген җир шарында яшәү өзлексез алып барылган көрәштән гыйбарәт. Моннан соң инде кылыч сугышлары, ихтимал ки, бик дәвам итә алмас. Әгәр чират икътисади бәрелешләргә килсә, кытай милләтенең алга чыгачагы шөбһәсез. Боларда бөтен нәрсә икътисадка нигезләнгән. Шул сәбәпле, бу милләтнең киләчәге башка бөтен милләтләрдән дә яктырак».

ӘРМӘННӘРНЕҢ МИЛЛӘТЧЕЛЕГЕ

Бераздан Гомбо-Жаб җәнапларыннан аерылып, туп-туры кунакханәгә киттем. Бераз ял итәм дә, аннары чәй эчәрмен. Ул арада кунакханә хуҗасы килде. Кулына газета тоткан. Миңа:

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

– Сез бу газетаны укый алмассызмы икән? – дип мөрәҗәгать итте.

– Нинди газета бу?

– Әрмән газетасы.

– Сез әрмәнмени?

– Әйе, мин әрмән, тик монда тудым, монда үстем. Әрмән телен белмим.

– Бу газетаны кайдан алдыгыз? Кайда чыга?

– Кулымнан килгән кадәр бер ярдәм булсын, дип, акча җибәргән идем, ләкин, кызганыч, үзем укый алмыйм. Бу газета Кафказда чыга.

– Укый белмәгәч, нишлисез инде бу газета белән? Ни дип акча җибәрәсез инде?

– Аз булса да, милләткә файдам булсын. Максатым шул иде.

Менә милләтче шундый булырга тиеш! Безнекеләр исә, укый-яза белә торып, газетага акча бирүне гөнаһ дияр дәрәҗәдә юньсез эш дип саныйлар.

Мин әрмән язуының шәкелен генә беләм, ләкин укый алмыйм. Шулай булса да, газетаны кулыма алдым. Бераз караштырдым. Кайбер игъланнар рус телендә дә бирелгән иде, аларны күздән кичердем. Минем әрмән әңгәмәдәшемнең шуңа да күңеле булды.

Владивостокта японнар да бик күп. Ләкин алар күбесенчә сәнгать әһелләре һәм һөнәрчеләр, араларында зур капитал ияләре юк.

Биредә японнар турында да, кытайлар турында да язмаска уйлыйм, бары тик тиешле булганда, бер-ике сүз генә әйтеп үтәрмен.

15 ноябрьдә Владивостоктан китәргә дигән карарга килдем. Русларның «Добровольный флот» фирмасы пароходлары белән булса да юлга чыгарга әзерләндем. Бөтен кирәк-ярагымны әзерләдем, чөнки, гадәттә, диңгездә хәлем бик яхшы булмый. Боларны уйланып утырганда, Япония консуллыгы хезмәткәре килде. Безнең теге танышыбыз – Хиашита – күптәнге дуслар кебек: «Сезгә ярдәм итәргә дип килдем, Рәшит әфәнде», – дип, исемем белән эндәшеп, ишектән килеп керде. Мин дә бик канәгать булып каршы алдым: «Бик яхшы. Инде бар әйберем дә әзер. Иртәгә инде Русиядән китеп барачакмын», – дидем.

Хиашита миңа унлап адрес бирде: «Бу кешеләр белән очрашсагыз, алардан күп ярдәм күрә алырсыз», – диде. Шул арада кунакханә хезмәтчесе кулына телеграмма тотып керде. Телеграмма Хабаровскидан: «Сезне озатырга киләчәкбез. 16 ноябрьдә тимер юл станциясендә каршылагыз. Имзалар».

Моннан соң сәфәремнең вакытын күчерергә мәҗбүр булдым, бу кадәр дус 700 километр ераклыктагы җирдән мине озатыр өчен килә икән, ничек көтмәскә кирәк?!

Хиашита: «Мин бик шат. Инде болай булгач, безнең пароход белән китәчәксез. Ох, ох, бик кәефләндем», – дип, сөенечен белдерде.

Чынлап та, гаҗәеп яхшы очраклылык: димәк, 18 ноябрьдә китәчәк япон пароходын көтәчәкбез. 16 ноябрь көнне уллары белән Габделкадыйр Кәримов, Габдулла Виргазов, Виктор Бикаривичлар килде. Владивостокта иң зур кунакханәгә урнаштылар. Алар белән биредә тагын бик матур ике көн үткәрдем. Бу ике көн минем өчен тагын бер форсат булды, тагын берничә шәхес белән күрештем.

Бигрәк тә профессор Цыбиков белән кабат күрешү насыйп булды. Цыбиковның сөйләгәннәре буенча, Тибет һәм Һималай тауларыннан үтеп сәяхәт итүче чит ил кешеләре соңгы вакытларда шактый күбәйгән. Тик Будда диненең мәркәзе булган Әлхас яки Лас һәм Илхас дип аталган монастырьда булган борынгы әсәрләр һәм моннан 1600 ел элек төзелгән борынгы биналарның архитектура ягыннан нәфислеге бүгенге белгечләрне дә шаккатырырлык дәрәҗәдә сирәк күренеш булса да, ул сәяхәтчеләрнең һичбере боларны күрүгә ирешү һәм алар хакында мәгълүмат алу түгел, хәтта аларның булуын да белмиләр икән. Цыбиков үзе Будда динендәге кеше булганга, гаҗәеп

күп мәгълүмат алып кайткан. Менә шул Илхас-Әлхас монастырьларының һичбере шушы вакытка кадәр рәсемгә төшерелмәгән булган. Цыбиков моңа да ирешкән һәм башка бик күп рәсемнәр (җыеп әйткәндә, 200гә якын бик әһәмиятле рәсемнәр) алып кайткан.

Шул рәвешле, бу шәхес белән күрешеп мәгълүмат алу минем өчен дә искиткеч кирәкле булганга, мондый очраклылык белән кабат күрешә алуыма, дөресен генә әйтим, бик күңелем булды.

ВЛАДИВОСТОКТАН КИТҮ

1909 елның 18 ноябрендә Япониянең Хозан Мару исемле пароходы белән Русиядән китеп барачакмын. Мин – мәмләкәттән күп тапкырлар аерылып киткән, күп тапкырлар чит җирләргә юл тоткан кеше. Тик бу юлы, ни сәбәпледер, илдән аерылып китү мине бик нык уйланырга мәҗбүр итә иде. Мин инде яшь кеше түгел, шуңа күрә, тормыш дигән нәрсәнең һәр ике җәһәтен дә уйлау бик табигый. Потпәрәстлек мәмләкәтенә, көфер иленә китәм. Мөселман кешесен очрату ихтималы юк, тел белмим, акчам юк, таныган-белгән бер кешем дә юк – болар бик уйланырлык нәрсәләр. Хәтта тәкъдирдә язылган әҗәлем шул чит җирләрдә килә калса, үзем өчен түгел, илдә калган гаиләм, туган-тумачам, дус-ишләрем өчен никадәр борчулы хәл буласына кадәр һәммәсен берәм-берәм күңелемнән үткәрдем. Тик ни өчендер, белмим, йөрәгем бик тыныч һәм эчем сөенеч хисләре белән тулы иде. Күптәнге дусларым булган берничә зур кешене хәтта төшемдә дә күрдем. Себер халкының иң олы хәйриячесе, милләте өчен йөз-мең акчалар түгеп, бер тиенсез калганчыга кадәр «милләт, милләт...» дип тәкрарлап гомер итеп киткән мәрхүм Нигъмәтулла хаҗины берничә тапкыр төшемдә күргәнем булды. Бу юлы, Владивостоктан китәсе көнне дә бу мәрхүмне һәм бөтен тормышым буенча матди ярдәм күрсәтеп торган бөек затлардан Насретдин хаҗи, Гани бай Хөсәенев, Хәбибулла Акболакларны, болардан тыш тагын Шәех Җәмалетдин әл-Әфгани, Хәсән Хөсни әт-Тавирани кебек бөек шәхесләрне төштә күреп, йөрәгемдә рух ныклыгы хасил булды. Мин ихтирам иткән, ләкин шәхсән таныш булмаган күп кенә бөек кешеләрнең, зур галимнәрнең – алар арасында атам да бар – мине пароходка озатырга килгәннәрен [төштә] күреп, эшемнең уң буласына ышанычым артты.

Алда әйтеп үтелгән көндә, сәгать 11дә пароходка утырдым. Ун минутлап вакыт үтүгә, дустыбыз Хиашита килде һәм мине яхшы каютага урнаштырды. Биредә танышкан кешеләрем, Хабаровскидан килгән дусларым барысы да пароходка ук кергәннәр иде. Ял итү залында бер ярты сәгатьләп алар белән сөйләшеп утырдык. Пароход кузгалып китәргә әзерләнә. «Юлчыларны озата килгән кешеләрнең пароходтан чыгуларын үтенәбез», – дигән белдерү булды. Озатыр өчен килгәннәр пароходтан чыктылар. Шунда ук пароход кузгалып та китте. Юлчыларның пароходка керә башлаулары белән пароходның кузгалып китүе арасында ярты сәгатьләп вакыт үткәндер. Ни пароходка кергәндә, ни пароход кузгалып киткәндә – ник бер жандарм кешесе, ник бер полиция кешесе булсын, ник бер: «Син кем, кая барасың, паспортың кайда?» – дип сораучы булсын?! Борчу салучы берни дә күрмәгәнемә аптырап калдым. Без Одессадан Истанбулга кузгалып китәргә торганда, кулыбызда паспортыбыз була торып, никадәр кимсетүләр күрә һәм шуңа түзә идек. Госманлы консулы килә – виза тикшерә, жандарм килә – тикшерү уздыра, полиция кешесе килә – белмим, ниләр тикшерә, гражданский полиция кешесе инде пароход кузгалырга торганда иң соңгы тикшерүдән уздыра торган иде. Бу хәлләрне кырык тапкыр күргән, кичергән кешенең, мондый мөнәсәбәтне күреп, әлбәттә, аптырашта калмый хәле юк.

Япон пароходы «Хозан Мару»

Пароход причалдан кузгалып китәргә торганда, полиция комиссары килде. Шулвакыт баскычта басып торган бер егет комиссарның кулына бер кәгазь сузды. Кәгазьдә юлчыларның паспорт мәгълүматлары язылган була икән. Сәгать кылт 12: «Хозан Мару» причалдан кузгалып китте. Ярдагылар пароходтагы якыннары белән саубуллашканда, шуңа игътибар иттем: кул кысышулар да, үбешүләр дә, елашулар да, кулъяулык болгаулар да – берсе дә булмады. Юлчылар арасында дәрәҗәле япон гаиләләре дә, боларны озатырга килгән чибәр ханымнар да бар иде. Барысы да вәкарьле мөлаем елмаю, иелеп хөрмәт күрсәтү белән чикләнде.

«Хозан Мару» причалдан еракლаша бара. Юлчыларның күбесе бинокль белән тирә-юньне күзәтә иде. Порт ап-ак боз эчендә калды, кырыйдан караганда, пароходлар да боз өстеннән китеп бара кебек. Шәһәр искиткеч манзара эчендә: биек таулар арасында ак карлар белән әйләндереп алынган биек биналар, тау башларында авызын ачып ажгырган аждаһа кебек торган пушкалар, чыбыксыз телеграф баганалары, барысы да фән җимеше булган, дәһшәт хис иттерә торган бастион-ныгытмалар. Каяндыр гаскәри быргы тавышлары ишетелә. Болар барысы да кешенең йөрәген дәһшәт белән тутыра, гүя хәтта солых һәм тынычлык елларында да кешегә: «Һич ышанма!» – дип кабатлап тора; йөз-меңнәрчә тере җаннарны бер мизгел эчендә юкка чыгару өчен әзер торган көчләрнең булуын күрсәтеп, искәртеп тора иде.

«Хозан Мару» бозлар арасыннан алга бара, өч сәгатькә якын юл үткәннән соң, ачык диңгезгә керергә әзерләнде. Сәгать кылт 4 иде, пароход кычкырта башлады. «Нәрсә булды? Нәрсә бар?» – дип чыккан идек, күрдек: ярдан килгән бер каек пароходка таба якыная. Пароходтан бер кеше төшеп, каекка утырды. «Бу нәрсә икән инде?» – дип сорадым. Портның махсус хезмәткәре, пароход киткәндә, аны шушы тирәләргә кадәр озата, килгәндә дә, шушы урынга кадәр килеп каршы ала икән.

Пароход әле порттан ераклашканчы ук, матрослар амбарларны яхшылап бикләделәр, пароход палубасын чиста итеп юдылар. Шуннан соң болар бер ярты

сәгать-бер сәгать тирәсе күздән югалып тордылар. Матрослар бераздан берәмсәрәм чыгып, пароходтагы әфәнделәр арасына кушылдылар. Кулларында китап яки газета иде. Палуба китапханәнең уку залын хәтерләтә башлады. Юлчылар алай күп түгел, каюта юлчылары бигрәк тә аз. Шулай булуга да карамастан, рус, инглиз, татар, япон, грузин, осетин кебек төрле милләт кешеләре бар иде.

Сәгать дүрт тирәләрендә Аскольд[1] утраулары янынннан үттек, бераздан юлчыларны ашарга чакырдылар. Табын янына утырмаган идек әле, баш капитан килде, үзен юлчыларга танытып, һәр хезмәткә әзер булуларын белдерде. Табын янына килдек. Барлык юлчылар утырганнан соң, баш капитан, бик мөлаем елмаеп, кирәк булса, тәрҗемәче дә була алачагын әйтте. Япон, рус телләрен генә түгел, инглиз телен дә белә икән. Шул рәвешле, беренче тапкыр аш табыны янында җыелдык.

Без, бер рус кешесе белән бергә, үз җаһиллегебездән зарланып утырабыз, икебез дә чит тел белмибез. Рус юлдашым миңа кызыгып карый: китаплардан өйрәнгән бер-ике сүз белән теләгәнемне әйтергә маташканымны күреп, ул мине япон телен белә, дип уйлый иде. Мин бертуктамый, көне-төне дип әйтерлек, тәрҗемә китаплары укыйм, кирәкле дип тапкан сүзләрне яттан өйрәнергә тырыша идем.

РӘСЕМНӘРЕМ

Бу урында минем бик күп санлы, бик кызыклы рәсемнәрем булырга тиеш иде. Ләкин Русия почтасының эш тәртибе укучыларымны бу рәсемнәрдән мәхрүм итте. Мин рәсемнәремне бөтен җирдән Казанга, балаларыма җибәреп бардым, чөнки янымда болай да әйбер аз түгел иде.

Русия почтасы аларның күбесен урлаган булып чыкты. Бигрәк тә Владивосток порты бөтен якларыннан фоторәсемгә төшерелгән иде. Боз өстеннән портка якынлашкан пароходлар, порттан чыгып барган пароходлар, бастион-ныгытмалар – барысының да рәсемнәре бар иде һәм алар барысы да почтада югалган булып чыкты.

ПАРОХОДМЫ, КИТАПХАНӘМЕ?

«Хозан Мару» 12 мил[2] юл үткәннән соң, пароходта матрос, юлчы аермасы калмады. Бөтен матрослар әфәндегә әйләнде һәм белем арттыру эшенә чумды. Пароходыбыз шунда ук китапханәгә әйләнде дә куйды. Пароходның кайсы ягына карама – бөтен җирдә караватка сузылып яткан һәм кулына йә китап, йә газета тотып, күңелен укуга биргән кешеләрне күрәсең. Америкага китеп баручы берничә рус эшчесе бар иде. Бары тик болар гына, укый-яза белмәү сәбәпле, берни дә укымыйлар, гел сузылып яталар иде. Ә японнар вакытларын китап укып үткәрделәр.

Хәтта буфетта хезмәт күрсәтүче ашчылар, официантлар да гел китап укый иде. Пароходның капитаны, ара-тирә килеп, юлчыларның хәлләрен сорашып китә, берәр нәрсә кирәк булса, үзенә әйтүләрен үтенә иде.

Шул рәвешле, минем китапханәм дә диңгез өстендә нәкъ 40 сәгать дәвам итте. Биредә мин күргән кешелекле мөгамәлә шулкадәр күңелемә хуш килде ки: алар турында сөйләп бетерерлек түгел.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

[1] Аскольд утравы бүгенге көндә шул тирәдәге иң биек, иң зур, торак урыннары булмаган һәм тулы изоляциядә яшәгән бердәнбер утрау булып санала. Иң кыска, иң туры юлдан санаганда, материктан 6,6 км ераклыкта урнашкан (тәрҗ. иск.).

[2] Диңгез миле 1852 метр тәшкил итә (тәрҗ. иск.).

Безнең мирас №5 май 2019

ӘГӘР ФАИЛ ИСӘН БУЛСА...

Эльмира Шәрифуллина

Язучы Фаил Шәфигуллинга, исән булса, быел 18 майда 80 яшь тулыр иде. Ләкин ул моннан 37 ел элек фаҗигале төстә вафат булды.

Фаил Шәфигуллин 1969 елда СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды. Диңгездән кайтып (1962) яшәгән һәм яза башлаган унбиш-егерме ел аралыгында тугыз китабын чыгарды. Тарих өчен аларны теркәп куйыйк әле: «Яңа ел бусагасында» (Шигырьләр, 1967); «Авылым сандугачы» (Хикәяләр, 1968); «Гашыйк» (Шигырьләр,1969); «Каен як-

тысы» (Хикәяләр,1972); «Әлфинур» (Повесть һәм хикәяләр, 1976); «Дулкынга дулкын» (Шигырьләр, 1977); «Күзгә карап» (Юмористик хикәяләр, 1979); «Ак яллы аргамаклар» (Повесть, хикәяләр, 1980); «Бәхет йолдызы астында» (Повесть, 1982). Саналган китапларның гомуми тиражы 78000 данәне тәшкил итә. «Снег на голову» (Юмористические рассказы, 1983) исемендәге унынчы китабын, үзе төзесә дә, кулына тотып карый алмады. Әмма «массовый» дип аталган 50000 тираж белән чыгасын белә иде.

Фаил вафат булды, ләкин язучылык миссиясе тукталмады, аның бүгенге көнгә кадәр тагын тугыз китабы дөнья күрде. Алар: «Ак маңгайлы бүреләр» (повесть, хикәяләр һәм әдәби-музыкаль монтажлар, 1985); «Кешелек тавы» (повесть, хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, очерклар, 1988); «Өй салуның ние бар?» (повестьлар, 1991); «Бер атуда ике куян» (юмористик хикәяләр, 1999); «Бер малай, өч аргамак» (повестьлар, хикәяләр, 2005); «Тальян гармун» (повесть, хикәяләр, 2011); «Сагынырлар әле безне таулар» (әсәрләре, истәлекләр, 2014); «Яшьлегем тугае» (шигырьләр, 2014). Әле саналган китапларның кайберләрен төзергә, җыярга кызларым һәм оныкларым да ярдәм итте. Ә 2002 елда латин графикасында дөнья күргән «Тау битендә күләгә» исемле хикәяләр җыентыгының төзүчесе дә, редакторы да Нурзидә Нотфуллина булды. «Мәгариф» нәшрияты, латин графикасында йөгерек уку күнекмәләрен камилләштерү максатыннан, «Мәгарә» сериясеннән китаплар чыгаруны дәвам итә. Әлеге сериядән үзенчәлекле рәвештә тәкъдим ителгән II китапка классик әдип Фаил Шәфигуллин хикәяләре тупланды», – дип язган иде ул аның аннотациясенә.

Боларының гомуми тиражы – 54700. Җәмгысы: 182700 данә. Унтугызынчы һәм егерменче китаплары – Татарстан китап нәшрияты папкасында.

Фаил, гомумән, китапларның ничә данәдә чыгуына бик игътибар итә иде. Шуңа күрә мин дә аларны исәпләргә булдым. Аерма, күргәнебезчә, күзгә бәрелеп тора.

Фаил Шәфигуллинның төрле газета-журналларда сибелеп калган мирасын җыю, билгеле, җиңел булмады. Аның өчен, мәсәлән, «Ватаным Татарстан» («Социалистик Татарстан») кебек күләмле авыр тупламаларны күтәреп машинисткаларга илтү яки һәр мәкалә һәм очеркын кулдан күчереп алып, кабат бастырырга кирәк булды. Чөнки Фаил бигрәк тә публицистикасын җыеп бармаган иде. Әдәби әсәрләренең дә төрле язмышлылары бар. Язучылар берлегендә чыгарылып килгән стена газетасы «Тынгысыз каләм» битләрендә сакланып калганнары да, Татарстан радиосы фондыннан миңа тапшырылганнары да һ.б. Мәсәлән, 2005 елда «Бер малай, өч аргамак» китабында беренче тапкыр басылган «Кызыл мәрмәр» исемле хикәсен очраклы рәвештә таптым. Бу хикәя белән 1980 елда «Яшь ленинчы» газетасы үткәргән ябык конкурста катнашкан булган икән. «Үр менгәндә» хикәясе дә шулай соңлап табылды.

Шунысы һәркемгә мәгълүм – Фаил бик эшчән-тырыш кеше иде. Моны аның китапларына язылган рецензияләр дә исбатлап тора. Шуларның берсен сезгә дә, хөрмәтле укучым, тәкъдим итәм. Ул – Рафаэль абый Мостафин язган бәяләмә. Аннан соң бу документлар китапларның ул елларда нинди катлаулы, озын, әмма җаваплы юл үтүе, җиде кат иләктән иләнеп эшләнүе турында да сөйли бит әле.

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ «КЕШЕЛЕК ТАВЫ» ИСЕМЛЕ КУЛЬЯЗМАСЫНА ЭЧКЕ РЕЦЕНЗИЯ

Төзүчесе – Э.Шәрифуллина. 323 бит.

«Э.Шәрифуллина бик зур эш башкарган. Ф.Шәфигуллинның матбугатта чыккан мәкалә, рецензия, очерк, парча һәм башка төрле бик күп әсәрләрен җыеп, машинкада бастырып, бергә туплаган. Бу материаллар буенча Фаил Шәфигуллинның төрле өлкәдә – әдәби тәнкыйть, очерк-публицистика, журналистика һ.б. бик актив эшләгәнен күрәсең. Мин, мәсәлән, моңача да аның вакытлы матбугат битләрендә басылган әсәрләрен күргәләп килә идем. Ләкин бу җыентыкны укыгач, аның шулкадәр эшләгән булуына таң калдым, аңа булган ихтирамым бермә-бер артты.

Тик, кызганычка каршы, Ф.Шәфигуллинның күпчелек әсәрләре журналистик рухта язылган. Бу әле начар дигән сүз түгел, әлбәттә. Аның материаллары барысы да диярлек матур, җанлы тел белән, образлы һәм үтемле итеп язылган, алар җиңел укыла, файдалы фикерләр үткәрелә. Тик алар бик тыгыз рәвештә конкрет бер момент: яңа чыккан китап, берәр кампания, конкурс, күргәзмә яисә башка шуның ише агымдагы вакыйгалар белән бәйләнгән. Алар барысы да үз вакытында һәм үз урынында яхшы һәм файдалы булып яңгыраган. Әмма китап итеп күз алдына китерә башласаң, яңа таләпләргә җавап биреп бетермиләр, күбесе инде искергән булып чыга.

Остазлар-каләмдәшләр белән. Беренче рәттә сулдан: Нури Арслан, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев; икенче рәттә сулдан икенче Фаил Шәфигуллин, Саимә Ибраһимова (дүртенче), Рафаэль Мостафин (бишенче), Ләбибә Ихсанова (җиденче), Фәрваз Миңнуллин, Яхъя Халитов. 1970 нче еллар ахыры



Фаил Шәфигуллин каләмдәшләре Зөлфәт һәм Рафаэль Мостафин белән. 1970 нче еллар ахыры

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Ф.Шәфигуллин тәнкыйтьче булып түгел, хикәяче буларак дан казанды. Күпчелек материаллары кыска рецензия-аннотация яисә юбилей уңае белән котлау формасында язылган. Вакыт узу белән аларның әһәмияте дә югалган. Тәнкыйть материалларыннан төзелгән аерым бер җыентык итеп бастырырлык материал кулъязмада юк.

Шулай да кайбер язмалары әлегәчә үз әһәмиятен югалтып бетермәгән. Тик аларны, минемчә, мәкалә-рецензия итеп түгел, язучының әдәбият яисә язучы-дуслары турында уйлану-парчалар формасында бастыру дөресрәк булыр. Аларның күпчелеген балалар өчен язылган булуын истә тотып, аларны аерым китап итеп түгел, ә бәлки балалар өчен язылган хикәяләр китабына аерым бүлек итеп кертергә кирәктер. Әһәмиятен югалтып бетермәгән һәм китапка кертергә мөмкин булган мәкаләләр:

1. «Кешелек тавына күтәрелгәндә». Мәкалә 1980 елгы балалар әдәбиятына обзор характерында язылган булса да, аны бераз кыскартып һәм редакцияләп, әдәбият турында уйланулар формасында бирергә була.

2. «Йөрәктәге эзләр». Китап күзлегеннән караганда сайрак язылган булса да, язучының үз коллегасына карашын ачыклау өчен мөһим булган мәкалә. Юбилей уңае белән язылган булуын кыскартып, төшереп калдырырга мөмкин.

3. Кечкенә рецензияләр (Ш.Галиевнең яңа китабына рецензия). Рецензия характерында язылган урыннарын кыскартып, уйлану итеп бирергә була.

4. «Якты нур» (кыскарта төшеп һәм редакцияләп).

5. «Болынга бетон җәйгәндә» (шулай ук шактый кыскартып).

6. «Ялыкмас юлчы».

7. «Таң җилләренә ияреп». Бу материалга М.Хуҗинга 50 яшь тулу уңае белән язылган мәкаләдән кайбер абзацларны да өстәргә була (51 б.).

8. «Бәхет орлыклары мул уңыш бирә».

9. «Күңелдәге язулар» (икесенең дә юбилей уңае белән язылган булуларын төшереп калдырырга кирәк булыр).

10. «Көлеп моңая» (Афзал турында язылган башка материаллары белән берләштерергә була: 954. 109, 149 б.б.).

11. «Җиткерермен җитмешне!»

12. «Ак җилкәннәр корып» (фактик өлешен кыскарта төшеп, язучының А.Гринга булган мөнәсәбәтен күрсәткән урыннарны гына калдырырга кирәк булыр).

13. «Илсөярне ил сөя».

14. «Кече күңелле өлкән дустыбыз» (бу парча И.Туктар исән чакта язылган, бераз редакцияләргә туры килер).

Калган материаллар йә фактик яктан искергән, йә фикер бик сай, йә китап өчен әллә ни әһәмиятле түгел. Шуңа күрә, минемчә, аларны китапка кертеп булмый.

Сәнгать турында парчалар.

1. «Театр ишеге төбендә» (инсценировка).

2. «Якташыбыз Эрьзя».

3. «Күңеленә Идел сыйган».

4. «Каен җиләге».

5. Кояшлы хезмәт турында җыр.

6. «Туган як моңнары».

7. «Өзлексез әйләнеш».

Бу парчалар үзләре бер бүлек тәшкил итәчәк, аларга иллюстрация рәвешендә рәсемнәр, фотолар да бирелсә, тагы да әйбәтрәк булыр иде.

Очерк, публицистика, тормыш һәм тәрбия турында уйланулар.

1. «Мәңгелеккә» (беренче бит һәм шигъри юллар).

2. «Әрәмәлек патшасы».

3. «Яшьлегеңдә күп тырышсаң». Беренче яртысы бик матур язылган. Икенче яртысында китерелгән фактлар искергән, хәтта геройлары да үлгән булуы ихтимал. Ләкин Э.Шәрифуллина очерк эзеннән барып барысын да ачыкласа, ниндидер искәрмәләр бирсә, басарга була. Бу – башка очеркларга да карый.

4. «Хөрмәтле кеше». Матур очерк. Ләкин искәрмә кирәк, искергән булуы ихтимал.

5. «Дәшә китап серле дөньяга». Публицистик язма итеп калдырырга мөмкин. «Балалар китабы атналыгы» (1982 ел) уңае белән язылган урыннары искергән.

6. «Куркак булу җиңелме?»

7. «Яңа ел бүләге».

8. «Хыяллар тормышка ашканда» (балаларга төбәп язылган публицистика).

9. «Урман һәркемгә ышана».

10. «Һәммәсе дә безнеке».

11. «Аксакал» (тик башта тикшерергә кирәк).

12. «Туган җир – туган ана».

13. «Киләчәк белән ялкынланып».

14. «Ул бит Майорова». Матур язылган, ул кешене мин дә беләм. Тик очеркның кайбер моментлары искергән. Мәсәлән, Нинаның ире алкоголикка әйләнә, ул аның белән аерылышырга мәҗбүр була.

15. «Топольләр шаулый» (әгәр төп герое исән булса).

Шулай итеп, барысы бергә 4-5 табак күләмендәге бер китап итеп тә (балаларга төбәп) бастырып чыгарырга була. Ләкин, минемчә, хикәяләр китабына өстәп бирелсә, матур һәм шактый тулы, башкалар тарафыннан яратып укыла торган бер том булачак».

Рафаэль Мостафин

Фаил Шәфигуллин һәм Эльмира Шәрифуллина кызлары Резеда белән Рица күле янында.
1982 елның октябре

Әлеге «Кешелек тавы» дип исемләнгән китапның редакторы Харрас Әюпов булды. Ул, китапның укучы күңелен җәлеп итәрлек булып чыгуы өчен, бу эшкә җаваплы килде. Дәлил рәвешендә эш барышындагы берничә хатны китерәм.

«Эльмира!

Мин Фаилнең китабын карый башлаган идем. Кайбер киңәшәсе әйберләр бар. Алдагы атнада бер вакыт табып кереп чыксаң иде.

Сәлам белән, Харрас (Әюпов. – Э.Ш.). 05.06. 87».

«Эльмира!

Күптин-күп сәламнәр сиңа вә кызларыңа.

Бүген Харрас Әюповтан хат килеп төште. Фаилнең җыентыгын редакцияләү аңа кушылган, ахрысы.

Ул язган: «Җыентыкка сүз башы («кереш мәкалә») язмассыңмы», – дигән. «Язармын», – дип аңа хат яздым. Ләкин минем сүз башы озын булмас – машинкада 3-4 бит. Теге рецензия нигезендә булыр кебек. Вакыт табып, син Харраска кереп чык әле. Минем өчен рецензияне һәм кульязманы ал. Язганда кульязма да кирәк бит. Истә калган буенча гына язып булмый. Кайчанга өлгертергә кирәклеген дә сора.

Сәлам белән: Нурихан абый дип белерсең. 3 июнь, 1987 ел, Казан.
Почтилчикның индексын язып җибәр әле берәр».

«Эльмира!

Безнең эшләр ахырга якынлашып килә. Кулъязманы машинкага тапшырдым. Сиңа үтенеч: шул өч әйберне ачыклыйсы иде.

1. «Ленин байрагы» газетасы кайда чыга? («Яңа елның яңа туны» шунда басылган).
2. «Хикмәтле китап» исемле мәкалә кайда басылган?
3. «Кече күңелле өлкән дустыбыз» исемле мәкалә кайда басылган?

Калганнары ачыкланды кебек.

Сәлам белән, Харрас. 11.08.87».

«Ак маңгайлы бүреләр» һәм «Кешелек тавы»ннан соң, «Өй салуның ние бар?» китабын төзедем. Ләкин бу китап, алдагыларыннан аермалы буларак, төзүчесе күрсәтелмичә нәшер ителде. Юкса, монысын да, редактор буларак, Харрас Әюпов эшләде.

Мин инде «Сыерчык бураны» повесте «Кешелек тавы» җыентыгына кергәч, монысына да кертү дөрес булмас, дип уйлаган идем. Редактор барлык повестьларын бергә туплап бирүне кирәк тапты. Бу, билгеле, бик дөрес гамәл булды. Редакторның минә бу хаты шуны исбатлап тора.

«Эльмира!

«Кешелек тавы» китабыннан «Сыерчык бураннары» повестен әзерләп китерсәң иде Фаилнең. Ябыштырып.

Сәлам белән, Харрас. 09.04.90.
420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Таткнигоиздат. Аюпову Х.»

«Өй салуның ние бар?» поветеның икенче кисәге минем өчен аеруча кадерле. Ул аны 1982 елның сентябрь аенда, язучыларның Абхазиядәге «Пицунда» иҗат йортында язды. Без анда өчәү: дүрт яшьлек кызыбыз Резеда белән барган идек. Диңгездә коендык,

яхшылап ял иттек. Тик, кайтып ундүрт көн үтүгә, Фаил бакыйлыкка күчте. Повесть каралама хәлендә калды. Җөмлә эчендәге кайбер сүзләрнең бер яки ике-өч хәрефе генә куеп кителгән урыннары да күп иде. Фаилнең почеркын яхшы белгән, моңа кадәр аның әсәрләрен күп мәртәбәләр баскан «Чаян» журналы машинисткасы Фәния Хафизова ярдәмгә килде. Фәния белән икәү, төртелеп калган урыннарны кат-кат укый-укый, ниһаять, ерып чыктык. Мин аны «Казан утлары» журналына бирдем. Повесть 1984 елның 5 нче санында басылды. Әсәрне укучы яхшы кабул итте. Язучы Нурихан Фәттах «Социалистик Татарстан» газетасының 1984 елгы 4 нче ноябрь санында «Соң булса да» дигән мәкалә белән чыкты. Фаил Шәфигуллинның иҗатын югары бәяләп: «Өй салуның ние бар» повестеның икенче кисәген бернинди шикләнүсез роман, (тәмамланмаган роман) дип әйтергә була», – дип язды.

– Фаил сюжет һәм конфликт остасы да. Аның бер генә әсәре дә килде-китте сүз уйнатуга яисә сүлпән генә сагыз чәйнәүгә нигезләнмәгән. Фаилнең күп кенә хикәяләре, повестьлары сюжет, конфликт җәһәтеннән бик күпләргә, бигрәк тә яшь прозаикларга иң яхшы үрнәк хезмәтен үти ала./.../ Әгәр дә мәгәр көтмәгәндә һәлак булмаса, ул әле безнең һәммәбезне таң калдырырлык әсәрләр иҗат итәр иде. /.../

Үлгәннәр, гадәттә, тиз онытыла. Ләкин Фаил Шәфигуллин онытылмаска тиеш. Аны онытмау өчен, беренче чиратта, әлбәттә, ул язган әсәрләрнең тулы җыентыгын чыгарырга кирәк. Арабыздан вакытсыз киткән каләмдәшебез иҗаты игътибар һәм кадер-хөрмәткә тулысынча лаек».

Томлыкларын чыгару уе Фаил арабыздан киткәч үк туган иде. 1984 елда, ягъни тууына 45 ел тулган вакытта чыгарып булмас микән, дип, язучы Камил Кәримов белән бергә әсәрләрен өч томга бүлеп, тулы исемлеген төзеп, ул вакыттагы нәшрият директоры Гәрәф абый Шәрәфетдиновка хат юлладык. Аннан 50, 60 еллыкларында да шушы ук мәсьәләне кузгатып карадым. Беренче Президентыбызга да мөрәҗәгать иттем. Тик томлыкларын чыгару бәхетенә ирешә алмадым. Ә менә Фаилнең сәхнә теле белән сөйләшүче геройларын сәхнәгә меңгерү уем барып чыкты.

Сезнең хозурга сәнгать белгече Ильтани Илялова мәкаләсеннән бер өзек китерәм:

«ӨЙ САЛУНЫҢ НИЕ БАР...»

«Арабыздан вакытсыз китеп барган язучы Фаил Шәфигуллин үзеннән соң шактый зур әдәби мирас калдырды. Арада күп санлы шигырьләр, җырлар, юмористик һәм сатирик хикяләр, повестьлар, мәкалә-истәлекләр бар. «Өй салуның ние бар» повесте язучы иҗатында аерым бер урын алып тора. Яшәү мәгънәсе, ир-егетнең тормыштагы урыны, мәхәббәт газаплары – бу әсәр әнә шулар хакында уйлануга нигезләнгән./.../

Минзәлә татар дәүләт драма театры әлеге әсәрне, сәхнәләштереп, тамашачыларга күрсәтә башлады. Аның инсценировкасын мәрхүм язучының тормыш иптәше – язучы Эльмира Шәрифуллина эшләгән. Сәхнәгә режиссер Фаил Ибраһимов куйган./.../

«Социалистик Татарстан», 1990 ел, 7 гыйнвар. ■

Безнең мирас №5 май 2019

СУГЫШТА ҖИҢЕП КАЙТКАН ӘТИЕМ

Рауза Хуҗахмәтова

Әтием миңа беркайчан да сугыш турында сөйләмәде. Беркайчан да! Гаиләбездә мин иң кечкенәсе идем. Сугыш турында мин абый-апамнардан ишетеп белдем. Минем булачак әтием, аның әти-әнисе һәм абый-сеңелләре сугышка кадәр Мәскәүдә яшәгән. Тату гаилә. Яшьлек. Спортка тартылу. Кара диңгез флотында хезмәт итү. Физкультура институтында уку. Һәм, кинәт, бөтенесе дә – чәлпәрәмә! Башта әтиемнең әтисен алып китәләр. Бүтән аны күрергә насыйп булмый. Бераздан әтинең үзен дә кулга алалар. Гомеренең биш елы төньякта уза. Өйгә кайтуга, сугыш башлана.

Элекке кызыл флотчы диңгез сугышларында катнаша: башта – Севастопольдә, аннары Сталинград янындагы бәрелешләрдә. Сталинград янында ул чак кына суга батмыйча кала. Ярдәм көтеп, аңа өч тәүлек буе судан чыкмыйча торырга туры килә. Аннан соң ул совет поляр җирләрен азат итүдә катнаша. Авыр булдымы икән аңа? Куркыныч булдымы икән? Җиңел булмагандыр. Бу турыда хәзер аның хәрби бүләкләре генә сөйли ала.

Тыныч күк. Гаилә. Бер ул һәм биш кыз бала. Без үсеп җиттек тә, таралыштык. Әти без кайтканны көтеп, сөенеп каршы ала иде. Очрашкан вакытларыбызда ул безгә: «Йөз ел яшәячәкмен әле», – дип әйтеп килде. Беребез дә аны карт итеп күз алдына китермәде. Әтиебез бик таза иде. Тик соңыннан, әтиемнең көндәлеген укыгач кына, мин аның башыннан ниләр кичкәнен, йөрәге авыртканын, нинди газапларга тап булып та, алардан исән калуын, шәфкатьлелеген югалтмавын белдем. Дөньяга шатлыклы күзләр белән карап яшәде ул.

Мин туганда әти кырык сигез яшьтә булган.

Авыр вакытларда гел әтиемне хәтергә төшерәм: ул чыдам булган, мин дә бирешмәскә тиеш! Шатлыклы чакларымда да аны һәрвакыт искә алам: андый мизгелләрдә ул: «Егет икәнсең!» – дип әйтер, минем белән бергә куаныр иде кебек.

Тугызынчы май көнне күзләремә яшьләр тула. Әтием исән чагында аңа күп яхшылык эшләргә теләдем, әмма аны сөендерерлек әллә ни игелекләр кыла алмадым. Көн саен шылтыратып, аның хәл-әхвәлен белешеп торасы калган икән, дим хәзер, ә мин алай итмәдем. Тагын бер тапкыр әтимне кочаклыйсым калган, дим. Тагын бер мәртәбә аның белән бергә шахмат уйныйсым калган... Булмады... Гафу ит, әтием! Кичерә күр...

Мингалим Хуҗахмәтовны Димитровградта (элекке Мәләкәстә) гомер итүче өлкән буын яхшы хәтерли булыр. Әти ачык йөзле, изге күңелле, шат кеше иде. Әңгәмәдәше белән сөйләшкәндә, дәртләнеп китеп, бик озаклап гәп корып утырыр иде.

Кызыл флотчы Мингалим Хуҗахмәтов. 1934 ел

Татарстанның Әлки районы егете Мингалим Хуҗахмәтовның сугыш вакытында төшкән фотосы

Сулдан беренче – Мингалим Хуҗахмәтов. 1942 ел

Мингалим Хуҗахмәтов гаиләсе белән. Ангарск шәһәре, (Иркутск өлкәсе). 1957 ел

Яшь вакытында әтигә «Кызыл Кавказ» крейсерында хезмәт итәргә туры килгән. Үзе күргән, үз башыннан кичкән хәл-вакыйгалар турында сөйләгәндә аның йөзе балкып торыр иде. Ул кабат күрергә теләгән Севастопольгә минем дә бик барасым килде. Әти Төркиядә, Грециядә һәм Италиядә булган. Бу хакта ул горурланып сөйли иде.

Әтиемә сугыш вакытында да Севастополь өчен барган хәлиткеч бәрелешләрдә катнашырга туры килә. Кораблары баткач, катерда сугышчыларга кораллар һәм азык-төлек ташый ул. Сталинград өчен барган төнге сугышларда да катнаша. Кыскасы, әти чын мәгънәсендә утны-суны кичә: утка керә, суга бата, ярый әле аны вакытында коткарып өлгерәләр...

Сугыштан соң тыныч тормышка җайлашырга, гаиләсен көйләргә кирәк була әтигә. Ни әйтсәң дә, зур гаилә бит, алты бала, барысын да аякка бастырырга кирәк.

Күпме сынаулар үтеп тә, сыгылып-бөгелеп төшмәде ул. Тормыш авырлыгыннан беркайчан да зарланмады. Кешеләрдән үзенә берни сорамады, түрәләргә ялынмады, әмма башкаларга бик теләп булыша иде. Әдәби китаплар укырга яратты. Өйгә «Советский спорт» газетасын, «Огонек», «Вокруг света», «Казан утлары» һәм «Чаян» журналларын алдыра иде. Театр белән кызыксынды: драма түгәрәгенә йөрде, җырларга яратты, бихисап концертларда һәм спектакльләрдә катнашты. Кечкенә балаларны бик яратты, оныкларын көтеп алды. Оныклары үсеп җитеп, зур кешеләр булды инде. Кызганыч, әти аларның үзе шикелле яхшы ир-егетләр булып җитлеккәнен күрә алмады... ■

ИСКЕ МОСТЯК ХАТИРӘЛӘРЕ

Коллегаларым арасында, Ульяновск өлкәсенең Кулаткы районы хакында сүз чыккан-да, күңелемдә һәрвакыт бер хатирә яңара:

1984 елның җәе. Казан дәүләт педагогика институтының татар филологиясе факультетын тәмамлап, кулга шул вакыт таләпләре буенча юллама тотып, әлеге район үзәгенә бер үк төркемдә укыган Фәрит дустым Абдуллаҗанов (Аллаһның рәхмәтендә булсын) белән килеп төштек. Интернет заманы түгел, кая, ничек барасыбызны да чамалап кына юлга чыктык. Бер яктан караганда, Ульяновск өлкәсе – безнең авылның «ындыр башында» гына, авыл яшьләре дә, мәктәпне тәмамлагач, нигездә, шунда китеп эшкә урнаша. Әлеге төбәккә юллама биргәндә ВУЗ җитәкчеләре анда татар авыллары бар икәнлеген тәгаенләделәр дә, милли кадрлар җитмәү сәбәпле, шул авылларның берсенә татар теле һәм әдәбияты укытучылары буларак баруга ризалык алдылар.

Әлбәттә, без дөнья күрмәгән егетләр түгел, институтта 5 ел уку чорында фольклор экспедициясендә Себер-Тобол якларында булырга, мәшһүр Иртеш елгасы итәгендә җәелеп утырган татар авыллары тормышын күрергә, Казаннан килгән студентлар буларак, милли мәдәниятебезгә сусаган милләттәшләребез алдында дистәдән артык концертлар куеп, күңелләрен күрергә туры килде; үзебезгә дә себер татарларының рухи байлыклары белән юл блокнотларыбызны мул итеп баету мөмкинлеге булды. Моннан тыш та төрле төбәкләрдә чыгышлар ясап, берни белән дә алыштыргысыз студент елларында вакытны файдалы да, истәлекле дә итеп үткәрергә хирыс идек...

Фәннур Хәсәновның Иске Мостяк мәктәбендә укыткан вакыты. 1984-1986 нчы еллар



Фәннур Хәсәнов. Казан. 1983

Татар бүлегендә укучы егетләрнең күпчелек кызлардан гына торган төркемнәрдә «күз өстендә каш» сымаграк кабул ителүе күпләргә мәгълүмдер. Һәрвакыт игътибар үзәгендә булуның да ике ягы бар: дәресләргә әзерләнү кебек көндәлек мәшәкатьләр, нигездә, кызлар җаваплылыгында булса, факультет өчен спорт ярышларында катнашу, «Студентлар язы» кебек чараларга концерт программаларын эшләү, әлбәттә, җыр-көйгә оста, милли уен коралларында уйнау хирыслыгы булган егетләргә – безнең җилкәгә төшә иде. Мондый «эш бүленеше» белән һәр ике як та канәгать: укуда да калышмыйбыз, тәрбия эше дә югары дәрәҗәдә. Шул сәбәпле, без, мәктәптә укытучылар коллективында һәм укучылар белән эшләргә, милли телебез, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез байлыклары белән бүлешергә әзер хәлдә, яңа җирләргә барудан баш тартмадык кына түгел, әлеге тәкъдимне кызыксыну белән кабул иттек. Уку программасыннан хәтердә калганнардан – бу як XIX гасырның җор телле, романтик рухлы мулласы – Габделҗаббар Кандалыйның һәм Габдулла Тукаебыз замандашы, фикердәше – Сәгыйть Сүнчәләйләрнең туган ягы безне дә чит итмәс әле, дигән өмет белән юлга чыктык...

Үзебез эшләячәк Кулаткы районының Иске Мостяк авылына барып җитү зур кыенлыклар тудырмады да кебек. Казан каласының тимер юл вокзалыннан төнге берләрдә, ягъни яңа көн башланганда «Казан-Волгоград» поездына утырып, үземнең Буа районының Яңа Тинчәле авылының бакча башыннан узып китеп 300 чакрымнар юл үткәч, күпмедер вакытлар автовокзалда «ял итеп», ул чорның «Ульяновск-Кулаткы» фирменный «Икарус» автобусында тагын 6-7 сәгать буе 300 чакрым «ял» итеп, район үзәгенә килеп төшәсең һәм авылга бара торган автобуста берәр сәгать «иркәләнүдән рәхәтлек алгач» – менә ул Иске Мостяк авылы. Тагын бер унбиш минут җәяү һәм син – Фаилә әбинең чәй табыны каршында.

Август ае. Без район үзәгендә – Кулаткыда. Укытучыларның август киңәшмәсеннән соң, Фәрит дустымны Кирюшкино авылына билгеләделәр. Ул үзенең булачак коллективының арбасына утырып, ялгышмасам, утыз чакрымнар ераклыкта урнашкан авылга юл алды, ә мин үземнекеләр белән алдарак искә алынган Иске Мостякка таба юл тоттым.

Әлбәттә, игътибарны беренче чиратта юлларының төзеклеге, табигатенең гаҗәеп тә матур булуы үзенә тартты. Гәрчә, үземнең авылым да кечкенәләрдән түгел; заманында 5 мәчетле, 700 йортлы (минем чорда 500ләп өе, 2 мәчете бар иде) авыл баласы булуыма да карамастан, авылның зурлыгына да игътибар итми мөмкин түгел иде.

Безне борчыганы, кызыксындырганы – эш урыны, коллектив һәм, әлбәттә, яшәү

Иске Мостяк мәктәбе

урынының нинди булуы. Ул заманда Мостяк авылының мәктәбе – ике катлы төзек бина, 200гә якын бала укуга исәпләнгән урта мәктәп булып, директоры – кешелекле һәм таләпчән Рәсим Туктар улы Абдиев, Сәйдә Закир кызы Сатдыкова – уку эшләре буенча, Тәүһидә Абдулла кызы Бакиева – тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары – күңелгә беренче күрүдә үк чын укытучылар булып кереп калдылар. Яңа гына ВУЗ бетереп, Казаннан килгән яшь белгечкә бөтен күңеле белән шат икәне йөзенә үк чыккан «минем Таһирә апам» (урыны оҗмахта булсын) –Таһирә Якуб кызы Нургалиева, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, минем яшь укытучы буларак остазым – төпле белемле, кешелекле, таләпчән, яшьләргә игътибарлы, ярдәмчел кеше күңелемдә уңай хисләр генә калдырган. Мин шушы урында Иске Мостяк авылы урта мәктәбе коллективындагыларның һәрберсен исемләп атап, аларга моннан утыз биш еллар элек, бу якта эшне тәгәлләп, туган якларыма кайтып киткән чакта әйтеп бетерә алмаган олуг рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Күпне күргән, зур хөрмәткә лаеклы ветеран Адельша Зариф улы Мурясов – тарих укытучысы, Рифат Ибраһим улы Фатфуллин –башлангыч хәрби белем бирүче укытучы, Равил Зәки улы Куртяков – хезмәт дәресе, Сәкинә Шәрәфетдин кызы Хәбибуллина һәм Фатыйма Сафа кызы Атауллиналар – математика фәне укытучылары, Галия Исхак кызы Әксәнова һәм Таһирә Мөдәррис кызы Нигъмәтуллина – рус теле һәм әдәбияты, Дамирә Кәшаф кызы Куртякова – француз теле белгече, Рәисә Абдракип кызы Хәбибуллина – физика, Венера Адельша кызы Мурясова – география һәм биология укытучысы, Наил Насыров, Зәкия Зәйнетдинова, Фәридә Бульхина, Таһирә Хайрова, Руфия Сөләйманова, Рәсимә Нугаева, Гөлкәй Фәтхетдиновалар, ашханәдә эшләүче кызлар, лаборантлар һәм башкалар, һәм башкалар... Әлеге исемлекне тагын дәвам итәргә булыр иде. Мин аларның барчасына да рәхмәтлемен. Һәрберсе – үзе шәхес, шул чорның белемле, үз һөнәренә тугры булган, Бөек укытучы исеменә тап төшермәгән кешеләр! Бу исемлек шушы укытучылар тәрбиясендә үскән укучыларга да якты бер истәлек булып калсын иде. Әлеге коллективта без ике ел буена бергәләп бик күп эшләр башкардык: укыдык, укыттык, кичәләр, бәйрәмнәр оештырдык – янып яшәдек.

Мәктәптә беренче дәресләребез, дулкынлану, борчулар, кич утырып дәрескә әзерләнүләр, кич төнге якка авышканда авыл клубында гармуннарга биюләр, дискәтүкләр оештыру хакында сөйли башласаң, бик күпкә җыелыр, ул – һәр яшь укытучының да башыннан үткән тормыш юлы. Үзем яшәгән йортның хуҗасы – Фәгыйлә (мишәрләрдә – Фаилә) әби турында искә алып үтәсем килә. Ул вакытларда авылларда безнең кебек «яшь белгечләр» өчен фатирлар юк, нигездә, авылның олырак яшьтәге гаиләләренә яки ялгыз карчыкларга кертәләр. Язып үтүемчә, мине фатирга улы Кәшаф белән яшәүче Фаилә әбигә керттеләр. Тулай торактагы тормыштан соң аның уртача гына, ләкин бик пөхтә, җыйнак өендә яшәү – эти-әни йортындагы кадер-хөрмәттән һич ким булмады, дип әйтә алам. Ул чорларда укытучыларга дәүләт исәбеннән бик күп ярдәм бирелә иде: ут-суга, йорт түләвенә ярты бәя, түләүсез утын, укытучыны ашатып-карап торган өчен күпмедер өстәмә акча һәм башкалар. Дәүләт дөрес оештырган, дип уйлыйм, бер атуда ике куян, дигәндәй, укытучыга – җылы урын, урта хәлле яшәүчегә – ярдәм. Фаилә әбием (соңрак аны чын мәгънәсендә үз туганым, әбием кебек күреп, улы Кәшаф абыйны да якын абыема тиңләп, хөрмәтләп яшәдем) мине үз улыдай күреп, эштән, төрле чаралардан кайтканда кайнар ризыгы, җылы карашы белән каршы ала, чын күңелдән эшем, уңышларым турында сораштыра, җайлап кына киңәшләрен дә бирә. Их, аның каз мамыгыннан ясалган ике-өч катлы ястыкмендәрләре өстендә тагын бер тапкыр гына булса да рәхәтләнеп йоклыйсы иде. Алгарак китеп, шуны да әйтәсем килә: Фаилә әбине ихлас күңелдән якын иткәнемне, Мостяк авылында 2 ел эшләп, яңадан Казанга кайткач, аннан соң армия сафларында хезмәт итеп, Дәүләт ансамбле белән гастрольләрдә йөргәндә генә аңлап бетерә алдым: әбием вафат булганчы, җае чыккан саен, барып, хәлләрен белеп тордым. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләгәндә, аннан соң да әле, ул якларга махсус концерт-тамашалар оештырып, әбиемдә кунак булгаладым. Иҗатчы дусларымны да әбием белән таныштырдым. Хәтта булачак хатыным Алияне дә аңа күрсәтеп, бәһа аласым килде. «Шиколад балакаем, шиколад», – дип мактап сөйләгәннәре, инде өйләнешеп, ике ир бала үстереп, ничәмә-ничә еллар үтсә дә, хәзер генә әйткән кебек, бүгенгедәй хәтеремдә саклана. Хәзерге көндә дә аның якты образы яшьлек елларының нурлы бер хатирәсе булып күз алдында тора. Аллаһның рәхмәтендә булсын иде...

Кулаткы районы – тулысы белән татар районы: авыллар исәбен белмим, ләкин алар күп һәм зур, нык авыллар, гомумән, биредә күңелле халык яши. Мондагылар күңел ачарга да, хезмәткә дә хирыс иде ул заманнарда. Шул чорның алдынгы яшьләре белән аралашып, дуслашып, районда үткәрелгән һәрбер чарада катнашып яшәдек. Фәрит дустым белән һәрдаим тамашаларны «алып баручылар» булдык, мин җырладым, ул биюдә өстенлек күрсәтте, мин гармунда уйнадым, ә ул бөек шагыйрьләребезнең әсәрләрен сәхнәләштерде. Программалар төзеп, районның иң талантлы артистлары белән берлектә, ике ел рәттән, «Ульяновск шәһәрендә район көннәре»н оештырырга булыштык...

Институттан соң юллама алып чыгып киткән юлыбыз чыннан да хөрмәткә лаеклы остазлар, гомерлек дуслар, туганнарга тиң авыл халкы белән таныштырган, олы юлга алып чыккан уңышлы юл булып чыкты. Кулаткы районы халкына, шушы язма аша, тормышта беренче сабаклар биргән өчен олы рәхмәтемне, хөрмәтемне юллыйсым килә. Һәр эшегездә уңышлар телим!

Фәннур Хәсәнов,
«Татарстан» телевидениесенең алып баручысы,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре ■

Сергей Михалков белән очрашу

Саимә Ибраһимова

Рәсемдә: беренче рәттә уңнан Саимә Ибраһимова, Сергей Михалков, Җәвад Тәрҗеманов, Анатолий Алексин, Габдулла Шамуков; икенче рәттә уңнан: Зоммер Гыйләҗев, Рәйсә Яхина, Әнәс Сәләхетдинов, Илгизәр Сәмигуллина, Хәмзә Зарипов. 1974 ел

1974 елның 24-25 май көннәрендә Казанның Политик мәгариф йортында Татарстан Язучыларының VIII съезды булды. Әлеге чарага Мәскәүдән атаклы шагыйрь Сергей Михалков белән прозаик Анатолий Алексин килгән иде. Мин, «Яшь ленинчы» редакциясе заданиесе белән, боларны табарга тиешле булдым. Кунакларның «Казан» кунакханәсендә тукталганнарын белдем дә, 25е көнне иртә белән шунда килдем. Алар йокыдан тормаган һәм иртәнге ашны ашарга өлгермәгән иде әле. Ничек тә күрешербез, дип, көтеп утырам шулай. Бераздан болар ашарга кереп китте. Мин исә һаман көтеп утырам. Берзаманны радиодан мөхәррир Эльза Гобәйдуллина (язучы Гариф Гобәй кызы) килде: «Син нишләп утырасың монда?» – ди. Нигә килгәнемне әйтеп тормадым моңа. Кунаклар йокыдан торды, хәзер алар ашарга кереп китте, дидем. Эльза һаман саен сәгатенә карый. «Они давно туда ушли?» – дип сорый бу миннән. «Байтактан инде», – дим. «Нет, мы же на это время договорились. Я больше ждать не буду!» – диде дә Эльза кунакханәдән чыгып китте. Мин исә һаман көтеп утырам. Бик озакка китте бу. Менә бервакыт болар өчәү килеп чыкты. Өченчесе – үзебезнең язучы Җәвад Тәрҗеманов иде. Язучылар берлеге кунакларны озатып йөрүне аңа тапшырган, күрәсең. Сергей Михалков:

– Вы не в-в-видели из р-р-радио к-к-кого-нибудь? – дип, тотлыга-тотлыга сорый миннән. Ул шулай гел тотлыгып сөйләшә икән.

– Она уже давно ушла, – дидем.

– Вот д-д-дураки, вот д-д-дураки! – ди Сергей Михалков.

– Я ведь тоже за вами пришла, – дим. Кунакларны үзем белән таныштырам.

– Давайте к нам пойдем, мы тут рядом! – дип, Бауман урамы буйлап, Матбугат йортына алып киттем боларны.

Редакциядә күңелле генә сөйләшеп утырдык. Бик тәмләп чәй эчтек. Бергәләп фотога төштек. Ул фотода, кунак язучылар белән бергә, үзебезнең редакция хезмәткәрләре дә, танылган артистларыбыз да бар. «Әгәр Эльза Гобәйдуллина сабыр итеп көткән булса, безгә Сергей Михалков белән фотога төшү насыйп булмый иде бит», – дип сөендем мин шул чакта. ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Фаил Шәфигуллинның тууына 80 ел



Күренекле шагыйрь һәм прозаик, сатира-юмор остасы Фаил Хафиз улы Шәфигуллин 1939 елның 18 маенда Татарстанның Норлат (хәзерге Яшел Үзән) районы Карашәм авылында колхозчы гаиләсендә туа.

1953 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын башлап җибәрә: өч ел колхозда эшли, аннары, 1956 елдан 1962 елның җәенә кадәр, Коми АССРда – урман кисүче, чирәм җирләрдә – тракторчы, Приморск краеның Находка шәһәрендә – кара эшче, слесарь, Тын океанның балык тоту флотында матрос була.

1973 елдан башлап, Ф.Шәфигуллин Казанда журналист хезмәтендә: әүвәл «Казан утлары» журналы редакциясендә – әдәби хезмәткәр һәм шигърият бүлеге мөдире, аннары яшь язучыларның әдәби альманахы «Идел»нең җаваплы мөхәррире вазыйфасын башкара. Гомеренең соңгы елларында (1975-1982) ул «Чаян» сатира-юмор журналы редакциясендә әдәбият һәм тәрҗемә бүлеге мөдире булып эшли.

Ф.Шәфигуллинның беренче шигырьләре матбугат битләрендә 1958 елда күренә башлый. Үзе исән вакытта 9 китабын бастыра.

Ф.Шәфигуллин 1982 елның 7 октябрендә фаҗигале рәвештә һәлак булды.

Журналист Фәрит Шәрифуллинның тууына 80 ел

Танылган журналист, тәрҗемәче, ТАССРның атказанган укытучысы (1979), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1989), Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе лауреаты (1989) Фәрит Әхмәтнур улы Шәрифуллин 1939 елның 19 маенда Саба районының Олы Шыңар авылында туа.

Олы Шыңар җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Ф.Шәрифуллин Арча педучилищесында, аннары Казан педагогия институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлегендә белем ала.

1963 елның җәй ахырында Ф.Шәрифуллин «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналы редакциясендә эшли башлый.

1970-1977 елларда журналның педагогика-методика бүлеген җитәкли.

Бер ел баш мөхәррир урынбасары булып эшләгәч, ягъни 1989 елда ул журналның баш мөхәррире вазыйфасын башкарырга алына.

Фәрит Шәрифуллин оста тәрҗемәче булуы белән дә билгеле шәхес. 1984 елда тугызынчы сыйныфларга «Гаилә этикасы һәм психологиясе» дигән фән укытыла башлагач, дәреслекләр булмау сәбәпле, Ф.Шәрифуллин «Мәгариф» журналында ике ел

дәвамында дәрес үрнәкләре биреп бара һәм 1989 елда «Гаилә тормышына әзерлек дәресләре» дигән китап бастырып чыгара.

Ф.Шәрифуллин 2011 елның 8 апрелендә вафат булды.

Әдәбият белгече Мәсгут Гайнетдиновның туууына 90 ел

Әдәбият белгече, текстолог, филология фәннәре докторы (2000) Мәсгут Вәлиәхмәт улы Гайнетдинов 1929 елның 25 маенда Ульяновск өлкәсенең Малыклы районындагы Лабит авылында туа. Мәләкәс шәһәрендә укытучылар институтын тәмамлый (1950). 1968 елга кадәр Үзбәкстан ССРның Яңа Юл районы урта мәктәпләрендә укыта. 1968 елдан СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1996-2003 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли. К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ен (1957), Г.Ибраһимов әсәрләрен (Т.1-8, 1974-1987), Х.Туфанның «Сайланма әсәрләр»ен (Т.1-2, 1974-1975) текстологик әзерләүдә, «Татар поэзиясе антологиясе»н (Т.1-2, 1992) төзүдә катнаша. Х.Туфан иҗатын тирәнтен өйрәнә. Хезмәтләре 19-20 нче йөз татар әдәбияты тарихына, совет чоры поэзиясенә, татар әдәбияты текстологиясенә карый.

М.Гайнетдинов 2016 елда бакыйлыкка күчте.

Археолог Альфред Халиковның тууына 90 ел

Археолог, тарихчы, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1992), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1974), Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге лауреаты (1994) Альфред Хәсән улы Халиков 1929 елның 30 маенда Чистай кантонында (хәзерге Нурлат районында) туа.

1947 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә һәм аны 1952 елда бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Әле укыган вакытта ук, ягъни 1951 елда аны СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтына лаборант итеп эшкә алалар. Ул анда утыз ел буе археология һәм этнография бүлеген җитәкли, докторлык диссертациясен яклый, профессор дәрәҗәсенә (1968) ия була.

Альфред Хәсән улы Халиковның тәкъдиме һәм тырышлыгы белән, Казан университетында археология музее төзелә. Казан урамнарының берсе бүген А.Халиков исемен йөртә.

Альфред Халиков 1994 елның 24 июлендә вафат булды.

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2019

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

ТАШ СЫБЫЗГЫ

Без *таш сыбызгы* дип йөрткән уен коралы Кытайда, Японияддә һәм Америкада моннан җиде мең еллар элек үк билгеле булган. Аны, гадәттә, шаманнар, руханилар явыз рухларны куганда, Тәңре белән «сөйләшкәндә» һәм башка шундый йолалар үтәгәндә кулланганнар. Тышкы кыяфәте дә коточарлык ямьсез итеп ясалган. Кытайча ул *сюн* дип аталган.

Мондый уен кораллары дини бәйрәмнәрдә Америка индеецларында хәзер дә кулланыла. Җөмләдән, галимнәр бихисап еллар инде төрки халыклар белән индеецлар арасында зур охшашлыклар булуын икърар итә. Беренчедән, төс-бит охшашлыгы. Икенчедән, уртак сүзләрнең байтаклыгы (бу фикерне галим Әбрар Кәримуллин

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

да куәтли иде). Өченчедән, музыка уен коралларының охшашлыгы. Һәм тагын да гаҗәпләндергәне – бу халыкларны пентатоник музыка да үзара якынайта!

Хәзерге таш сыбызгы, бәлки, бик борынгы заманнарда башкача аталгандыр. Бу уен коралында тавыш хасил булу *сыбызгы алымына* туры килми (ягъни курайдагы кебек түгел), аның һава чыга торган икенче башы томаланган була. Өрелгән һава уен коралының эчендәге куышлыкта җыйнала һәм, музыкаль авазга әверелеп, тишемнәрдән чыга. Шуңа күрә аның авазы үзенчәлекле, сихри яңгырый (борынгылар аны *җил тавышы* дип атаганнар).

Кечкенә вакытта без тал кабыгыннан сыбызгы ясап уйный идек. (Аның тавыш хасил булу ысулы нәкъ таш сыбызгыныкы кебек).

Артыграк мавыгып китсәң, олылар: «Сызгырма, җил чыгарасың!» – дип ачулана иде. Балачакта игътибар ителмәгән әлеге әйтем дә безне борынгы чорга кайтара. Чөнки элгәреләрнең сыбызгы сызгыртып яңгыр теләве, чир кууы һәм башка шундый йолалар үтәве мәгълүм.

Окарина (таш сыбызгының бер төре) уен коралын Италия остасы Джузеппе Донати әле XIX гасырда гына уйлап таба (дөресрәге, кытайларның «сюн» уен коралын һәркем уйный алырлык итеп үзгәртә). Һәм ул тиз арада бөтен дөньяга тарала.

Татарларда таш сыбызгыны музыка уен коралы буларак куллану турында мәгълүмат аз. Изге Болгарда казу эшләре вакытында табылган ике тишемле бер таш сыбызгы саклана миндә. Шулай ук, Казан кирмәнендә дә борынгы таш сыбызгының бер кисәге табылган иде. Анысы – күренекле галим Р.Халитов коллекциясендә. Аңарчы, 1984 елда алты тишемле таш сыбызгының *үрдәк* дип атала торган бер үрнәген миңа галим Марсель Бакиров бүләк иткән иде.

Татарстанда таш сыбызгы ясаучы берничә остаханә бар, ләкин алар бу әсбапны бары тик балаларга уенчык, сувенир буларак кына эшлиләр. Аны чын музыка уен коралына әверелдереп, билгеле бер тавыш югарылыгына көйли белмиләр. Бүгенге сәхнәдә яңгыраган таш сыбызгыларның барысы да чит илләрдән кайтарылган. Ни сәбәпледер, Россиядә сыйфатлы итеп окарина ясаучы осталар юк. Әйткәнемчә, бары тик балалар өчен ике яисә дүрт тишемле таш сыбызгылар гына эшләнә.

Фольклор ансамбльләрендә таш сыбызгы куллану бик отышлы. Алтмышынчы-җитмешенче елларда таш сыбызгыда һәм төрле зурлыктагы курайларда уйнап көчле алкышларга күмелгән артист Хәмит ага Бакировны хәтерлим әле. Миңа да аңа кушылып баянда уйнау бәхете насыйп булды.

Әйтелгәннәргә таянып, шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: татар халкы элек-электән үк таш сыбызгыда уйнаган һәм хәзер дә ул безнең өчен ят музыка уен коралы түгел.

Уйнарга теләүчеләр өчен киңәшем шул: ике тишемле таш сыбызгыны сувенир кибетеннән сатып алыгыз; ләкин сайлаганда шуңа игътибар итегез – түбән тавыш белән югары тавыш арасы нәкъ октава булсын. Тишемнәрне бармаклар белән өлешчә генә каплап-ачып та бер октава эчендәге барлык хроматик авазларны чыгарырга мөмкин.

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Дәвамы бар ■

МУЗЫКАБЫЗ*

(Граммофоннар)

Сәгыйть Сүнчәләй

*«Р.Ишморат ике бертуганның (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына кергән Иске Мостяк авылы егетләре шагыйрь Сәгыйть һәм абыйсы Шәрифҗан Сөнчәләйләр. – **Ред.**) Сараштагы яшәү рәвешләрендә җыр һәм музыканың зур урын алып торуын яза. Сәгыйть скрипкада һәм мандолинада оста уйнаса, абыйсы яхшы гармунчы була. Гомумән, кече Сүнчәләй гомере буе музыкага гашыйк булып яшәгән, үзе уйнау, үзе җырлау белән генә канәгатьләнмәстән, бу өлкәдәге оештыру эшләренә бик теләп катнашкан. Мәсәлән, «Көрәш» газетасы 1918 елгы 25 март санында Уфада С.Сүнчәләй рәислегендә «Татар әдәбияты һәм музыкасы җәмгыяте» төзелүен хәбәр итә. 20 нче еллардагы хезмәт урыннары да — сәнгатькә, музыкаль тормышка бәйле җаваплы вазифалар. Әсәрләренә дә үтеп керә аның музыкага, сәнгатькә гашыйклыгы. Әдипнең бер пьесасы «Сәнгатьчеләр» дип аталган, персонажлары — актриса Әлфия, сукыр музыкант Халикъ, җырчы Биньямин, художник Рәшит, шагыйрь Борындык. Әнә, «Таң алдыннан», «Скрипка моңнары» дигән сәхнә әсәрләренең эмоциональ-эстетик дөньясы да музыкага нисбәтле мотивлар, образ-сурәтләр белән сугарылган. Сүнчәләй композиторлык сәләтенә дә ия булган (ул унлап көй язган; ноталы язмалары архивында саклана»).*

Зөфәр Рәмиев

Без, татарлар борын заманнардан бирле музыканы яратып килдек. Муллалар музыканы хәрамласалар да, бу хактагы фәтваларын тыңлатсалар да, гаклыбызны гафләткә табындыра алсалар да, безнең күңелемез гаклыбыздан өстенрәк, нәзегрәк, нурлырак иде. Күңелемез музыканы хәләл күрде: уйнадык, җырладык.

Газиз көйләребезне зур читенлекләр белән булса да саклый килдек. Әлбәттә, күп матур көйләребезне онытып та бетерә яздык. Шунда да мунчаларда, начар урыннарда, туйларда гына булса да без үзебезнең һәйбәт музыкабызны хәзергә кадәр көчкә өстерәп җиткердек, бөтенләй онытмадык.

Гаҗәп түгелме, XIX гасырда музыканы хәрамлаган бер фәтвачы мулла бар идеме? Ә без мулласыз тумый да, үлми дә идек, гаклыбыз зәгыйфь, игътикадларыбыз шуларның фәтвалары золмәтендә иде түгелме?!

Без курайлар, эскрипкәләр, гармуннар уйнадык. «Тәфтиләү», «Сакмар», «Тәскирә», «Кара урман», «Әллүки», «Су өсте», «Ашказар»ларны вә бүтән кыска көйләребезне уйный килдек, җырлый килдек. Мөнәҗәтләр, бәетләр, «Мөхәммәдия»ләр[1], «Йосыф»лар[2], «Бакырган»нар[3] — әллә ниләр укыдык, көйләдек, моңландык, ләкин, мәгаттәәссеф *(кызганыч ки)*, менә боларын онытып та бетерә яздык. Күңелләребезнең моңнарын коры, сатхый *(беркатлы, сай)* фәтвалар гына җиңә алмады.

---

* Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 11 апрель (1165 нче) санында «Әбүлфәрит Вәкъкас» тәхәллүсе белән басылган, газета исеме янындагы «эчтәлек»тә «Граммофондагы җыр вә көйләребез» дигән искәрмә дә бар. С.Сүнчәләй «Мияубикә» китабына язган рецензиясен «Сәгыйть Вәкъкас» имзасы белән бастырган иде. Бу юлы исә шагыйрь, үзенең 1912 елда туган улы Фәрит исеменнән файдаланып, «Әбүлфәрит Вәкъкас» имзасын ясаган. (Әбүлфәрит — гарәпчәдән тәрҗемә итсәк, Фәритнең атасы дигәнне аңлата.)

[1] «Мөхәммәдия» — төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби угылы (?-1451) тарафыннан төзелгән көйле әсәр.

[2] «Йосыф» — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы турында сүз бара (XII-XIII гасырлар).

[3] «Бакырган» — «Бакырган китабы», 12 нче йөз Урта Азия шагыйре Сөләйман Бакыргани төзегән китап.

XIX гасырыбыз музыка ягыннан фәкыйрь түгел иде. Ул гасырның моңнары әле дә булса колакларда чыңлый. Хыялларны, исәпләрне борынгылыкка — ямьлегә илтә.

XX гасыр керде. Без музыкабызны яктыга, иреккә чыгардык та шик вә шөбһәсез уйный, җырлый башладык. Иске матур көйләребезне күңелләребезгә ныграк сеңдерергә телибез. Яңа көйләр (бик үк милли һәм матур булмаса да) чыга торалар. (Бу турыда «золмәт»тәге хатын-кызларыбызның зур хезмәте тия.)

Үзебезнең хәзерендә әле композиторларыбыз юк. Шуңа күрә искеләребез белән генә канәгатьләнәбез.

Безнең музыка эче-тышы белән трагедияле. Нинди генә көебезне алма — һәммәсе амиз хәсрәтле *(хәсрәт катнашкан)*. Берәүгә татарча шат көй уйна, диген — кем уйнар, ни уйнар, кайсы көйне уйнар? Шат дип уйнаган бер кыска гына көйләребезне уйнатып тыңлап кара. Шуларның эчендә дә никадәр хәсрәт, кайгы, скорбь һәм трагедия сизәсең, һәр көй никадәр көйне сөйли. Күпне аңлата... Гадәтчә, намәгълүм *(билгесез)* бер зат бер көй чыгарса, шат кеше чыгарса да, була татар рухы, татар хөзене *(кайгысы)* ул көйдә... һәр көйдә балкый, балкый...

Безнең музыканың шушындый хәсрәтле вә фаҗигале аһәңле булуы — аның кимлеге түгел, бәлки өстенлеге, һәйбәтлеге, кәмаләтедер.

Без үзебезнең музыкамызның ярлылыгын инкяр итмәсәк тә, аны «милли хөббеннәфес» *(эгоизм)* аркылы гына түгел, бәлки чын мәхәббәт белән сөябез, ул безнең сәмигъләргә *(колакларга)* чит милләтләрнең шедеврларыдай — изге, изге.

Хәзер кайсы авылга гына барма, кайсы мужикка, муллага гына уен, җыр, яхуд граммофон тыңлатма — һәркем ярата. Үз музыкабыз алдында баш ия.

Инде «Шөбһәле мәкруһ»лар басылгач, күп татар гаиләләрендә музыкага мөнәсәбәтле бер аләт була башлады.

Элегрәк уенлы сәгать (монысы, хәер, татарча түгел), аннары уенлы ящик, аннары да граммофон, патефон вә пианино...

Хәзер күп гаиләләрдә граммофон күренә, яшьләремез гитара, мандолина, эскрипкә, гармун вә пианиноларда уйныйлар. Әмма музыка вә әдәбият кичәләребез бер дә булмаган, дияргә мөмкин. Барлы-юклы уенчыларыбызны кадерли алмаганыбызга (эскрипкәчеләрдән Мөхәммәдшаһ карт, Кара малай, Зайпин[1] вә бүтәннәрне), татар музыкага, уенга, җырга мохтаҗ булганга, музыкасыз күңел төшенкелеге куәтле булганга — чарасыз өенә граммофон кертә...

Милләт зәвыгы кечкенә эш түгел. Шуңа күрә мин граммофон табаклары хакында кечкентәй генә бер мөляхазә йөртмәкче *(фикер йөртмәкче)* булдым. Бу мәкаләмне язуыма да шул сәбәпче булды. Граммофоны хакында берни дә сөйләп булмый инде. Менә табаклары! Иң мөһим нәрсә — табакларына уйналган уеннарда, җырланган җырларда! Хәзерендә үзебезнең көйләр уйналган вә җырланган пластинкалар күп. Шуларның бәгъзеләрен актарыйк.

КЫЗ-ХАТЫННАР ҖЫРУЫ

1. Җырлаучылары: Мәхмүзә Булатова һәм иптәшләре. Тавышлары ямьсез, асла *(һич)* уйнатырлык, җырлатырлык түгел. Көйләрен аңламассың — шаблон! Әллә ни җырлыйлар. Сәмигыңны *(колагыңны)* яра да җибәрә инде! Граммофон җырлары биргән вак-төяк акчага (яңа шөһрәткә) кызыгып, татарның газиз көйләрен хур итеп, мыскыллап «җырлаган» хатын-кызларга ни димәк кирәк?! Бик зур әдәпсезлек, инсафсызлык, дисәң дә, аннан да каты сүз тапмагач, ачуыңнан төкерегеңне йотасың шул!

[1] Зайпин — Гали Мостафа улы Зайпин (1873-1918), музыкант.

Сәгыйть Сүнчәләй, 1914 ел

2. Мәрьям Искәндәрова. Искәндәрова ханымның зыялы татар галәмендә кадере, хөрмәте булмаса да, ул шансонеткалар рәвешендәрәк җырласа да, аның тавышын әшәке дип булмый. Тавышы ярыйсы, хәтта чибәр дә. Әллә нинди нәзек, көмеш тавышлы ул Мәрьям ханым. Җырлаганда, аның тавышының кайбер урыннары өзелеп, (вальцованныйныкы шикелле), үзгәреп китә. Менә шушы үзгәрү, өзелү бик матур була. Нечкәртеп җибәргәндә дә күңелле генә чыга. (Мәсәлән, «...уф Алла» дигәндәге «Алла» сүзе.) Гомумән, Мәрьям ханымның тавышын «көмеш тавыш» дисәк, мөбаләгә *(арттыру)* булмас. Җырларының сүзләре дә матур була.

3. Нәфисә Пуснякова. Нәфисә ханымның да тавышы чибәр, музыкальный. Ул ни җырлаганын белеп җырлый. Аның «Кара урман»ы, «Тәскирә»се бар. Нәфисә ханым да күңелне канәгатьләндерә ала.

Мәрьям ханым да, Нәфисә ханым да – чибәр генә җырчылар. Тавышлары тагы да һәйбәтрәк тәрбия, гыйлем алса, без бу ханымнар белән, ихтимал, мактана да алыр идек.

4. Бүтән кыз-хатыннар начар җырлыйлар.

Хосусан, өчәү-дүртәү җыелышып такмаклар әйтүләре муафыйк эш түгел. Граммофонга кереп үз «золмәт»ендәге чәйнәүләрне оялмыйча голәмага ишеттерү гүзәл эш түгел.

ИРЛӘР ҖЫРУЫ

1. Мирфәйзә Бабаҗанов[2]. Бабаҗанов хатын-кызларча нечкә тавыш белән җырлый. Бабаҗановның музыкасы да тавышына муафыйк була. Ул үзе дә ни эләкте – шуны җырламый, ул бик сак. Ул үзенә җырларга көйләребезнең иң матурларын, моңлыларын гына сайлыймы, югыйсә үзе шулай матур җырлыймы – ул чибәр җырлый.

Дөрест, җырларында сүзләре күбесенчә шаблонный, хәтта ямьсез дә була-

[2] Мирфәйзә Бабаҗанов (1867-1943) — «Тройски Мирфәйзә», җырчы, гармунчы.

лар (мәсәлән, гүләйт, җиңгәчи...). Шунда да аның тавышының саклыгы, сафлыгы, күркәмлеге ул гаепне генә җуя ала.

Бабаҗанов – үзенең җырлары, бәгъзән мөнәҗәтләре белән тәмамән XIX гасырыбызның мәҗлесләрен, туйларын сагындыра. Үткән хәсрәтле вә серле тормышларыбызның, туйларыбызның рухын аңдыра, бик үк куәтле булмаса да, сихерле.

Бабаҗанов – тәкъдир ителерлек җырчы ул. Аның «Фазлуш», «Карлыгач» вә бүтән көйләрен, «Фани дөнья» атлы мөнәҗәтен ихтыярсыз кат-кат тыңлыйсың килә.

2. Камил Мотыйгый[3]. Камил Мотыйгый үз көйләребезне начар җырлый. Аның тавышында, гомумән, татар моңы, татар аһәңе юк. Ул урысчага тарта. Озын көйләребезне бозып җырласа, кыска көйләребезне гаять ямьсез җырлый. Аның бәгъзе бер урысчадан урлаган көйләре бар, мәсәлән, «Нәрсәдә ләззәт?», «Кемне сөяргә?» (Тукай шигырьләре). Бу шигырьләрне урысчарак көйләргә тартып җырлый. Бу юлда, бераз булса да, муаффәкыять тә казана ала. (Ләкин Камил әфәнде тузып беткән сүзле, иске вә ямьсез мәгънәле шигырьләргә гашыйк.) Камил Мотыйгый хакында кыска гына әйтәсе сүзең булса, шул: ул татар җырларын җырлый ала торган җырчы түгел. Аңардан күп нәрсә көтә алмыйбыз.

3. Хөсәен Йосыпов. Бу әфәнденең дә тавышы нечкәрәк. Ләкин Бабаҗановка җитү кайда! Йосыпов муаффәкыятьле кеше түгел, аның чинавы, күңелсез, эчпошыргыч тавышы сәмигыңны мыскыллый. Җитмәсә, авызын җәеп җырлый булырга кирәк. Мишәрнең дә мишәре. Ләкин мишәр аһәңе аңарда юк. Әллә нинди: мисрагъ саен «аклы ситса күлмәгеңне» кычкыра! Гармунының да улавы мәгънәсез.

4. Адамантов Ибраһим әфәнденең тавышы салмаклы, ләкин артык нәфис түгел, тәрбияле дә түгел. Музыкага да ияләшә алмый. Адамантовның «Төш» дигән бер җыры бар. Менә шушы «Төш» белән ул ифтихар кыла *(горурлана)* ала. «Төш» һәйбәт ул, әмма... Адамантов әфәнденең әллә нинди бер зат белән җырлаган көйләре бар. Менә ул көйләре гаять ямьсез. Чөнки ул зат (сәхипзадәме, әллә кем) тәмамән боза, ямьсезли. Ул тупас тавышлы бер карт шәкерт йә талчукчы булырга кирәк.

5. Кариев[4]-Карцевның да мөсаһәлә *(йомшак, мәсьәләгә җиңелчә карау)* чаклары булган икән!

Инде килик җырсыз, фәкать уенлы табакларга.

1. Бу юлда «Казанский оркестр» аталган кыллы уенчылар шактый муаффәкыять казаналар.

2. Габдулла Козлов дигән бер гармунчы уйный, начар уйнамый.

3. Кудашев-Ашказарский[5]. Ул да зарарсыз уйный. Ләкин кайбер урыннарда тәмамән бозып җибәрә.

Азаккы теләк вә үтенечләрем:

Граммофон пластинкаларына Фәттах Латыйпов[6] җырласын иде. Кара малай яки Зайпин, ләкин бергә түгел, эскрипкәдә (ләкин рояль белән) уйнасыннар иде.

Эбер-чебер адәмчекләр милләт зәвыгын мәсхәрә кыла күрмәсеннәр, юк хакка алданып, милләтне дә ваксытмасыннар иде.

«Тавышлырак» кешеләребез тавышларын тәрбияләсеннәр, консерваторияләргә барып укысыннар иде.

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Зөфәр Рәмиев** әзерләде.* ■

[3] Камил Мотыйгый (1883-1941) — журналист, нашир, беренче профессиональ җырчы, артист.
[4] Кариев Габдулла (1886-1920) — артист, режиссер, драматург, «Сәйяр» труппасы җитәкчесе.
[5] Кудашев-Ашказарский Ильяс (1884-1942) — артист, режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.
[6] Фәттах Латыйпов (1884-1966) — артист, җырчы, композитор.

Безнең мирас №5 май 2019

ЗУР ИҖАТКА БЕР КАРАШ

Рәдиф Сәгъди

...Күңелне җилкендереп көй агыла башлый. Бер көчәя, бер тына ул! Бер салмаклана, бер тизләнә! Шундук, күңелләргә шом-сагаю салып, барабаннар кинәт-кинәт дөпелдәп ала. Баян тавышы бәреп чыгып, мәхәббәткә мәдхия укый, сөю сагышының мизгелләренә басым ясап, эскрипкә елый. Шул көй астында әкрен генә пәрдә ачыла. Музыка кабат бер талпынып ала да, тынып кала. Сәхнәдә вакыйга, тамаша-тормыш башлана. Паузадан файдаланып, оркестр чокырында урнашкан көйчеләр чираттагы яңгыраш өчен ноталарын җайлыйлар, кирәк минуты җиткәч, өскә күтәрелгән дирижер таягы кабат идарә итә башлый. Дирижер сәхнәдә күрсәтеләчәк драманың эчтәлеген режиссер кебек үк энәсеннән-җебенә хәтле белергә, кулындагы таягының һәр селтәнеше вакыйгага бәйләнеп, берегеп барырга тиеш. Спектакльгә ятышлы итеп язылган көйләр тәэсир итү көчен бермә-бер арттыра. Тамашаның музыкаль бизәлешен төгәл алып барыр өчен, сәхнәдәге үйналышның һәр мизгелен, һәр үзенчәлеген төптән белү сорала дирижердан.

Безнең мирас №5 май 2019

Фоат Әбүбәкеровның Финляндиядә чыгыш ясаган чагы

МӨҺАҖИРЛЕКТӘ...

Хәмит Әбүбәкеров, әтисе вакытсыз үлеп, әнисе икенче кат кияүгә чыккач, балалар йортында үсә. Әнисен, туганнарын сагыну-юксынуы, биредәге кыенлыклар, кыерсытылулар үсмерне илаһилыкка, матурлыкка омтылуга этәрә. Ул, музыка белән шөгыльләнә башлап, тырышып, үзенең хыялларын тормышка ашыра башлый. Әҗере дә озак көттерми, Хәмит Әбүбәкеров татарның беренче профессиональ виоланчелистына әйләнә. Аның бу музыка коралы буенча беренче укытучысы танылган Рувим Львович Поляков була. Үсмернең сәләтен, тырышлыгын белгән мөгаллимнәре аны яңа гына җыелган Мәскәү консерваториясенә укырга барырга тиешле сәләтле, талантлы яшьләр төркеменә кертә. Хәмит Әбүбәкеров белән бергә, киләчәктә зур иҗатка нигез салачак М.Мозаффаров, А.Ключарев, З.Хәбибуллин, Н.Җиһанов та ошбу төркемдә була. Хәмит Әбүбәкер улына биредә дә үз эшен яхшы белгән, фидакарь укытучы Абрам Ильич Ямпольскийда белем алырга туры килә. Ләкин балачактагы интегүләре, сәламәтлегенең таушалуы үзенекен иткән: үпкәләре чирле булу сәбәпле, Хәмит Әбүбәкеров дүртенче курстан белем алуын туктатырга мәҗбүр. Шуңа карамастан, башкалабызга – борынгы Казанга кайту белән үк ул җиң сызганып иҗат итәргә керешә, Курчак театрына эшкә урнаша. Шул ук вакытта Татарстан Дәүләт радиокомитеты оркестрында күп кенә танылган җырчыларның сольный концертларында уйный. Салих Сәйдәшев белән аралашып-дуслашып китүе дә аның иҗатына зур этәргеч бирә. Тәтеш районының Әтрәч авылында мулла гаиләсендә туып үскән Хәлимә атлы кыз белән танышып китеп, тормыш корып җибәрә. Яраткан эше, сөйгән хатыны булуы – киләчәктә матур тормыш корып яшәүләренә өметләре зурдан була. Тик... Дәһшәтле, юк өчен дә бик күпләрнең башына җиткән 1937 нче еллар килә. Мәгърифәтле, үз сүзен турыдан әйтә торган кешеләрне чүпләү башлана. Дусты Исмай Шәмсетдиновның, алдан ук нидер сизенеп: «Хәмит, телең озын, башыңа җитмәсеннәр!» – дип кисәтүе бик урынлы була. Яңа гына никах укытып гаилә корган егет хатыны белән Үзбәкстан якларындагы Нәмәнган шәһәренә качып китә. Чөнки биредә, ни дисәң дә, якын туганнары да бар! Мөһаҗирлеккә китеп туган ягын сагынып-сагышланып яшәсә дә биредә дә үз урынын таба. Бу чорларда Нәмәнганда ул нота таный торган бердәнбер шәхес була. Сугыш башлангач, әлеге калага танылган музыкантлар, иҗат эшлеклеләре күчеп килә. Фәкыйрьлек, ачлык-ялангачлык хөкем сөрсә дә Хәмит Әбүбәкер улы алты баласына да музыка белеме бирдертер өчен тырыша, аларны укырга кертә. Бер хезмәт хакына гына укытып та, зур гаиләне яшәтеп тә булмый, әлбәттә. Аңлавымча, җирле татарларга, кыргызларга, үзбәкләргә, казакъларга да кирәк чакта туйларда, бәйрәмнәрдә, сөннәткә утырту йолаларында да ипилек кенә хезмәт күрсәткәннәрдер талантлы музыкантлар. Нәваи исемен йөрткән театр Үзбәкстанда иң танылган театрлардан санала башлый, чөнки биредә мөһаҗир музыкантлар

Ф.Әбүбәкеров беренче укытучысы Раиса Ивановна Семьянова белән. Нәмәнган шәһәре. 1952

төркеме иҗат итә, шулар арасында Хәмит Әбүбәкеров та – иң алдынгылар рәтендә. Үзбәкләр аны, якын итеп, яратып, «үз абзыебыз!» дип йөрткәннәр.

Килгән мәлләрендә туганнары янына елышкан Хәмит аганың гаиләсе әкренләп кенә аякка баса башлый. Үзбәк театрында милли классикадан «Ләйлә илә Мәҗнүн», «Таһир-Зөһрә» кебек шәрык әдәбияты җәүһәрләре куела. Шул ук вакытта В.Шекспир әсәрләре дә сәхнәгә менә. Барлык әсәрләрдә дә Хәмит ага җитәкчелегендәге оркестр уйный. Хәмит Әбүбәкеров бөтен язу-сызу, музыка сайлау, яздырту кебек эшләрне дә үзе булдыра. Аның профессиональ осталыгы, хезмәт сөючәнлеге бөтен шәһәр халкы алдында танылуга, зур хөрмәткә лаек булуга китерә. Шул ук вакытта балаларына төпле музыка белеме бирүне дә игътибардан ычкындырмый. Алар алтысы да – көйчеләр. Ләкин әтисенең һөнәрен турыдан-туры дәвам итүчесе берәү генә була, ул – безнең күренекле скрипкачыбыз Фоат ага Әбүбәкеров. Скрипкада биш яшеннән үк сыздыра башлаган малай мәктәпкә укырга кергәч үк зур танылу ала. Мәктәпне дә «бишле» билгеләренә генә тәмамлый ул. Рус теленнән хәтта «+5»ле куялар. Уку чорында, үсмер апа-абыйлары белән берлектә, Нәмәнган шәһәренең театр оркестры составында төрле концерт-чараларда катнашып, халык алдында һөнәрен күрсәтеп, чыныгу ала башлый. Шуларга мәктәп бәйрәмнәрендә катнашуын да өстәсәң, үзе бер уку йортын бетерүгә тиң булыр иде.

Хәмит ага белән Хәлимә апалар балалары күңеленә кечкенәдән үк туган телләренә,

аның көй-моңына тартылу оеткысын салалар. Аларга ата кеше С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов музыкасын, «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Нурхан», «Алпамыш», «Таһир вә Зөһрә» эпик драмаларындагы әсәрләрне виолончельдә бер уйнап күрсәтүе була, кечкенә Фоат аны шундук эләктереп алып, эскрипкәдә кабатлый. Татарстанны сагынып яшәгән Хәмит ага балаларына театр рухын тирәнрәк сеңдерергә тырыша. Әнисе исә даими рәвештә Г.Тукай, Дәрдемәнд шигырьләрен яттан сөйли. Аның пешергән ризыклары җирле татарлар өчен кулинария үрнәге булып, ул шәһәрнең хөрмәтле ханумасына әйләнә. Бәйрәм-туйларда икесенең дә урыннары түрдән була. Балаларының тырышып укуларын күреп сөенсәләр, туган җирләреннән читтә яшәүләренә дә бик еш көенәләр. Ярый әле биредә туганнары шактый ишле, аралашыр, күңел бушатыр өчен үз татарлары бар.

ВАСЫЯТЬ

Нәмәнган дәүләт театрына музыкаль бизәлеш эшләрен алып килгән Хәмит ага Әбүбәкеров балаларын үзе хыялланган, гомерен багышлаган һөнәренең дәвамчылары итеп күрәсе килә. Ул аларның изге туган җирләренә кайтачакларына ышана. Тик инде анда төпле музыкант кына түгел, тәрбияле кеше булып танылуларын да тели. «Аракы эчеп, тәмәке тартып, җил куып гомерегезне әрәмгә уздырмагыз!» – дип, гел искәртеп тора Хәмит ага.

Үзбәкстанда музыка мәктәбен һәм училищесын бик яхшы билгегә генә тәмамлаган Фоат: «Әти беребезнең генә булса да Казанга кайтуын теләде, аның васыяте иде бу. Үзен генә бирегә алып кайтып җирләп булмады, җәсәде Нәмәнганда калды, шуңа нык үкенәм. Ләкин җирле халык аны олылап искә алып, каберен карап-тәрбияләп тоталар, рәхмәт аларга», – дип искә ала.

...Үз-үзен белә башлаганда нык тәэсир иткән хәлләрнең берсе – җирле үзбәк

Ф.Әбүбәкеров – консерватория студенты. 1966

Консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов Ф.Әбүбәкеровка диплом тапшыра. 1968

халкының үксеп-үксеп елаганы аның күңеленә тирән сеңеп кала. Соңрак, үсә төшкәч кенә, моңа миллионнарның язмышына вәхшиләрчә йогынты ясаган Сталинның 1953 елдагы үлеме сәбәп булган икәнлеген аңлый ул. Икенчесе, иң зурысы – балачак хатирәләреннән үзәгенә үтеп кергәне, әлбәттә, әтисенең туган илен, Казанын сагынуы. Хәмит ага, ялгыз калган чакларында да, гаиләсе белән булган мизгелләрдә дә бик еш шау-шулы Казанын, анда калган яшьлек елларын искә алып, күңел сыкравын музыка коралларында ирештерә. Биредә инде җайга салынган иркен-тук тормышта яшәсә дә, иҗат юлын тапса да, җирле халыкның зур ихтирамын казанса да, соңгы көннәренә, минутларына хәтле Татарстанны сагыну сагышы белән яши ул.

Аллага табыну нык тыелган чорлар булса да, шыпырт кына мәчеткә дә йөри. Хәлимә ханым белән Коръән сүрәләрен дә укып, балаларының тарихи Ватаннарына кайтып, милләткә кирәкле, файдалы шәхесләр булып җитлегүен дә сорыйлар. Бөек Иҗатчы догаларны кабул итә – васыять үтәлә башлый. Фоат Хәмит улы да әтисеннән күчкән осталыгын мирас итеп алып, әлегә хәтле күзе күрмәгән, ләкин йөрәгендә сабый чагыннан ук кадерле бер ядкарь итеп йөрткән төбәккә 1962 елны юнәлә. Биредә инде аның Равия апасы консерваториядә белем ала торган була.

Шунысы күңеленә рәхәт: Казан каласы да, туганнары да, Хәмит аганың изге догалары барып ирешкән, күрәсең, үз заманы өчен шактый гына җылы каршы ала талантлы үсмерне. Равия апасының белемдәш дуслары – Григорий Гарт, Герман Крушильницкий һәм Галина Грековалар, аның кайтачагын белгәч, алдан сөйләшеп тә куйганнар: аны күренекле музыкант, профессор Натан Брауде тыңлап карарга тиеш була. Үзе ул бу мизгелләрне: «Кич, унынчы яртыда курка-курка гына түргә үтәм! Сәхнәдә бер студент скрипкада бик яхшы итеп Паганинины уйный. Натан ага миннән: «Телисеңме аның кебек оста итеп уйнарга?» – дип сорады. Каушаудан тел-

сез калдым! «Әйдә, уйнап күрсәт инде алайса!» – ди профессор ага, хәлемне аңлап. Ояла-ятсына сәхнәгә менеп, белгәннәремне башкардым. Ул миңа, бернинди дә фикер җиткермичә генә: «Ярый, иртәгә көндез кил, сөйләшербез!» – дип искә ала. Шулай итеп, тарихи Ватанга кайтып төшкән үсмер скрипкачы консерваториядә белем ала башлый. Уку йортын 1968 елны кызыл дипломга тәмамлап, шул турыда таныклык тапшырганда Нәҗип Җиһанов аңа, үзенчә шаяртып: «Син, Фоат энем, Ленин кебек укыгансың икән!» – ди. Фоатның да, әтисенеке кебек, теле үткен: «Юк, Нәҗип ага, мин аннан да яхшырак укыдым, чөнки аның бер дүртлесе булган!» – дип җавап бирә. Әтисе Хәмит ага белән Мәскәүдә укыганда бер телем ипине уртаклашкан, йоклаганда, чиратлашып, җылырак булсын өчен рояль өстен бүлешкән атаклы музыкант һәм композитор җавапны ошатып бетерми. Егет аңа әтәчрәк тоелгандыр, күрәсең. Шулай да Әбүбәкеровны күздән яздырмый. Бүгенге көндә исә ул, олыгайган саен, үзенең игелекле остазларын сагынып искә ала. Натан Владимирович Браудене: «Ул миңа, музыка дөньясында гына түгел, Казандагы тормышымда да җитәкләп юл күрсәтеп йөрде. Кулыма акыллы китаплар тоттырып, интеллектымны үстерү белән дә шөгыльләнде. Аның өендә минем ач тамагыма һәрвакыт ризык табылды. Хәтта салкын көннәрдә, өс-башымның юкалыгын искәртеп, җылы өендә генә дәресләр бирә иде. Шул кайгыртучанлыгын күңелемне төшермәслек итеп аңлата да белә иде ул.

«Син җылы яклардан кайткан кеше, Казан кышына чыдамассың!» – дип, бервакыт бер уч ике тиенлекләр хәстәрләп куйган. Мин, телефоннан шалтыратып, аңа һава торышын җиткерәм дә, ул шунда миңа укырга килергәме-юкмы икәнлеген әйтә. Натан Брауде, Израильгә күчеп киткәнче, мине ярдәменнән ташламады», – дип сагынып искә ала Фоат ага. Яһүд кавеменнән булган, үзләренә бик таләпчән, максатчан, талантлы бу халыкны җылы сүзләр белән зурлап, бездә дә аларга ихтирамны ныгыта ул.

1968 елны кызыл диплом алган каһарманыбыз Опера театрына бирелгән юлламаны шатланып кабул итми. Шулай күңелсез генә эшләп йөргәндә Академия театрында оркестр ачылачагын ишетеп ала. Бәхетенә, аның театр музыкасына нигез салучыларның берсе булган Әбүбәкеров баласы икәнлеген, егетнең татар театр сәнгатенең үзәгендә булырга тиешлеген уйлый-бәяли белүчеләр бар икән әле! Фоатны ул чагындагы талантлы актриса, тәвәккәл, бер сүзен ике тапкыр кабатларга яратмаган театр директоры Рәшидә апа Җиһаншина үзе эзләп таба. «Энем, кунакханә бүлмәсендә көн үткәрәсең икән, кил, әйдә, фатирлы да булырсың!» – дип, артык икеләнеп торырга урын да калдырмыйча, эшкә чакыра. Хатыны – виолончельдә уйнаучы Татьянасына да оркестрда урын табыла. Театрның аңа хәтле хезмәт иткән музыкаль бүлек мөдире Владимир Березин дирижерлык таягын аңа тапшырганда: «Бу театрда бөек Салих Сәйдәшев эшләгән, син аннан ким булмаска тиеш!» – дип, хәерфатихасын бирә.

Театр өлкәсендә, бигрәк тә драма театрларында музыка беренче планга чыгарга тиеш түгел, хәтта җыр-биюле әсәр уйналса да. Ярый әле Фоатның әтисенә ияреп йөреп Нәмәнганда туплаган тәҗрибәсе бар. Ходай Тәгаләдән бирелгән тоемлау, чаманы да белү кирәк дигән аңлавы бар. Драма театрында спектакльне озата барган көйләр аңа уралып-үрелеп барса да, кирәкле дәрәҗәдә генә бизәргә тиеш. Шуның белән бергә, куючының уй-фикерләрен тулырак һәм тирәнрәк аңларлык булсын тамашачы. Шул сәбәпле, иҗат йортының баш музыканты һәрбер актерның җырлый белү сәләтеннән чыгып иҗат итәргә, аларга һәрчак ярдәм кулы сузарга тиеш. Көй күпчелек очракта уйнаучының холкын, дәртен дә искә алып языла.

Без – театр училищесының 1974 елгы җыен студентлары ачлы-туклы хәлдә,

Равия, Наилә, Галия, Ренат, Фоат, Ирәдә әниләре Хәлимә Камал кызы белән

дәресләрдән соң хәлсезләнеп калган булсак та, М.Горький урамына урнашкан данлыклы театрга чабабыз. Р.Гайнетдинов, И.Хәсәнов, Ш.Миңнуллин һәм башкаларыбызга могҗизалы тәэсир иткән спектакльләрне кабат-кабат карыйбыз. Шыгрым тулы заллар булу сәбәпле, театр администрациясе без хәерчеләрне кертмәскә тырыша. Шулай да без, үҗәтләнеп, Марсель абыебызның күренүен, аның күзенә чалынуыбызны көтәбез. Ул, безне шәйләп алып: «Барыгыз, балконга менеп, ут бирү бүлемтегеннән карагыз, тик осветительгә генә комачауламагыз!» – дип, ишектән уздырып җибәрә. Өченче каттан чибәррәк кызларны да күреп-чамалап, шул ук вакытта Фоат ага Әбүбәкеровның таягын селтәп, оркестрның уйнап җибәрүен дә рәхәтләнеп карап була. М.Сәлимҗанов, П.Исәнбәт, Ришат Хаҗиәхмәтов куйган әсәрләрне тамаша кылабыз. Караган саен, кабат күрәсебез килә башлый. Хәзер дә мин, горурланып, сагынып, ул чордагы олуг иҗатчыларны искә алам. Мин бит Фоат ага Халитов, Шәүкәт Биктимиров, Рәшидә апа Җиһаншина, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Вера Минкина һәм башкаларны якыннан күреп белдем. Хәтта аралаштым да, дип, аларны юксынып искә алам. Ә тылсымлы музыкасы белән сихерләп могҗизалы сәхнә вакыйгаларына алып кереп киткән көй «маг»ыбыз, Аллага шөкер, исән бит әле: без аның белән аралашабыз, фикерләребезне белешәбез; аның файдалы киңәшләрен, истәлекләрен колак салып тыңлап утыру үзе зур бәхет бит ул. Кайсы авторларның сәхнә әсәрләренә генә музыка язмаган Фоат ага! Алар Туфан ага Миңнуллинның дистәләгән әсәрләрендә яңгыраш тапкан! Шуларның кайберләре: «Дуслар җыелган җирдә!» (1977), «Адәм баласына ял кирәк» (1980), «Моңлы бер җыр» (1981), «Монда тудык, монда үстек» (1982), «Вөҗдан газабы» (1987), «Илгизәр плюс Вера» (1991), «Акбай һәм Кыш бабай» (1991)... Йөзләгән башка әсәрләргә дә көй язган композиторыбыз ул. Шушы өчлек – милли сәнгатебезне үзләренең затлы «актерлар гаскәре» белән СССР империясенә генә түгел, чит илләргә дә танытткан М.Сәлимҗанов, Т.Миңнуллин, Фоат ага Әбүбәкеровлар, шулай ук П.Исәнбәт, Ришат Хаҗиәхмәтовлар, авторлардан

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фоат Әбүбәкеров Татарстанның халык артисты Наил Әюпов белән. Р.Якупов фотосы

Н.Исәнбәт, Р.Батулла, Х.Вахит, Ю.Әминов, И.Юзеев, Р.Хәмид, А.Гыйләҗевләребез һәм башка бик күпләр бар. Кайсы гына режиссер, кайсы гына театр директоры мөрәҗәгать итмәгән аңа. Дистәләгән театрларга, шул исәптән Башкортстан, Оренбург һәм башка иҗат коллективларына да ярдәм кулын сузган фидакарь шәхес – Фоат ага Әбүбәкеров ул. Хатыны Татьяна ханым да – күренекле виолончелист, гомере буе аның янәшәсендә татар музыка дөньясына башы-аягы белән кереп чумган шәхес. Уллары Руслан-Арслан да алардан ерак китмәгән. Пианино, рояль, синтезатор – аныкы. Курчак һәм Академия театрларына музыка язган углан ул. «Мине инде театр дөньясыннан, аның үзенчәлекле сәхнәсеннән беркем дә аерып ала алмый. Аңа соңгы көннәремә хәтле тугры калачакмын, чөнки бу сихри дөнья – миңа әтием тарафыннан сабый чагымнан ук иңдерелгән, васыять итеп тапшырылган мирас. Г.Тукай сүзләре белән әйтсәк: «Шатлыкларым, борчуларым, кайгыларым да биредә минем!»

«Бүгенге көндә, барлык Россия театр һәм кино иҗат йортлары кебек үк, безнең татар иҗат йортлары да эзләнүләр, таптанулар чоры кичерә. Аннан чыгу өчен, бергәләп иҗтиһад итү, иҗат эшчәнлекләрен даими киңәйтү кирәк! Бу өлкәдә режиссерларның, драматургларның, көйче һәм музыкантларның аңлашып, киңәшеп эзләнүләре, иҗат итүләре бик мөһим. Шул чакта гына халык театр залларына сагынып, ашкынып киләчәк. Иң мөһиме – татар милләтенең үзенә генә хас булган яңа әсәрләр сәхнәгә чыгып торсын! Читнекен йөрәге белән кабул итә алмаса да, төрләндерер өчен, анысын да фидакарь тамашачыларга тәкъдим итәргә кирәк». Фоат аганың үз сүзләре белән әйтсәк: «Һәр милләткә үзенеке кирәк! Моның өчен бөтен мөмкинлекләребез дә бар. Талантлы режиссерларыбыз Ф.Бикчәнтәев, Ф.Ибраһимов, И.Мәхмүтова, Р.Әюпов, И.Хәйруллин һәм башкалар җиң сызганып иҗат итә. Мин исә – алар куйган әсәрләргә моң өстәүче генә! Бөтен күңелемне, бөтен хисләремне салып, режиссер куйган әсәрне баетучы гына. Мин шуның белән бәхетле! Театрым, халкым белән!» ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе



ӘХМӘДВӘЛИ МӘҢГӘР ТУПЛАНМАСЫ

Әхмәдвәли Ибраһим улы Мәңгәр 1891 елның 8 декабрендә Казакъстанның Петропавел шәһәрендә туа. Аның әти-әнисе Казан губернасының Мәңгәр авылыннан (хәзерге Әтнә районында) чыккан кешеләр була.

Әхмәдвәли Мәңгәр, мәдрәсә белеме алганнан соң, Монголиягә китә, «Штукен» дигән алман фирмасы белән берлектә Россия һәм Кытай арасында йон сату эшен җайга сала. 1925 елда Кытайга күчеп килә. Монда аның кырыклап сатуалу үзәге була. Мәктәп салдыра. Мукден шәһәрендә «Милли байрак» исемле газета аның ярдәме белән чыга. Бу газетада Ә.Мәңгәрнең Кытай, Япония һәм Кореяда яшәүче татарларның хәле турында үз мәкаләләре дә басыла.

1939 елдан ул Истанбулда яши башлый. Швейцариянең «Ульрих Мейер» фирмасы белән арадашчылык итә. Күпмедер елдан соң, Төркиядәге алман фирмалары «Мерседес-Бенц» һәм «Роберт Бош»ның җитәкчесе була. Зур автомобиль сату үзәге «Мәңгәр» исемен йөртә.

1970-1980 елларда татарча «Казан» журналын чыгаруга ярдәм итә. Анда үзенең дә мәшһүр татар шәхесләре турындагы язмалары басыла. Истанбулда һәм Анкарада оешкан татар үзәкләренә мәдәни чаралар үткәрү, аралашу өчен биналар юнәтә. Фәнни-популяр, дини ки-

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

таплар бастыруга акчасын кызганмый. Бик бай китапханәсен Төркиянең Анкарадагы Тарихи эзләнүләр институтына бүләк итә. Төркия белән Татарстан арасында мәдәни-хәйрия фонды оештырырга талпынып карый...

Әхмәдвәли Мәңгәр 1978 елда Истанбулда вафат була.

Аның исемендә, үзе васыятендә язып калдырганча, химаячелек фонды төзелә, соңгы елларга кадәр бу фондны кызы Сафия ханым Имре җитәкли. Милли китапханәдәге йөз китаптан торган тупланмасы нәкъ менә аның кызы булышлыгы белән 1998 елда Төркиядән китертелде.

Тупланманың төп өлеше – төрки халыкларының тарихына, мәдәниятенә, әдәбиятына багышланган хезмәтләрдән һәм Төркиядә яшәүче татар галимнәренең төрек телендә басылган фәнни язмаларыннан тора. Татарның мәшһүр әдибе Гаяз Исхакыйның Төркиядә яшәгән чорда иҗат иткән әсәрләре саклана. Кызыклы, сирәк басма – алман телендә, Ислам буенча тулы энциклопедик белешмә дә бар. Тупланмада, китаплардан тыш, татарның күренекле әдипләре, гыйлем ияләре, җәмәгать эшлеклеләренең сурәтләрен дә күрергә мөмкин. ■

СИМЕТБАШ ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

Арча районының Симетбаш авылында 2015 елның 16 июнендә Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм тыл ветераннарына багышланган мемориаль комплекс ачылган иде. Әлеге комплексның бер өлеше булган, ДТ-54 тракторы белән Игенче-механизаторның кылган батырлыгын мәңгеләштергән әлеге һәйкәл – республикабызда бердәнбер. Проектның идея авторы һәм иганәчесе «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин**. Сүз уңаеннан, иганәченең әтисе **Нурислам Нигъмәтуллин** 39 ел тракторчы булып эшли, ә абыйсы **Нургали Шәфигуллин** сугышчан батырлыклары өчен, Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә, мәгълүм сәбәпләр аркасында, Кызыл Байрак Ордены белән генә бүләкләнә.

1941
БЕЗ СУГЫШТА ЮЛБАР
БЕЗ ТЫНЫЧТА АТТАН

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Март ахырында Әтнә дәүләт халык театры «Әкият» Казан дәүләт курчак театры бинасында балалар өчен Морис Метерлинкның «Бәхет кошы» пьесасы нигезендә спектакль (режиссеры – Рамил Фазлыев) премьерасын күрсәтте.



● Март ахырында язучы Локман Закирның «Антиутописты» дигән яңа китабы дөнья күрде.

● 1 апрельдә «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Бәрәңге район хакимияте (Мари Иле) башлыгы Әлфит Ибраев белән очрашты.

● Апрельдә күренекле галим Хатыйп Миңнегуловның «Бер елда – биш илдә (2018). Библиографик мәгълүматлар» дигән китабы «Ихлас» нәшриятында басылып чыкты.

● 4 апрельдә Татарстан Язучылар берлегенең Проза секциясе утырышында Риман Гыйлемхановның иҗаты тикшерелеп, ул берлеккә әгъзалыкка тәкъдим ителде.

● 4 апрельдә «Әкият» татар дәүләт курчак театрында шагыйрь, прозаик, драматург һәм тәрҗемәче Равил Бохараевны (1951-2012) искә алу кичәсе булып узды.

● 5 апрельдә күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм табиб Морат ага Кәримов фатирында мөхтәрәм шәхесләребез Индус Таһиров, Хатыйп Миңнегулов, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон ике кардәш халык – татар һәм казакъ тарихы, мәдәнияте һәм әдәби мирасы хакында эшлекле сөйләшү алып барды.

● 11 апрельдә «Безнең мирас» хезмәткәрләре Мамадыш хакимияте җитәкчелеге, аерым алганда, Вәзир Нәзирҗан улы белән очрашты.

● 12 апрельдә журнал хезмәткәрләре Минзәлә театрында булып, аның күркәм музееннан басмабыз өчен бик күп истәлекле мәгълүматлар алып кайтты.

● 13 апрельдә «Безнең мирас» хезмәткәрләре, Ык буе авыллары һәм Сөн Сабан туйларына нисбәтле язмалар алып кайту макса-

тында, Актаныш район хакимияте башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов белән очрашты.

● 15 апрельдә бер төркем зыялыларыбыз Г.Тукай каберен зыярәт кылды. Әлеге чарада әдипләребез һәм сәнгать әһелләре Д.Салихов, Р.Гаташ, Ә.Шакиров, Р.Зәйдулла, Г.Төхфәтова, Л.Лерон, Нияз хәзрәт Сабиров чыгыш ясады.

● 17 апрельдә Г.Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театрына Кыргызстаннан бер төркем милләттәшләребез кайтты. Мәгълүм ки, узган елда Әтнә театры Бишкәк шәһәрендә Чыңгыз Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» спектаклен тәкъдим иткән иде. Спектакль ул чакта Кыргызстанның бөтен шәһәрләренә телевидение аша турыдан-

туры трансляцияләнде. Әтнәлеләрне бик яратып калган милләттәшләребез, Казанга Бөтендөнья татар хатын-кызларының съездына килгәннән соң, театрыбызны, артистларны сагынып, Әтнәгә кайтып килергә дә җай таптылар. Әтнә театрына, аның тарихына, Олы Әтнәнең табигатенә, авылның төзеклегенә, мәчетенә, Гатаулла бай Даутов утарындагы музейга сокланып, чын татар мохитенә, мәдәниятенә, теленә гаҗәпләнеп, ләззәтләнеп йөрделәр.

● 17-18 апрель көннәрендә Уфада Татарстан әдәбияты һәм мәдәнияте көннәре булып узды. Әлеге тантаналы чара кысаларында, ут күршебез Башкортстан башкаласында мәшһүребез Г.Тукайга һәйкәл ачылды.

● 22-29 апрель көннәрендә Каспий буе дәүләтләренең милли театрлары халыкара фестивале быел беренче тапкыр Махачкалада (Дагыстан) уздырылды.

Әтнәлеләр анда Аяз Гыйләҗевнең «Югалган көн» драматик повестен алып барды (режиссеры – Рамил Фазлыев).

Әтнә дәүләт драма театры үз спектаклен 22 апрельдә Махачкаланың Максим Горький исемендәге Республика дәүләт рус драма театры сәхнәсендә тәкъдим итте.

Мирасворд

Кайбер ислам илләрендә мөселман булмаганнарга салынучы салым (иск.)

Мулла улы (иск.)

Алма сорты

Гарәп артикле

Ибн, ибне, …

Шәһрәт

Шабаев, Макаров

Борынгы грекларда халык җыелышы

… Гамбәр

Борынгы Скандинавия халыкларында: батырлар турында хикәят

Патша, ил башлыгы (бор.)

«… бичара кыз» драмасы (Фатих Халиди)

Галимҗан Ибраһимов повесте

Сөт анасы

Аның хәлен тук белми

Алтын Урда ханы

Борынгы төрки халыкларда дәүләт башлыгы титулы

Балтач районындагы авыл

Урта Азия халыкларында: шагыйрь-импровизатор, җырчы

Фарфор, фаянс (диал.)

… Геллер

Немецларның элекке атамасы

Караңгылык (иск.)

Рәсүл Гамзатовның милләте

Мишәр абзые

Башкорт халык җыры

Һади Такташның улы

Драматург Хәй …

Ир туган (иск.)

Япония каласы

Публицист … Медведев

Ай (иск.)

… Кәрим

Каеш прәшкәсе

Кулай

Сибгат Хәким поэмасы

Химик элемент

Хат, записка (иск.)

Шахмат фигурасы

Балавыз (иск.)

Урта гасыр үзбәк шагыйре

Мәккәгә барып гыйбадәт кылып кайту

Шарт теркәгече

Борынгы грек шагыйре

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: кауга, әсас, комык, Садә, Кир, Ананд, ату, вече, Әкрам, Терешкова, әл, кырма, «Иртә», чуат, Бруно, Реад, Хөсни, Аяз, «Авыл», Саттар, «Ана».
Өстән аска: күке, Фатих, Ает, Урманче, куас, аергыч, аса, Алкин, Ризван, дүшәмбе, аты, Клара, ялт, «АМО», Удә, «Нәс», Тавлин, Нури, сакура, Роза, Һади, «Сәрләүхәсез».

Рәис Габдулла төзеде.

Безнең мирас №5 май 2019

Яңа ел белән, фронтта һәм тылда яңа җиңүләр белән, иптәшләр!

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

№ 1 (6987) | ШИМБӘ, 1 ЯНВАРЬ, 1944 ел. | АЕРЫМ НОМЕРЫ 20 ТИЕН.

БЕЛОРУССИЯ ССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНА БЕЛОРУССИЯ ССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫНА БЕЛОРУССИЯ КП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫНА

Үткән ел эчендә немец илбасарларга каршы көрәштә Кызыл Армия һәм совет халкы зур уңышларга ирештеләр... Җиңү хәзер якын, ләкин аны яулап алу өчен көчләрне тагын да җигәргә кирәк, бөтен тылның үз - үзен аямыйча эшләве, фронтта Кызыл Армиянең оста һәм кискен хәрәкәтләре кирәк.
(И. СТАЛИН).

Художник Н. Сокольский плакаты.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш М. И. Калининның 1944 нче елга карата яңа ел рече

«Кызыл Татарстан» газетасы. №1 (6987), 1гыйнвар, 1944 ел

«Безнең мирас» елъязмасы /май

100 ел элек (1919)

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты рәисе М.И.Калинин Казанга килә. Ул театр мәйданында халык алдында һәм шәһәр җәмәгать оешмаларының берләштерелгән утырышында чыгыш ясый.

100 ел элек (1919)

«Эш» газетасында Г.Камалның «Ирек нуры» һәм «Революция» дигән шигырьләре дөнья күрә.

95 ел элек (1924)

«Безнең байрак»та Г.Ибраһимовның «Әдәби тел мәсьәләсе яңадан күтәрелә» исемле мәкаләсе басыла.

95 ел элек (1924)

«Татарстан» газетасы «Кызыл Татарстан» исеме белән чыга башлый.

90 ел элек (1929)

Г.Кутуй, Г.Гали, Г.Нигъмәти, ТАППның делегатлары сыйфатында, Украина пролетар язучыларының II съездына китә. Съезд 26 майдан 31 майга кадәр эшли. Съездда Г.Гали татар әдәбияты турында чыгыш ясый. («Эшче», 7 июнь.)

90 ел элек (1929)

«Безнең юл» журналы Алтын Урданың башкаласы Сарай шәһәрендә иҗат ителгән борынгы тел-әдәбият истәлеге «Нәһҗел-фәрадис» исемле әсәрнең Сәед Вахиди тарафыннан табылуы турында хәбәр итә.

90 ел элек (1929)

«Безнең юл»да Ш.Маннурның «Колчеданлы таулар өстендә» исемле шигыре һәм Ә.Еникинең «Мидхәт» дигән хикәясе басыла.

85 ел элек (1934)

Татарстанның әдәбият оешмалары, ВКП(б) ҮКның һәм Татарстан өлкә комитетының карарлары нигезендә, Татарстан Совет язучыларының Бердәм союзын төзергә һәм ул оешканчы әдәби хәрәкәт белән җитәкчелек итү өчен, Оештыру комитеты төзергә була. Оештыру комитетының мондый составы раслана: Г.Нигъмәти (рәис), З.Гали (рәис урынбасары), М.Әмир (сәркатип), И.Гази, К.Нәҗми, Г.Гали, Г.Иделле, Ш.Камал, Б.Зернит, Т.Имаметдинов.

80 ел элек (1939)

ТАССР Югары Советы Президиумының «Татар язуын латин алфавитыннан рус графикасы нигезендә төзелгән алфавитка күчерү турында» дигән Указы чыга.

*Журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. МАЙ 2019



И останется в мире слово моё…: Сагит Сунчаляй.

Историческое наследие: «Сююмбике». О.Иванова; «На парижской выставке». Г.Гали**;** «Очаг, приютивший сирот». И.Салихджан; Дом-музей Шарипа Шаймиева.

Татарский мир: «Энгель Фаттахов: «Сабантуй должен поднимать национальную гордость!»; «Кто он Эдуард хаджи Ганиев?» И.Халимов; «История кулаткинских чтений». И.Сафин; «Апанаевская мечеть: история и современность». Н.Сабиров; «Хатип Миннегулов: учёный и наставник». Т.Гилязев; «Свет зелёного камина». А.Закир.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Кладезь памяти: «Он вернулся с Победой». Р.Хузахметова.

Художественное наследие: «Древние татарские музыкальные инструменты».

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. MAY 2019

There will be left my word in the world…: Sagit Sunchalai.

Historic heritage: «Suyumbike» by O.Ivanova; «On the exhibition of Paris» by G.Gali; «The warm hearth sheltered orphans» by I.Salikhjan; House-museum of Sharip Shaimiev.

Tatar world: «Engel Fattakhov: Sabantuy must reinforce the national pride!»; «Who is he Edward khaji Ganiev?»; «The history of Kulatka's readings» by I.Safin; «The mosque of Apanai: history and modernity» by N.Sabirov; «Khatip Minnegulov: scientist and mentor» by T.Gilazov; «The light of the green fireplace» by A.Zakir.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

On the guard of the memory: «My father who returned with victory from the war» by R.Khuziakhmetova.

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments».

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Рауль Нурмөхәммәтов

1922 елның 25 маенда Чиләбе өлкәсенең Троицк каласында туа. 1948 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый. Рауль Вәли улы – Бөек Ватан сугышы ветераны, СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1950), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982).
Казан шәһәрендә яшәде һәм иҗат итте.

«Җилле көн». 1985. Киндер, майлы буяу

«Рәсем сәнгате музее». 1980. Картон, майлы буяу

«Порт». 1979. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Авыл яшьләре Сабан туена әзерләнә. Камышлы. 1961
(Минвәгыйз Зәйнетдинов «Камышлы хатирәләре»)

Бараба татарлары. Фәрит Юсупов
Безнең таң. Г.-Халикъ Садри
Өчәү. Рашат Низамиев
Үпкәләрмен кебек. Рөстәм Мингалим
Вәгъдә. Рәмзи Вәлиев
Түрәләр Татарстанны үз итә. Әгъзам Фәйзрахманов
Камышлы хатирәләре. Минвәгыйз Зәйнетдинов

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *podpiska.pochta.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.